Мансур Шиһапов

Шигырьләр, җырлар



# Язгы ташкын булып

Казан
«Мәгариф» нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ш48

Төзүчесе *Әхәт Хафизулла*

**Шиһапов М. Ә.**
Ш48 Язгы ташкын булып : Шигырьләр, җырлар / Мансур Шиһапов.— Казан : Мәгариф, 2010.— 295 б.
ISBN 978-5-7761-2036-7

Шагыйрь Мансур Шиһаповның бу китабына соңгы елларда язган шигырьләре, халык арасында популяр булган җырлары тупланды. Аларда — мәңгелек Мәхәббәт хисләре, үткәннәр белән бүгенгене тоташтыручы Хәтер басмалары, Заман агышының ярсу дулкыннары, кыскасы, алдыбызга тормыш һәм яшәеш куйган, барыбызны да борчыган проблемалар бергә җыйналган.

ISBN 978-5-7761-2036-7

© «Мәгариф» нәшрияты, 2010
© Бизәү.
«Мәгариф» нәшрияты, 2010

## МОНЛЫ ШАГЫЙРЬ

Җыр күңелне сафландырып җибәрә, хисләр дулкынында йөздерә, үткән матур-матур хатирәләрне яңарта, башны уйларга сала, өметләр уята, чын мәгънәсендә яшәргә ярдәм итә. Шуңа күрә тормышыбызны аннан башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Ни кызганыч, хәзерге күп җырларның сүзләре төссез, мәгънәсез. Шөкер, мәгънәви тирәнлек белән сугарылган җырларыбыз да шактый. Мөгаен, шуңа күрәдер андый шигырьләрнең фикерле эчтәлегенә тәңгәл килә торган көйләр туа да. Инде күп еллар дәвамында эзлекле рәвештә әнә шундый җыр текстлары тудыручы каләм ияләребезнең берсе — шагыйрь Мансур Шиһапов. Аның шигырьләренә язылган җырлар халык тарафыннан гел җылы кабул ителә, яратып җырлана һәм тыңлана, чөнки алар тирән хисле, күңеле моң белән тулган шагыйрьнең йөрәге түреннән чишмә сыман бәреп чыга, үзләре үк көй сорап тора.

Килү белән язлар, һәр кич назлап,
Пар сандугач җырын тыңладык.
Язлар бәхет бүләк итте безгә,
Туй күлмәген алдык нәкъ шул көздә,
Тик киярга насыйп булмады.

Авторның «Туй күлмәге» дигән популяр җырыннан бу юллар. Хәзер аны ишетмәгән, белмәгән татар юктыр. Композитор Мәсгут Имашев белән иҗат ителгән бу җыр ничәмә еллар халык күңелендә яши.

Мансур Шиһаповның башка шигырьләренең язмышы да шулай: композиторлар аларга канат куя тора, әсәрләр, халык күңеленә якын җырга әверелеп, радиокомитетның алтын фондына кертелә тора.

Авторның «Яшьлегем эзләре» дигән җыры да (Сара Садыйкова көе) — шул фондка кергән җырларның берсе.

Җил белән серләшкән каеннар
Яңарта яшьлегем хисләрен.
Шомыртлар ак шәлен ябынса
Сагынам авылым кичләрен.
Сагынам, сагынам, өзелеп,
Ялкынлы яшьлегем эзләрен.

Бу җыр, беренче мәртәбә ишетелүгә үк, күңелгә уелып кала, тыңлаучыны хисләр дулкынында йөздерә, күпләргә яшьлекләрен искә төшерә, чөнки ул шагыйрьнең йөрәгеннән ургылып чыккан.

Шагыйрьнең көен Рәшит Гобәйдуллин язган «Мәңгелек ут» дигән җырына игътибар итик:

Чәчләрдәге бәсләр,
Күзләрдәге яшьләр
Югалганнар, өмет өзмим мин.
Утлы юллар узган
Таң нурыдай кызлар,
Яз җилләре иссә түзмим мин,
Чәчәкләрдән сезне эзлим мин.

Сугыш кырында ятып калганнар турында менә шулай хискә бирелеп, шул ук вакытта гади, ләкин

күңелгә үтеп керерлек итеп язу өчен, шигъри җанлы талант иясе булырга кирәк!

Шагыйрьнең күп кенә җырлары 50 ел буе дияр-лек җырлана. Бу еллар эчендә инде аларны башка-ручыларның өч буыны алышынды, ләкин һаман җыр-лана, чөнки аларның көйләре дә, сүзләре дә халык күңеленә сеңеп калган, алар халкыбыз рухына җавап бирердәй итеп язылган.

М. Шиһапов,— нигездә, лирик, нечкә күңелле ша-гыйрь. Хәтта аның, әйткәнемчә, сугыш темасына язылган шигырьләре дә җылы хискә төрелгән, һәм алар да үзләреннән-үзләре көй сорап тора. Менә аның «Җиңү көне җиңел бирелмәде» шигыре:

Яшь каеннар яфрак ярган таңда,
Яшь каендай зифа егетләр,
Ил бурычын иңнәренә салып,
Утка төренеп, яуга кerделәр.

Монда сүз сугыш кырына чыгып киткән ир-егетләр турында барса да, шагыйрь шушы кырыс чынбарлыкны йөрәккә үтеп керерлек, күңелгә сеңәрлек итеп яза алган. Баксаң, сугыш темасын да лирик алымнар белән чагылдырып була икән ләбаса!

Шагыйрь иҗатында мәхәббәт темасы зур урын алып тора:

Мәшһүр ханнар, гаярь патшалар да
Мәхәббәттән янып-көюдән
Ярты ханлык, патшалыгын биргән
Нечкә билле бөек Сөюгә.
Сөю — илаһ! Бары бер тартылыш
Итеп карыйбыз без ник аңа?..
Әгәр сөюләрсез генә калса,
Зур фаҗига килер Дөньяга.

Бу фикерне шагыйрь үзенең «Мәңгелек сер» дигән шигырендә әйтә. Чыннан да, дөньяда мәхәббәт, сөю булмаса, кешелекнең яшәеше төссез, мәгънәсез нәрсәгә әйләнеп калыр иде бит.

Дөрес, шагыйрь мәхәббәт турында гына язмый, татар җанлы шәхес буларак, аны яшәешебезнең бик күп проблемалары борчый. Шуларның иң беренчесе һәм иң мөһиме — милләтебез язмышы.

Планетаның төрле почмагыннан
Ишетелә татар тавышы.
Ул тавышта үпкә, әрнү хисе,
Туган ягына бетмәс сагышы.

Бу юллар — авторның «Татар язмышы» шигыреннән. Дөньяның төрле кыйтгаларына сибелгән милләттәшләребез язмышы турында ачыну белән сугарылган ул.

Шагыйрь иҗатында, билгеле инде, кеше үзәк фигура булып тора, ул аңа күп шигырендә мәдхия җырлый.

Әмма кеше яңалыкка бара,
Аны тудыру өчен җан ата.
Күпсенмәче, Тәңрем, кеше гомерен,
Корып куйма аңа каршылык...
Син яраткан Җирдә ул булмаса,
Ник Кояшың кирәк, Яктылык?! —

ди автор «Ник» дигән шигырендә.

Тик кеше дә әүлия түгел, тормышта аның да төрлесе бар. Кеше затының ямьсез сыйфатлары, әхлаксызлык шагыйрь күңелендә чын мәгънәсендә сызлану, борчылу тудыра. Ә якты дөньяда яшәүләре бик

тә рәхәт бит. Авторның «Яшәү» дигән шигырендә әйтелгәнчә, «Зәңгәр күктә, җәелеп, кояш көлә, Җәй кочагы гүя ял йорты. Кешеләргә гомер өстәү өчен, Сихәтле бал җыя бал корты», «Урманнарда — кошлар симфониясе, Кырда тургай нәсел ишәйтә. Ак күгәрчен уйный һаваларда, Яшәү өчен канат көчәйтә». Тик шушы яшәеш гүзәллеген дә кешелек боза бит: планетабызның төрле нокталарында сугышлар, төрле конфликтлар чыгып кына тора. Бу хәл шагыйрьне аеруча борчый, һәм ул шушы шигырен:

Бар да яшәргә дип омтылганда,
Тудырганда аның чарасын,
Утлы корал, ракеталар төяп,
Ә син, кешем, кая барасың?! —

дигән борчулы уйлары белән тәмамлый.

Мансур Шиһапов юмор һәм сатира остасы да әле.

Үзенең «Төрек каешлары» дигән шигырендә шагыйрь үз илебездә җитештерелгән каешлар табып булмавы турында ачы итеп көлә. «Бурыч» дигән шигырендә исә автор күп авырлыгын халкы өстенә салган илебез адресына каты гына юллар җиткерә:


«Ил алдында бурычыңны үтә!»
Шушы иске җырны яңартып
Яши кеше, бар тапканын бүлешеп,
Казна кесәләрен кабартып...

М.Шиһапов күренекле шәхесләребезгә багышланган әсәрләренә дә олы мәгънә сала. Мәсәлән, Мөхәммәт Мәһдиевкә багышлап язылган «Утлы мизгелләрдә» дигән шигырендә ул болай ди:

Галәм гел мәңгелек булган кебек,
Бәлки, мәңгелектер кеше дә...
Шуңадыр ул Күкләр киткәннәрне
Оныттырмый — искә төшерә.

Шагыйрьнең бу яңа җыентыгы үз укучысын табар дип уйлыйм, чөнки анда авторның күп кенә җырлары да, лирикасы, тормышчан шигырьләре, юмор-сатирасы һәм багышлаулары да урын алган. Шәхсән үзем моң иясе булган бу шагыйрьгә киләчәктә дә иҗат уңышлары телим.

*Әхәт Сафиуллин,*
Татарстанның атказанган
мәдәният хезмәткәре



# Тормыш күкрәгендә бәргәләнәм

Киек казлар тагын кире кайтыр,
Туган якка тарткан – күңел ул!
Кеше гомере дә кире кайтса,
Икенче кат мин яшәмәс идем –
Кабатлану кызык түгел ул.

## ЯШӘҮ МӘҢГЕЛЕК

Яшен бәрде җирнең күкрәгенә,
Ялкын капты черек урманга.
Ут ялмады барын үз юлында,
Гүя сусаган күк корбанга.

Янды күптән корган чытырманлык,
Әрәмәлек, сары камышлар.
Табигатьтә төгәл исәпләнгән,
Табигатьтә булмый ялгышлар.

Ялкын узган киңлекләрдә язын
Тоташ яшеллекләр күкрәде.
Искене гел яңа алыштырды,
И яңарды җирнең күкрәге!..

Тормышта да һәрчак шулай булган,
Шулай килә,
Шулай булачак.
Яңарыш ул — үсеш, камилләшү,
Яңалык гел туып торачак.

Яңа сулыш, яңа җаннар сорый
Буыннарның яшәү чылбыры.
Табигатьтәгедәй кебек яңаруга,
Алгарышка барыр ил кыры.

Яшен генә кайчак хаталана,
Гөнаһсызга суга ут кулы.
Җыен вәхшиләре, башкисәре
Посып кала, каһәр суккыры!

## КЕШЕ ҺӘМ ЗАМАН

Гөрли заман,
Сөйли заман,
Мактый заман кешелекне,
Күмә-күмә гөлчәчәккә.
«Кеше» сүзен символ итеп,
Марс алыр киләчәктә.

Кешеләр ул — туачак моң,
Яңа марш, яңа җырлар.
Бәйсез дәүләт — Татарстан,
Без барасы яңа юллар...

Санап китсәң, кешелекнең
Иксез-чиксез эш эшлисе.
Фикер йөртсәң, заман түгел,
Бар дөньяны буйсындырган
Кеше-титан иң көчлесе.

## ИРЕКСЕЗ

Миңа әйтми генә тудырдылар,
Көчләп биләделәр биләүгә.
Моңа каршы акырып еласам да
Исе китмәде һич берәү дә.

Селкуләрне женем сөймәсә дә,
Салып селкеделәр бишеккә.
Әрләп үстерделәр... Күрсәттеләр
Дөнья карап торган ишеккә:

«Укырга!» — дип, фәрман яңгырады,
Укыттылар. Ансы ярыйсы...
Их, шулкадәр килгән иде минем
Авылымда атлар карыйсы.

Ни дисәң дә зәңгәр болыннарда
Син бәйсез бит! Җилләр иркендә.
Рәхәтләнеп, атлар утлап йөри,
Хыялыңны сүтми беркем дә.

Әмма юкка! Тагын әмер булды:
«Белемеңне эстә калада!»
Нәрсә кала тумышыннан алып
Һаман гел хокуксыз балага?

Ачлы-туклы укыдым. Тик берсе дә
Җылы ярдәм кулы сузмады.
Аннан — хезмәт... Гомерем буе язмыш
Фәрманнардан аерып тормады.

Күрсәтмәләр биреп килде фирка,
Өстәл сукты түрә булганы.
Һәм бүген дә шулай! Сорау телә:
Мин үземә үзем хуҗамы?!

Табигатьтә бар тереклек азат,
Бәйсез хәтта анда үләне.
Адәм баласы да — табигатьтән,
Ник хокуксыз кеше дигәне?!

Дус җилләрем чакыра туган якка,
Колагымда — атлар тавышы.
Ирекне бер татып карау өчен,
Болыннарга кайтып барышым.

## ГОМЕР ХАКЫ

Гомер юл башына кайтамын да
Кире киләм, үткәннәрне барлап:
Әнә бала чагым башак җыя,
Бармаклары белән басу тарап.

Балачакның сыек иңнәренә
И салганнар күпме тормыш йөге.
Кемдер яндырган да хыялларын,
Йөрәгендә калган бары көле...

Яшьлек атлый Казан урамыннан,
Туфлиенең тишек үкчәләре.
Аңа кырын гына карап уза
Башкаланың ыспай бичәләре.

Ә яшьлекнең такыр кесәләре
Яшәү, уку өчен саллар сүтә.
Идел шавы аңа рухлар өсти,
Дулкын җыры аны көчле итә...

Бүгенгедәй уйлап куям: «Нинди
Кыенлыклар күрми кеше заты?!»
...Ә шулай да, әгәр тормыш
Утка-суга салып алмый икән,
Гомер бәясе дә шалкан хакы.

## БЕР АВЫЛ БАЛАСЫ МИН

Шәһәргә килеп адашкан
Бер авыл баласы мин.
Озатып калган әнкәйнең
Йөрәге ярасы мин.

Кушымта:

Ташлап китмә дип рәнҗемә,
Сагынуларым үзем белән.
Авыл, кайгы-хәсрәтләрең,
Шатлыкларың минем белән.

Сабан туенда сайраган
Бер былбыл баласы мин.
Казанда акыл туплаган
Чын татар агасы мин.

Кушымта.

Көтәдер бәбкә үләне,
Яланаяк йөргән кар.
Сөйгәнемә кайттым инде,
Туган җиргә вәгъдәм бар.

Кушымта.

Сандугач булып җылыйдыр
Бакчада әнкәй җаны.
Көтегез, инеш буйлары,
Көт, серле авыл таңы.

Кушымта.

## ЙӨРӘГЕННЕ ТЫҢЛА

Һаваларга менеп, җиргә төшеп
И уйный ла кошлар көтүе.
Кеше исә җиңел күтәрелсә,
Тиз һәм авыр егылып төшүе.

Узган юлларның да чиге юкка
Ышандыру һәрчак файдасыз.
Җир — түгәрәк. Киткән урыныңнан
Тагын шунда кире кайтасың.

Ах, күп күрдек калай әтәчләрне—
Үзеңдә гел юкны бар иткән.
Барысы да төшеп калды алар,
Кеше булыр, дигән өметтән.

«Ну и ну»,— дип куйган чаклар булды,
Артык һавалыга юлыгып.
Тыйнаклары гамәл яңгыратты,
Андый исә калды тутыгып.

Бу тормышта уңга әйди күпләр,
Сулга дәшкәне дә күп аның.
Иң яхшысы,үз йөрәгең тыңлап,
Үзең үтү фани дөньяны.

## ӘЙЛӘНӘМДӘ — САРЫ ЯФРАК ШАВЫ

Гомер каеным яфракларын коя,
Алар бар да үткән елларым.
Кеше шулар белән бизидер ул
Алгы көнгә барыр юлларын.

Ә үткәндә — сары яфрак шавы,
Һәр яфрагы — гомер мизгеле.
Шул мизгелләр инде узганында
Ниләр кичергәнне билгеле.

Минем дөньям ачык әкият иде,
Шуңа күп яшьләргә чыланды.
Әгәр берәү берәр ярдәм кылса,
Аны миннән ун кат чыгарды.

Күңел күкләрем дә ачык иде,
Кемдер куып кертте яшенен.
Яшен сагалаган йөрәгемне
Учларыма кысып яшердем.

Тыйнаксызлык диеп уйламагыз,
Минем дә бар хакым әйтергә:
Бу тормышта юктан бар ясадым,
Яшәмәдем берчак әзергә!

Әйләнәмдә — сары яфрак шавы,
Кайбер мизгелләре ни тора!
Гомер каенымда калганнары
Моңга, җырга, хискә котыра!

## ЮГАЛТУЛАР

Гомер уза тора. Үткәннәрдә
Нинди рәхәт икән күрелгән?
Безнең йөрәкләргә ил кайгысы
Тугач та ук, ахры, үрелгән.

Ил хәсрәте тынган араларда,
Югалтулар телде бәгырьне.
Күпме дуслар китте мәңгелеккә,
Күрә алмый тиеш кадерне.

Мин соң Таһир түгел идеммени,
Ялгыз калган чакта Зөһрәмнән?
Хәзер яратулы тавышы гына
Колагыма килә күкләрдән.

Күпләр кебек әтиле дә идем,
Аны да бик яшьли югалттым.
Әнием дә иртә дөнья куйды —
Тормыш күкрәгемә ук атты.

Кайберәүләр:
— Мондый зарны нигә язган икән,
Кызганмаган, дияр, вакытын?
Шуңа яздым: халкым ярдәм итте
Бушатырга кайгым савытын.

## ҖАН АЧЫСЫ

Бүген монда, әрекмәнгә ятып,
Арган җилләр генә йоклыйдыр.
Кечкенә өй, капка-кура да юк,
Эзен салып, беркем чыкмыйдыр.

Үткән белән хәзергенең чиген
Аера бара бакча киртәсе.
Биредә кичләр ялгыз гына куна,
Нәумиз туа һәр таң иртәсе.

Заман хәрабә иткән шушы нигез
Гомер бирде күпме улларга.
Илнең мәнфәгате
Барысын да үзенә тартып алды
Һәм ташлады әрсез дөньяга.

Тормыш тегермәне, или-или,
Кайтырына юлын суытты.
Алар, ил хәсрәтен юа-юа,
Чит нигезгә барып юлыкты.

...Кайттым. Монда җилләр генә уйный,
Җан ачысы булып күкрәктә.
Бу нигезнең һәр уалган ташы
Гүя өзелеп төшә йөрәктән.

## ӘТКӘМ СУЛЫШЫ

Язгы таңда чишмә тавышыннан
Әткәм сулышы күк моң килә.
Сабый бала чагым, данлы җиңү көне
Искә төшсә тагын,
Әткәй, бәгърем, бер кат,
Бары, бары бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

Ил шатлыгы иде теләкләрең,
Ил бурычы иде җилкәңдә.
Илем дәшә алга,
Кыенлыклар туса,
Җиңел булсын җанга,
Әткәй, бәгърем, бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

Аяз күктә янган йолдызларның
Тыныч җиргә нуры сирпелә.
Шат илемдәй балкып,
Олы юлга чыксам,
Өстәр өчен ялкын,
Әткәй, бәгърем, бер кат,
Бары, бары бер кат
Төшләремә кереп иркәлә.

## ЯМАНСУ МИНУТЛАРДА

Көзге урман сары шәлен япкан,
Учма-учма яфрак коела.
Дулкын-дулкын моңга тулган алан
Яфрак яңгырына коена.

Кыр казлары китә, саубуллашып,
Туып үскән урман күленнән.
Ертык болытларның итәгенә
Шәлкем-шәлкем сагыш эленгән.

Тормыш кайный. Тырыш җир уллары
Ашлык-шатлык тутыра келәткә.
Алтын көзнең байлык-муллыклары
Җырлар булып туа йөрәктә.

Җирдә, күктә, галәм киңлегендә
Галиҗәнап Вакыт агышы.
Мәшәкатьләр белән беркем сизми
Мәңгелеккә ашыгып барышын.

Аккошлар да китә, ямансулап,
Алар күктә гүя ак тасма...

Урман яфрак коя
Язда тагын кабат яңарырга,
Кеше гомере менә
Үтеп бара башка кайтмаска.

...Һәм нәрсәдер җитмәс бу дөньяда,
Бәлки, безнең юклык сизелер.
Без утырткан тормыш агачына
Шәлкем-шәлкем сагыш эленер.

## КӨЗ

Урамнарда әле язлар иде,
Бүген инде әнә көз килде.
Янып торган гомер кояшының
Тагын да бер чите кителде.

Ак каеннар сары яфрак коя,
Кәүсәләрдә бары моң кала.
Яфрак төсле нигә сибелә кеше? —
Киткән юлларында шом кала.

Ах, торналар җанны телеп үтә,
Күкнең күзләрендә моңсулык.
Кеше китсә, әле җыры кайта,
Алар күбесе кайтмас моң булып.

Их, кирәк бит язда торна җыры —
Борчакларга яшел ут каба!..
Бүген әле сары яфрак коела —
Ак бәхетләр ява дөньяга.

* * *

Ак каеннар, ямансулап,
Сарыдан киенгәннәр.
Яшь имәннәр сергә чумып,
Моңаеп иелгәннәр.

Нигә бу көз ләззәтле дә,
Авыр да була икән,
Табигать аша күңелдә
Сагыш тудыра икән?

## МИЛЛИ ЖЫР

Капка төпләрендә яшь йөрәкләр
Бер-берсенә хисле сыенган.
Төннең карасыннан агылып чыгып,
Бер жыр килә инеш буеннан.

Тынган тал-тирәкләр, тынган урам,
Тыңлый аны гүя барсы да.
«Хафизәләм, иркәм, и аппагым!..»
Бу жыр канатында
Узган чорлар баса каршыга.

...Ул чакларда татар егетләре
Карурманнан атылып чыккан да,
Ирек, азатлык дип, кылыч айкап,
Атта яулар чапкан дошманга.

Йөрәгендә Хафизәләр булган,
Асылъярлар туган, моң булып.
Жиңүләре, янып сөюләре
Безгә килеп житкән, жыр булып.

Рәхмәт, җырчы! Ах, син бүген күпләр
Онытa барган җырны терелттең.
Үз күңелен үзе туң иткәннең
Күңеленә ялкын йөгерттең.

Моңнан калтыранды төнге урам,
Калтыранды инеш, чишмәләр.
Авыл булган чакта, милләт яшәр,
Милләт булса, милли җыр яшәр.

## ЙОЛДЫЗЛЫКЛАР АСТЫНДА

Безгә Елкы елы ни дә, Үгезе ни,
Кәҗәмөгезләр без — «сөзәбез».
Тик файдага моны башкарабыз —
«Сөзелгәнне» кеше итәбез.

Ат шикелле, авыр йөкләр тартып
Чыгарабыз кәҗә мае да.
Ачы кайгылар да өшеттерми,
Тугач салкын гыйнвар аенда.

Ат елында безгә астрологлар
Шактый бәхет вәгъдә итәләр.
Бәхете дә кирәк түгел, әгәр
Дус-ишләрдә ул юк, дисәләр.

Ә дус-ишләр төрле йолдызлыктан —
Кайсы Балык, Үлчәү, Сукояр...
Барыбыз галәмнең бу Җиреннән,
Уртак сыйфат — Акыл, Ихтыяр.

## КЕМ КИРӘК?

Бәхетлеләр бәхет эзләп бергә булса,
Иң беренче теләкләре — бала кирәк.
Бу парларга иң кадерле минут килсә,
Бәләкәйгә яшәү көче — Ана кирәк!

Кулларына китап алган сабыйларның
Йөзләре шат, күзе нурлы, күңел зирәк.
Фәннәр белән танышканда юл ярырга,
Кушу, алу, тапкырларга — Ана кирәк!

Сандугачлар парлап сайрый, күңелдә — яз,
Унжиде яшь — хисләрең саф, яна йөрәк.
Шатлыкларны, әрнүләрне таратырга,
Серләреңне бүлешергә — Ана кирәк!

Җитәр көзләр, олы юлдан җилләр исәр,
Сагышланып, яфрак кояр моңсу тирәк.
Илгә бәхет, безгә бәхет өстим дисәң,
Гомерең буе илһам биргән — Әниең кирәк!

## ХАТА КИҢӘШ

Җырчы булма, диден миңа,
Ул сиңа кирәк түгел.
Шагыйрь гомере — бәхетсез,
Ул гомер — утлы күмер.

Бул син, диден, сәясәтче,
Алар нинди көчлеләр!
Күкне иңнәрендә тоткан
Алып Антей төслеләр.

Дан-шөһрәт тә аларныкы,
Бәхете күктән ява.
Алар тотка ясаучылар
Син яраткан дөньяга!

Юк, тотмадым киңәшеңне —
Мин идем моңлы бала.
Сәясәтче килә-китә,
Ә җырчыдан җыр кала!

## ХИСТӘ УЙНАКЛАР

Мәхәббәттә күпме талымсызлык,
Тану кирәк азгын-бозыгын!
Уйнак күңелләрнең азгынлыгы
Сикереп чыга сөю сызыгын.

Гасырлардан милли йолаларын
Саклап килгән татар халкының
Йөзен көйдерә бүген ялган хисле
Катнаш никахларның ялкыны.

Рәшә төсле әкрен генә эри
Олы яратуның кыйммәте.
Төрле каннан туган кавемнәрнең
Юк чын горурлыгы, милләте.

Азмы бездә Әкрәм Ивановлар,
Хәбибуллин Егор, Борислар.
Ике дөнья арасында калган
Киләчәккә туган варислар.

Шунысы гаҗәп: сөюләрдә азган
Үзен тота шундый гөнаһсыз.
Ә артыннан йөрәк җимеше килә —
Күбесе телсез, денсез, имансыз...

## ҖИҢҮ КӨНЕ ҖИҢЕЛ БИРЕЛМӘДЕ

Яшь каеннар яфрак ярган таңда,
Яшь каендай зифа егетләр,
Ил бурычын иңнәренә салып,
Утка төренеп, яуга кerделәр.

Кушымта:

Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк елый Муса, Алиш өчен,
Егермеләп миллион җан өчен!

Тарих шаһит: үлмәс Карбышевлар
Әверелә бозга — ил сатмый.
Татар улы — батыр Газинурлар —
Күкрәкләре белән ут каплый.

Кушымта.

Яңгыра, җыр, тыйнак илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып,
Батырлыгы булып халкымның!

Кушымта.

## ДӨНЬЯГА

Дөнья, мине иртә яраттырдың,
Яраттыра белгән кыз кебек.
Ләкин гаҗәп, синдә яхшылыктан
Яманлыгы йөри иң элек.

Кеше сиңа тумышыннан гашыйк,
Күзләреңә карый, йотылып.
Ни өчендер, бәхетсезгә түгел,
Бәхетлегә
Бирәсең син бәхет, тотырып.

Ни булмасын, чиксез өслегендә
Беркайчан да сүнмәс яктылык.
Шуңа шатмын: күкрәгеңдә һәрчак
Яманлыкны җиңә Яхшылык.

## ЯЗМЫШ СҮЗЕ

— Йә, әйт, язмыш, нигә диеп әле
Ул чибәргә барыпябыштың?
Кешегә алдан язылып,
Алдан барын белеп,
Хисләреңдә тирән ялгыштың.

Зәңгәр төннәр төсле күзләреңдә
Нинди йолдызыңны күзләдең?
Аның чуарланган йөрәгеннән
Нинди шатлык, бәхет эзләдең?

Кабынгандай булып кыланды да
Синнән файдаланды, — янмады.
Бәхетеңә булган өметеңне
Иблис кызы кебек алдады.

Абындыңмы, сөртендеңме, дускай?
Бәгъреңә ул укны аталар!
Хәер, сезгә, язмышларга, һәрчак
Шактый гадәти хәл хаталар...

— Юкны сөйләмә син, — диде язмыш, —
Сез үзегез бит мине язасыз.
Уйламыйча абынып-сөртенәсез,
Ә хатасын миңа ябасыз.

## ИЛ БӘЛАСЕ

Киек казлар китә... Офыкларга...
Күзге күктә — моңнар агышы.
Алар кебек кешеләр дә китә,
Туган җирдә кала сагышы.

Адәм баласында гынадыр ул
Язмышларның иң дә кырысы.
Ватан кочагына бар да сыя,
Тик барысына җитми җылысы.

Азмы даһи башлар китеп барды,
Җитмәгәнгә җылы һавасы.
Гомер бакый ил кадәрле илнең
Бу — бәласе һәм дә җәзасы.

Киек казлар кайта... Каршы ала
Туган якта калган сагышы...
Чит илләрне дан-шөһрәткә күмгән
Безнең күпме галим-зыялының
Җаны гына кайтып барышы.

## ХӘРӘКӘТТӘ — БӘРӘКӘТ

Җир әйләнә...
Шуңа күрә әйтәдер ул гавам,
Хәрәкәттә, диеп, бәрәкәт.
Туктамасын гына бу хәрәкәт,
Ясамасын кеше һәлакәт.

Кай галимнәр бүген оран сала
Киләчәктә яшәү хакында:
Халык саны үрчи, диләр алар,
Җир туйдыра алмас барсын да.

Хакимнәргә гүя тик шул кирәк,
Бу фаразны итеп коралы,
Сугыш уены уйнап гомер кыя,
Кара канга батырып дөньяны.

Борчылмагыз, галим, хаким затлар,
Сезнең фикер, ахры, мүкләнгән.
Җир — җанлы ул! Аның — үз хисабы,
Анда һәрнәрсә дә үлчәнгән.

Кирәк булса, артуны да тыяр,
Кирәк кадәр бирер ризыгын.
Туганнарга кирәгенчә генә
Сызып куяр яшәү сызыгын.

Җир әйләнә. Мәңге әйләнсен ул!
Хәрәкәттә, диләр, бәрәкәт.
Кабынмасын гына җиһан сугышы,
Килмәсен лә соңгы һәлакәт!

## ЙӨРӘК АВАЗЫ

Кайвакытта үләселәр килә,
Китәселәр килә тормыштан.
Шулчак кинәт йөрәк аваз сала:
Нинди шайтан сине котырткан?!

Мондый уйны әйтсен йолкышлары,
Әтрәк-әләм, җыен бичара.
Синең шәкертләрең заманада
Халкын уйлап яңа юл яра.

Азмы шәфкать кылдың гомереңдә,
Бик рәхмәтле аңа кешеләр.
Ярдәм кулы суза белгәннәр ул
Бу дөньяда озак яшиләр.

Эчке дөньяң хисләр белән тулы,
Моңнар ага күңел кырыңнан.
Аһ-зар гына түгел, милли рух та,
Яшәү көче килә җырыңнан...

Бераз арттырса да, хакны әйткәч
Кабул иттем йөрәк тавышын.
Хәзер
Яшәешкә мәрсияләр җырлап,
Ак кояшка карап барышым.

## КАЗАННЫҢ ТАРИХИ ВОКЗАЛЫ

Җидегән йолдыз күк җемелдәп,
Нур сибә чал шәһәр байрагы.
Әй гүзәл шәһәрнең язлары,
Бакчада — гашыйклар назлары.
Тукайча дәртле син, нурлы син,
Моңлы син, Казанның вокзалы.

Толларның күз яшен яшерде
Сагышлы Иделнең чал яры.
Җиңүләр маршына кушылып
Җырлады Кремль чаңнары.
Мусаны юксынып елады
Казанның тарихи вокзалы.

Бәхетле яшьлекне яшьнәтеп
Ямьләнә башкалам таңнары.
Кол Шәриф мәчете милләтнең
Үткәнен, иманын саклавы.
Татарның меңьеллык көзгесе —
Казанның тарихи вокзалы.

## ГҮЗӘЛ ЗАТКА БИР ТҮЗЕМ

Бәйрәмнәр бетте... Саклады
Сигезенче март үзен.
Инде башкача әйтәм мин
Ирләрчә котлау сүзен:
Күңелләр җәүһәре булган
Асыл затка бир түзем,
Асыл затка бир түзем.

Үзгәрде заман... Саклады
Изге җан нурлы йөзен.
Яшәү көче, сулыш биргән,
Әйтеп иманлы сүзен...
Мәхәббәтнең таҗы булган
Әнкәйләргә бир түзем,
Әнкәйләргә бир түзем.

Сулдылар гөлләр һәм ирләр,
Шиңде чәчәкләр көзен.
Таллыкта моңнар тараткан
Сандугач тынды кичен.
Мәңге сүнмәс, төсен җуймас
Гүзәл затка бир түзем,
Гүзәл затка бир түзем.

## БУЛСА ДА

Тормыш күкрәгендә бәргәләнәм,
Җиһан киң һәм иркен булса да.
Ул иркенлек, белмим, кем өчендер,
Ә без әле һаман кысада.

Фикеремә, уйларыма кысан,
Әлегә сүз ирege булса да.
Иң кысылган ыру татардыр ул
Шушы иркен вә киң дөньяда.

«Карурман»нан чыктык томырылып
Тулпарларда, кыен булса да.
Дөрес юлны кемдер саташтыра,
Алда кора күпме бусага.

Тулпарчылар! Изге мәсләгенә
Бару кирәк, кыен булса да!
Татар максатына ирешә ул,
Алларында җирләр упса да!

## ЮЛГА ЧЫКСАҢ

Юлга чыксаң,
Якын дусты
Була ала
Кешенең эт.
Әгәр дустың
Эт күңелле
Кеше булса —
Яманлык көт.

## ТАЗА РУХ — ХЕЗМӘТТӘ

Авыр сүзләр әйттең миңа, дисең,
Хезмәт итеп яшәү хакында.
Хурлык тактасына кадакладың
Таныш, дус-ишләрем каршында...

Бәлки, хаксызмындыр. Мин дә, энем,
Хода тирмәсеннән төшмәгән.
Шушы җирдә туган, тирем тамган
Туфрагымның исен иснәгән.

Сөргән аны, чәчкән, азаматлар
Сугыштан соң кайтып егылгач.
Илнең яраларын бәйләшкәнмен,
Сезнең өчен анда ут тынгач.

Безнең буын тырыш гамәл белән
Чишеп килде Ватан кайгысын.
Хәзер ул хис сездә саклана мы,
Ил турында уйлый кайсысы?..

Бәлки, хаксызмындыр, бәхәсләшмим,
Эшләп арганнар ул карышмый.
Синең кебек кеше җилкәсендә
Яткан гына, энем, ялгышмый.

Менә хурлануың ансы яхшы,
Димәк, синдә әле өмет бар.
Хезмәт итсәң — рухың таза булыр,
Рухсызларга гомер юлы тар.

## ҖЫР ИШЕТӘМ ТАУЛАР ИЛЕННӘН

Юк, ял түгел, илнең мәнфәгате
Алып килде Кырым ягына.
Бер җыр ишетәм таулар итәгеннән,
Гүя диңгез
Чайпалды ла нечкә җанымда.

Бу милли җыр айкап, тетрәндереп,
Йөрәгемә елап сыенды.
Туган җирдән ерак тарафларда
Татар моңнарына коендым.

Эзләп киттем аны җырлаучыны,
Таптым көтүендә тугайдан.
Һәм сорадым: «Әйтче, и кардәш,
Мондый моң соң синдә ул кайдан?»

— Ата-бабалардан, — диде миңа, —
Ул килгән бит дәвер, чор аша.
Татар халкы күргәннәрне күрсә,
Гел моңсыз да моңлы булачак.

## ЯШӘҮ СЕРЕ

Тәгәрәп лә елыйсылар килә
Кайчагында ачы зарлардан.
Кемгә кирәк хәзер кеше зары,
Аңлаучылар сине кайларда?

Онытылып югаласы килә
Диңгез дигән зәңгәр киңлектә.
Дөнья мәңге дигән матур ялган
Тотып тора җиһан-бишектә.

Сүтелеп лә китәселәр килә
Җыеп алалмаслык иттереп.
Юк шул. Тормыш, чиш, дип, алларыңа
Каршылыклар өя, китереп...

Аптырагач, хис ташкыны булып
Кушылам да китәм язларга.
Заман кырыс. Хисләреңне менә
Аңлаучылар мохтаҗ назларга!

Ләкин җирдә гомер бакый һаман
Кешелекне Сөю коткара.
Сөю булса, фани дөнья яши,
Ул булмаса, Яшәү туктала.

## КАЙДА СОҢ?

Балык Бистәсе ягыннан
Алсу таң аткан чакта,
Иркәли Яншык җилләре —
Мин кайтам туган якка.

Әй ямьле, нурлы үзәннәр...
Без малай идек ул чак.
Бәтке чишмәсе суында
Баш юа идек, туктап.

Яшь юа иде чишмәдә
Соңгы ат, соңгы ирләр.
Өч авылдан өч йөз батыр
Соңгы кат үткән җирләр.

Әткәйнең сагышлы җырын
Әй ятлап калган кырлар...
Биш ятимнең күз яшеннән
Газиз әнкәйнең йөзенә
Бик иртә кунган сырлар.

Мин кайтам, хыялга чумып,
Каршымда — авыл тавы.
Кайда ул Шынгый чишмәсе,
Кайда ул таллар шавы?

Нәкъ шул чишмә буйларында
Бер кызны сагаладым.
Бөрнәкә очы сылуы
Йөрәкне телгәләдең дә
Гомерлеккә яр булалмый
Күңелне яраладың.

«Туй күлмәге» дигән җырым
Шул чибәр җаваплары...
Сагынудан талды микән,
Саргаюдан арды микән
Яшьлегем канатлары?

Чишмә ярында тукталам,
Карыйм су төмен татып.
Көмеш суда ак чәч йөзә...
Их, ник тиз үтә вакыт?..

## ӨМЕТСЕЗ ӨМЕТ

Күпләр:
«Яңа заман гел өметсез итте,
Идеалыбыз юк,— дип зарлана,—
Киләчәккә күңелләрдә,— диләр,—
Төшенкелек итә тантана».

Вәли исә андыйлардан түгел,
Өмет белән
Карый белә килер елына.
Алыпсатар булып, кеше талап,
Байлык туплый ике улына.

Зурысына шәп йорт салып бирде,
Кечесенә алды машина.
Өмет зурдан:
«Сагынып, дога юллап яд итәрләр,
Китеп баргач Тәңре каршына».

Оныкларына да акча җыйды,
Алар да өлешсез калмасын.

Ни дисәң дә, нәсел өметләре,
Шәҗәрәдә буын алмашы...
Менә аны озак авыру басты,
Үлә алмый ятты түшәктә.
Улларының берсе әйтте шулчак:
«Йөрәк таза икән имгәктә!»

## ҮЛЕМ ДӘШКӘЧ

(Әнгам Атнабаевка ияреп)

Үлем дәшкәч, нәрсә дияргә?
Якын итеп эзләп тапкан икән,
Туры килә барсын сөйләргә.

— Бурычым күп, туган, судан — салкын,
Уттан ялкын алдым, — бирмәгән.
Нәрсә булыр җирдә, эз калдырмый,
Җиңел китсә шулай һәр адәм?..

Беләгемнең көчен, йөрәк дәртен,
Килә намусымны түләсем.
Шатлыкларым, кайгы-хәсрәтләрем
Түләмичә ничек үләсең?

Туган туфрагыма хакым бик зур,
Кабул итмәс, үлем, ялгышма.
Бер чибәргә бәхет вәгъдә иттем,
Түләмәдем, салдым сагышка.

Үтелмәгән юллар, корыч куллар,
Изге теләкләрем калмасын.
Илгә, халкыма да бурычым зур —
Юк, юк, үлмим, Алла сакласын.

Үлем кадәр олы башың белән
Очсызланма, калдыр, яшәрмен.
Бурычларым бетеп хәлсезләнгәч,
Кунак итеп үзем дәшәрмен.

## БӘЙСЕЗЛЕК

Тудым... Дәрәҗәне күтәрергә
Бераз гына алдым елап та.
Кендек әби миңа бәхет юрап,
Әфсен укып өрде колакка.

Мин — ирекле! Бишек-җиһан — минеке!
Беркем дәгъва итми бит аңа.
Нинди рәхәт бәйсез булып яту,
Тавыш бирү азат дөньяга.

Бурыч, вазифа юк. Синдә бары
Яшәп калу өчен талпыну.
Имезлектән иңгән кара икмәк,
Ана сөте көченә табыну.

Тормыш юлына баскач... үзгәртәләр...
Бәйсез булып калу бик авыр.
Сурәнләнә хөрлек кояшың да,
Көннәр, еллар була болгавыр.

Язмыш дигәнең гел бәйлелектә
Иләнә дә, хәтта хуҗаңа.
Ил яклый ул! Хуҗаларның гына
Исе китми синең нужаңа.

О, ул бишек-җиһан бәйсезлеге!
Кайнар каныма минем сеңгәндер.
Мин үз фикерем белән гомер сөрәм,
Кешенеке белән — кемнәрдер.

## ХАЛКЫМ ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

Сөембикә манарасы
Ае нур сипкән көндә
Бөтен дөнья татарлары
Азан әйттеләр бергә.

Кушымта:

Кунак булыйк, милли бәйрәм —
Сабантуйда, татарлар!
Уйныйк, көлик, җырлыйк, биик,
Дошманнар сөйләп йөрсеннәр:
«Татар барда — хәтәр бар!»

«Татар барда — хәтәр бар»,— дип
Шау киләләр һәр илдә.
Сафлык, пакьлек, шатлык, хаклык
Халкым җыелган җирдә.

Кушымта.

Аяз күгемдә мәчетләр
Алтын нур сипкән кичтә,
Данлы Казан, моңлы азан
Мәңге сакланыр истә.

Кушымта.

## АКЫЛ САТУЧЫЛАР

Ишәйделәр акыл сатучылар,
Әйтерсең ул казна алтыны.
Ярый да бит әле үзенә җитсә
Аның сата торган акылы.

Акыл дигән кыйммәт төрле бит ул,
Бар төплесе, була кыегы.
Ничек яшәү рәвешен өйрәтәләр
Акыл шәрифләре сыегы.

Күбрәк «мин-мин»ләләр бик ярата
Тар акылы белән уйнарга.
Әнә кемнәрдер
Дәверләрдән «акыл» сатып килә
Үзеннән сәләтле татарга...

Табигатьтә нинди гармония,
Кешедә дә нинди камиллек!
Үз тиңеңә акыл өйрәткәнче,
Үз акылың үлчә иң элек.

## САГЫНАМ БАЛЫК БИСТӘСЕН

Ялгыз аккош парын эзли,
Язлар килгән, нишләсен.
Төшкән күлгә — гүзәл җиргә,
Сайлап Балык Бистәсен.
Таңнар аткан, ярын тапкан,
Серләшә, күз тимәсен.

Таң сандугачы тирәктә
Мактап сайрый чишмәсен.
Мең дә бер рәхмәт, гүзәл кош,
Күңел кылларын чиртәсең,
Яшьлек үткән серле якны —
Зурлап Балык Бистәсен.

Читкә киткән изге җаннар,
Сагынып Кама иртәсен,
Аккошлар булып кайталар
Чибәрләр, әй, күз тимәсен.
Туй ясарга бу якларга
Сайлап Балык Бистәсен.

## ТУГАН ТЕЛ

Тарих шаһит: золым телебезгә
Ничә тапкыр кулын күтәрде.
Иң беренче аны Явыз Иван
Кылыч йөзе аша үткәрде.

Горур калып, урманнардан чыкты
Ул чагында татар телебез.
Баш имәде чукындырганда да,
Шуңа күрә туган телле без.

Кызыл еллар аның итәгенә
Бик астыртын гына ут төртте.
Милли мәктәпләрне яба-яба,
Матур сөйләп каты утыртты.

Мондый чакта исән каладыр ул
Телнең иң төплесе, зирәге.
Югалтулар булды... Ана теленең
Кайнар калды типкән йөрәге.

Заманалар белән нигә безгә
Килә тора ачы гөнаһлар:
Бүген туган телнең тамырларын
Корыта бара катнаш никахлар.

...И туган тел! Дөнья кочагына
Алып кердең безне иң элек.
Аннан яшәү бирдең! Син үзең дә
Яшәү кебек сүнмәс, мәңгелек!

## ТАРИХИ ЧИР

Тарих түрләреннән килә ул «чир»
Хәзерге көннәрнең каршына:
Камай морза, Шаһгалиләр кебек,
Татар җитә татар башына.

Шушы үләт эшлекләрен эшли
Бик тә сак һәм үтә астыртын.
Көтмәгәндә кеше йөрәгенә
Угын китереп кадый капылтым.

Ни гаҗәеп, тормыш юлларында
Игелекле булган татарның
Арасында табыла вак җанлысы,
Үз намусын үзе сатары.

Табыла компроматлар җыючысы,
Кер эзләүче тырнак астыннан.
Явызлыкны өстен күрүчесе
Дуслык, туганлыктан — барсыннан...

Ак болытлар төшеп иңнәремә
Әкрен генә миңа эндәшә:
— Инкыйраз бит, барлык кан кардәшең
Дус һәм бердәм була белмәсә!

## ЯШЕН ХАТАСЫ

И күкрәде күкләр,
Яшен ертып йөрде болытларны!
Ләкин алар китте — яумады.
Яңгыр көткән кешеләр рәнҗи калды —
Болыт өметләрен алдады.

Гөнаһлылар әллә ишәйгәнгә
Яумый китте Тәңре яңгыры.
Әнә күпме әшәкеләр үрчи,
Төссезләнә гүя ил кыры.

Яшен кире килеп чартлады да...
Җирне телде утлы уклары.
Ялгыз бер имәнне сукса сукты,
Тик әшәкеләрне сукмады.

Нинди гаҗәп, сәер дөньядыр бу:
Чи утынлы учак күмерле?
Намуслы җан кыска гомер итә,
Кара җанлы — озын гомерле...

Яшеннәрнең сәер зур хатасын
Истә тотсын иде көчләләр:
Әшәкене канун алалмаса,
Себереп түксен аны кешеләр!

## РӘХМӘТЛЕ БУЛЫЙК

Бу дөньяга нигә тудым, диләр,
Уфтаналар...
Мин дә тудым. Болай ярады,
Тумасам, дөньяны күрмәс идем,
Күпне белде гомерем дәвамы.

Иң мөһиме, яктылыкны күрдем,
Яшәешнең таҗын — Кояшны,
Ямьле Җирне. Алар җылысында
Гамәлләргә җиктем бу башны.

Матурлыкны күрдем. Матурларның
Кылганнарын кыю батырлык.
Матурлыктан башка кешеләр юк,
Кешеләрдән башка — Матурлык.

Гүзәллекнең бер өлеше — кеше
Галәм тикле чиксез галәмдә...
Белдем бик күп затлы, зыялыны
Һәм очрадым затсыз адәмгә.

Кешелекне күрдем, шәфкатьлене,
Миһербанлыларны, гамьсезне.
Саф йөрәкне, изге күңеллене,
Мәкерлене, шактый мәнсезне.

Шау чәчәкле язлар каршыладым,
Катнашылды
Ил-халыкка кирәк эшләрдә.
Мәхәббәтнең үзе нәрсә тора!
Нигә яшерергә,
Аны татыдым зәңгәр кичләрдә...

Туу, яшәү — җирдә зур бәхет ул,
Нигә уфтанырга, ди, аңа.
Галәм-Җирнең сөйгән уртасы без,
Рәхмәтле булыйк дөньяга.

## КӨНБАГЫШ

Нинди кызу, челлә, җәй кояшы...
Нинди сихри кичен көнбаеш!
Кояш көнбаешка барган саен,
Аңа башын бора көнбагыш.

...Куштан савыт тота хуҗасына,
Көнбагыш күк башын бора да.
Ялагайлар үрчи, мәкер кавем,
Артык каза булып дөньяга.

Бик астыртын сатыла әхлак, намус,
Саф йөрәкле кеше сатыла.
Шундый түбәнлеккә төшә кемдер,
Үзе яшәп калу хакына.

Көнбагышны алай гаепләмим,
Ул бит — табигатьнең җимеше...
Менә нигә сата-сатыла икән
Тәңре җимеше булган бу кеше?!

## ЮГАЛМАСЫН ТАЛАНТЛЫЛАР

Талантларны барлап бару кирәк,
Акыллысы,
Мин шундый зат, диеп кычкырмас.
Һәрбер туган талант сүнеп барса,
Биеклеген саклап Ил тормас.

Татарда бик күп ул талантлылар —
Фикерләүнең Колумблары.
Шулар яктысына тигезләшә
Күп өлкәдә фәннең утлары.

Җир йөзендә Гейне, Байрон булса,
Бездә юкмы әллә Тукайлар?!
Алар җыры кораб компасыдай
Күрсәтәдер — алга юл кайда.

Үстерәбезме соң талантларны,
Сыегып бит рухи коебыз...
Ни өчендер, затлылыклар кими —
Бүген арзан акча колы без.

Ярый да бит шушы мәнсез шөгыль
Упкыннарга таба илтмәсә.
Тормыш шаһит: газиз татар башын
Татар ашый әле, җитмәсә...

Яңа чорга Тукай, Дәрдемәндләр,
Такташ, Туфан кирәк!
Аларсыз шигърият — Мулласыз.
Ясалмалылыкны яратабыз,
Яңалары
Тик ясалма гына булмасын.

## ВАСЫЯТЬ

Кузгалсам да, йөрәк чәнчеп ала,
Карап кына ятам дөньяга.
Туктар, ахры... Күкрәгемдә күпме
Язылмаган моңлы җыр кала...

Васыятем бар сезгә, мәкерлеләр,
Тапшырганда мине Ходайга,
Игелекле булып кыланмагыз,
Икейөзлеләр күп бит болай да.

Илсур энем, сиңа да бар теләк:
Үзгәрмә син, сабыр, түзем бул!
Элеккечә, бергә чактагы күк,
Икейөзләнмә, үзең бул!

Соңгы васыять сезгә, дус-ишләрем,
Бер нәрсәне оныта күрмәгез:
Дусның хөрмәтеннән үзегезгә
Гадәтенчә файда сөзмәгез.

...Ах, сүнмәдем! Рәхмәт инде, Ходам.
Сырхавыңны җиңдең, йөрәгем!
Васыятьләргә килсәк, исән чакта
Әйтеп кую ярый кирәген.

## НӘРСӘ ӘФЬЮН?

Тукыдылар илгә: «Дин — әфьюн ул,
Агу булып сеңә миеңә».
Малай чакта нәни йөрәк әйтте:
— Бисмилласыз тормыш ниемә?

Тормыш — тормыш инде, бара тора
Динлеме ул, әллә динсезме.
Фәрештәсе качып киткән заман
И үрчетте җыен денсезне.

Ә аларны үзенең ятьмәсенә
Урый барды хәмер дигәне.
«Яшел елан» менә исбатлады
Нәрсә мигә агу икәнне.

Миндә исә ике дөньясы да —
Иман һәм чынбарлык —
Бергә үрелеп килде, әлбәттә.
Чынбарлыктан яшәү көче алдым,
Иманыннан баедым әдәпкә.

Хәмер йотты бик күп алтын башны,
Хәтта ил тотарга яраклы
Кешеләр күптән хак мөһерне сукты:
«Дин түгел, ә аракы — әфьюн!»

## БӘЛКИ...

Кешелекле һәрбер гамәлләргә
Аяк чала кайбер мәгънәсез.
Юк, бу тормыш берчак булмас, ахры,
Мәгънәсез һәм мәнсез адәмсез.

Ә шулай да тормыш кысасында
Андый затлар алар сирәктер...
...Бәлки,
Кемнең кем икәнен белү өчен,
Шундый сирәге дә кирәктер?

## ТУГАН ЯГЫМ

Мирәт буйларында үстем,
Салкын суларын эчтем.
Чылтырап аккан суы тәмен,
Сихри болынның ямен
Ташлап еракка киттем.

Кушымта:

Их, Мирәт күл буем!
Кайтыр идем, күрер идем —
Тибрәнә синдә уем!

Күл өстендә акчарлаклар
Табигатькә ямь өсти.
Басмадан су алган кызлар
Һич тә исемнән китми.

Кушымта.

Бирер идем әллә ниләр
Күрер өчен агышың.
Кайтып яр буенда йөрсәм,
Күлдә ай йөзгәнен күрсәм
Бетәр кебек сагышым.

Кушымта:

Мирәт буе камышлар,
Сезгә кайтсам таралалар
Читтә җыйган сагышлар.

## ХАТИРӘЛӘР ЯҢАРГАНДА

Рус белән гомер кичердек, сайрашып...

*Г.Тукай*

Бәтке — рус авылы. Малайлары
Безнең белән кузна уйнады.
Әгәр алар хәрәмләшә калса,
Хаклык өчен йодрык сынадык.

Каршы як та җебегәннән түгел —
Җилкәбезгә төште кәшәкә...
Аннан җыелып бер карарга килдек:
Мондый ызгыш ничек әшәке!

Дуслар булып өйгә таралыштык,
Үсеп җиткәч, илгә таралдык.
Еллар узган саен, дуслыгыбыз
Хатирәләр булып яңарды.

...Рус белән тату гомер кичтек,
Бер бишектән төшкән шикелле.
Тормыш безгә бер үк сынауларны,
Бер үк җиңүләрне китерде.

Табыла әле хәзер Державада
Мәче йөгертүче арага.
Рус халкына юк ул, кирәк түгел,
Никтер, кирәк
Кайбер сәясәтче агага.

Шовинистлар арта синдә, Рәсәй.
Бу сагайта, хәтта куркыта.
Берсен берсе тигез күрсә генә,
Күпмилләтле халык Ил тота.

## КҮҢЕЛ ДУЛКЫНЫ

Урай буйларында — аксыл рәшә,
Инеш ярларында — керәшә.
Тал кызлары, толымнарын сүтеп,
Йөгерек дулкын белән серләшә.

Ә сез кайда, минем киек казлар,
Калдыгызмы чит-ят җирләрдә?..
Рәхмәт сезгә, минем торналарым,
Кайткансыз бит туган илләргә.

Тургайларым, зәңгәр һаваларда
Гел сайрагыз, шулай бирелеп.
Зур тормышның тәрәзәсе аша
Балачакка карыйм, үрелеп.

## ҖИР ҮЧЕ

Юк, исмәде котырынып җилләр,
Җимермәде көчле давыллар,
Күтәрелде кинәт елга-сулар,
Акты йортлар, акты авыллар.

— Афәт! Бәла! — диде бөтен халык,
Шуннан башка берни күрмәде.
Ул афәтне үз куллары белән
Китергәнен генә белмәде.

Сабыр Җир-анабыз гомер бакый
Тырыша ул үзен сакларга.
Ташуларын атты өслегенә
Каф таудагы утны басарга.

Табигатьнең серен һич аңламый
Миһербансызлыкның
Иман, хокук белән көрәше.
Шуңа күрә кайнар ноктларда
Үлем йөри, коеп күз яше.

Без сулыйбыз, җир дә сулыш ала —
Безнең өчен яшь Җир-ана!
Аның тынычлыгын санга сукмау
Хәвеф-хәтәр китерә дөньяга.

## БАШКАЛА

(Казанның 1000 еллыгына)

И Казаным! Янар яшьлегемә
Зур капкасын ачкан Башкала!
Милләт өчен бөтен игелекле эш
Кайнар йөрәгеңнән башлана.

...Даның күмү өчен, чал тарихта
Килде сиңа Иван[1], чехлар да.
Яралардан телгәләнеп беткән
Күкрәгеңне тотты тупларга.

Көл-күмердән чыктың, күтәрелеп,
Каһәр, ләгънәт орып Иванга.
Халкың сине чорлар аша нурлы,
Пайтәхетле итте җиһанда.

[1] *Иван* — Иван Грозный.

Бүген менә матур уйлар кила:
Кирәк очкыч, «кара алтын»ы.
Ят тарафта илсез-җирсез йөргән
Милләттәшкә күңелең ялкыны.

Иман, әхлак, рухи азык эзләп
Ашыга сиңа Хода бәндәсе,
И дөньяның татар өммәтенә
Иң кадерле, изге Мәккәсе!

Үсәсең син күккә,
Үсәсең син киңлекләргә —
Урман, сулар, кырлар ягына.
Кешеләрнең хезмәт тулы, таза,
Көләч тормышлары хакына.

И Казаным! Янар яшьлегемә
Туры юл күрсәткән Башкала!
Милләтемнең имин киләчәге
Шанлы гамәлеңнән башлана.

## СОНГА КАЛМАГЫЗ!

«Коткарыгыз-з-з!..»
Инеш дулкыннарын калтыраткан
Ялварулы тавыш ишеттем.
Шунда ыргылдым да соңга калдым—
Үсмер чакта җанны өшеттем.

Авылыбызның шундый гүзәл кызын
Әҗәл яшьли итте корбаны.
Әллә инде җирдә Тәңренең бер
Фәрештәсе артык булганмы?

Еллар аша ачы шушы сүзне
Хәзер менә тагын ишетәм.
Ул бер ләгънәт булып кереп-чыгып
Йөри бүген һәрбер ишектән.

«Коткарыгыз-з-з!..» Шундый аваз килә,
Якын көнчыгыштан, көньяктан.
Балкан-таудан килә өтәләнеп,—
Бу җирләрне
Су басмаган, анда ут капкан.

И кешеләр! Ник сез битарафлар?
Шартлау... Сугыш... Күпләр Алласыз!
Туктатыгыз тизрәк мәхшәр туен,
Юкса
Минем кебек соңга каласыз!

## ЯҢА ЕЛДА ЯҢА ТЕЛӘК

Яңа елда
Чыктык юлга,
Бик тә чиста кар ява.
Ак кар кирәк,
Пакь кар кирәк —
Сафлык җитми дөньяга.

Юртак чаба,
Карда — чана,
Ә чанада туй бара.
Татлы сүзләр,
Гашыйк күзләр —
Сөю җитми дөньяда.

Йөрәкләрдә,
Күңелләрдә
Кемдер калдырган яра.
Уйныйк, көлик,
Җырлыйк, биик —
Шатлык җитми дөньяга.

Хаклык телән,
Пакьлек телән,
Өмет утлары яна.
Ә мәхәббәт
Дәвам итсен,
Алмаш килсен дөньяга.

## НИНДИ КИЧ БУ?

Нинди кич бу? Йолдыз сипкән күкне
Каплады да алды кара болыт.
Караңгылык карый тәрәзәдән,
Кара йөрәкләр күк, шомнар булып.

Ә көне бит нинди матур иде,
Нинди матур иде зәңгәр дөнья!
Менә хәзер җанга кинәт кенә
Әллә нинди салкын яңгыр коя.

Яшен уйный. Пәри туе төсле,
Түбәләрдә бии куркыныч җил.
Капылт кына искә төшә шунда
Коръән кәлимәсе: «Иманга кил!»

Үрсәләнгән халәт ләкин тыныч —
Имансызлык кылып йөргәнем юк.
Гомер бакый әле тормышымны
Һич тә дәһрилеккә төргәнем юк.

Бу дөньяда бар да вакытлыча —
Кеше, гөлләр, чәчәк, караңгы төн.
Болыт таралды да...
Алтын Айның канатына басып,
Тәрәзәмә карый иртәге көн.

## ОСТА

Поши кебек чытырманны ерып
Килеп чыкты берәү урманда.
Бергә кайттык. Чыбык-ботак җыйган —
Нинди коры-сары юк анда!

— Нигә, мәйтәм, сиңа мондый чүп-чар,
Кәкре-бөкре чыбык-чабыклар?
Аның белән тормышта бит бары
Учак кына яга халыклар?

Күп сөйләшми дәште фатирына,
Матур иде аның күңеле.
Бер бүлмәгә кердек. Менә кайда
Әкиятләрнең сихри бер иле.

Ни генә юк анда: убырлылар,
Шүрәлеләр, Дию, бүреләр...
Синең күзләреңә карап тора,
Әйтерсең лә бар да тереләр.

Кайсы кая йөгереп качар төсле,
О, бу тылсымлы кул хикмәте!
Эшкәртелгән чыбык-ботаклардан
Көлә чын сәнгатьнең кодрәте...

Кемдер байлык, мал артыннан куып
Югалтканда иман догасын,
Кемдер зурлый, гүя җанландыра
Халык иҗатының мирасын.

* * *

Йодрык хәтле генә үзең, йөрәк,
Кулга алсаң, учка сыясың.
Үзең кайчак, янар таулар төсле,
Эчтән дөрләп, гүләп куясың.

Янар тау атылса, утлы лава ташый,
Син атылсаң, кайнар кан ага.
Һәр тамчысы тын-тын тама, гүя
Үпкә, каргыш булып дөньяга.

Ах, ник кирәк каргау бу дөньяны?
Ул бит — кешелекнең бишеге.
Миллиард җаннар анда тирбәлгән дә
Ямьләп киткән аның өслеген.

Балаларын нинди уттан алып,
Нинди суга салмый Җир-ана...
...Табиб йөрәгемне яман ята,
Ә мин көлеп ятам дөньяга.

## РӘНҖЕТҮ

Көчле иде. Һәрбер эштә
Булды кирәге.
Кеше өчен, диеп типте
Кайнар йөрәге.

Тау-таш кисте, юллар салды,
Төзеде кала.
Ул корган ГЭСлардан илдә
Якты ут яна.

Гигантлар салган чакта да
Керде өлеше.
Халкыма булсын, диП янды
Хезмәт җимеше.

Кулын суздЫ ярлыларга,
СуздЫ ятимгә.
Йөрәгенең ялкыннарын
Бүлде һәркемгә.

...Ул картайды. Ялга китте.
Аны...
Бар да онытты.
Картлыгында шундый мәнсез
Хәлгә юлыкты.
Көчле чакта Үзе кирәк
Һәм кирәк эше,
Күзләренә кергәч, нигә
Онтыла Кеше?

## ИДЕАЛ

О, идеал дигән тарту көче —
Кешеләрнең өмете, яшәве!
Тик, никтер, ул, аңа барган саен,
Офыкларга чигенә, каһәре.

Үзе тарта, үзе еракләша,
Мавыктыргыч утлар шикелле.
Ул бу җирдә күпме ихлас җанны
Үзенең фанатлары иттерде.

Без дә фанат идек. Ничә еллар
«Якты киләчәк» дип котырдык.
Матур ялган икәнен дә белдек,
Ләкин һаман аңа омтылдык.

Чөнки өмет идеалыбыз иде,
Ялган булуындамыни эш.
Идеал булса, авыр юл да җиңел,
Өмет булса, татлы ул тормыш.

Хәзер әнә ансыз гына калдык,
Елар чакта килә көләсе.
Ил чайкала, йөзә кай яккадыр,
Гүя Нух пәйгамбәр көймәсе.

Бүгенге көн белән яши бар да,
Иртәгене шайтанмы белә?
Идеалсыз, рухсыз мал куганы
Илгә бөҗәк төсле сибелә...

Заманалар алышынып тора,
Һәрберсендә төрле уй, хыял.
Әмма кешедә «чын Кешечә яшәү!» —
Менә нәрсә булсын идеал.

## КҮҢЕЛ СӘЯХӘТЕ

Туган як, туган туфраксыз
Яшәве җиңел түгел.
Ә шулай да...
Чегәннәрнең таборына
Ияреп китте күңел.

Алда — ирек, анда — хөрлек,
Болыннар һәм сулыклар,
Иксез-чиксез карурманнар,
Мавыктыргыч офыклар.

Кысып торган кануннарга
Газиз башны имисең.
Кимсетелү, җәберләнү,
Тарлыкларны күрмисең.

Иң мөһиме — бу тормышның
Иң азат баласы син:
Тирә-якта — тургай җыры,
Күктә — кояш, җирдә — мин!..

Менә бермәл туйды күңел
Чегәннәр таборыннан.
Аңлады ерагайганын
Туган җир тамырыннан.

Азатлык рәхәт! Барыбер
Күңел сагышка батты.
Кире әйләнеп кайтты ул —
Үз халкына, туфрагына
Каны һәм жаны тартты.

## ЗАМАН ҺӘМ ҖЫР

Сәхнәләргә атылып барып менеп,
Җырны мыскыл итте күбесе.
Нурсызланды тамашачы зәвыгы,
Тоныкланды рухи көзгесе.

Вакыт узган саен, бу кавемнең
Әрсезлеге һаман көчәя.
Җыр тавының бөркетләре кими,
Чыпчыклары гына ишәя.

Булырмы соң тагын киләчәкнең
Илһам, Әлфиясе, Зиләсе?
Өметсезлек... Кемдер булыр дисә,
Килә аңа башны иясе.

Чүп-чарларның кара төнгә сыенып
Чыкканына вәхши сунарга
Соңгы сүз әйтелер! Менә куелырмы
Соңгы чиге тессез җырларга?..

Шундый сорауларга җавап эзләп
Йөрим бүген кышкы буранда.
Чөнки беләм: Кеше көчле була,
Милли моңы, бөек Җыр барда.

## МОҢЛАНУ ҺӘМ СЫЗЛАНУ

Әллә инде җилләр усалланган,
Әллә инде каты күз тигән,
Яшьлегемнең сихри җырчылары —
Ак каеннар — сулып баш игән.

Тургайларым гүя мәрткә киткән,
Сүрән генә чыга кояш та.
Урамнарда өйләр кечерәйгән —
Тәбәнәеп калган бер башка.

Урай урманы да боегып тынган,
Җырлап акмый Шыңгый чишмәсе.
Аҗаганнар уйный шырпы сызып,
Кыр түрендә — төннәр киртәсе...

Аһ, ак җәй бит әле! Мондый күренеш
Керфегемә нигә эленгән?
...Күңелемдә — сары яфрак шавы,
Гомерем агышына көз килгән.

## НИГӘ?

Гомер бакый Кеше ут эчендә:
Үзе кабыза, үзе аңа керә.
Җирдә җәһәннәмне тудыра да,
Үзе үк шуңа төшеп үлә
Нигә?

Заманында
Атиллага Римда нәрсә калган,
Батый ханга — Болгар Иделендә,
Аксак Тимеренә — Әфганында,
Ә Ермакка — Себер киңлегендә?
Кан коелган нигә?

Тик берәүнең дан, рәхәте өчен
Миллион-миллион гомер киткән
Нигә?

Явызлык һәм Хаклык көрәшендә
Күбрәк Явызлыгы җиңгән
Нигә?

Күпме түзәлмәслек ачык яра
Ярылып ята тарих күкрәгендә.
Ә яңасы һаман салына тора
Акылы үҗәт Кеше «күкрәве»ндә
Нигә?

Галәм-җирне
Тетрәндереп килгән бу сорауны,
Кешеләр, бирәм сезгә!
Нигә?

## МОДАЛАР

Вакыт узып, чорлар үзгәрәләр,
Тик үзгәрми бары нужалар.
Заманалар кире кайткан кебек,
Кире кайтып йөри модалар.

Егерменче еллар...
«Долой стыд!» дигән төркемнәрдән
Шаулап тора Казан урамы.
Ярым шәрә кызлар-егетләрнең
Каннарында «ирек» бураны.

Барысы да тына...
Әдәп кайта үзенең кысасына,
Тормыш күген яулый яңа чор.
Әхлак эзләп таба ияләрен,
Туа таза рухлы яңа җыр.

Заман үзгәрде дә...
Шул ук мода тагын кире кайтты:
Урамнарда кыска итәкләр.
Ялан ботлы уйнак чибәрләрне
Азган хисләр бара җитәкләп.

Заманалар кире кайткан кебек,
Кире кайтып йөри модалар.
Ата-ана, ил хәсрәте өчен
Мода булып кала нужалар.

## ҮТКӘННӘРДӘН БЕР АВАЗ

Синдә кешеләрнең хыяллары,
Хәсрәт-кайгысы да, и авыл!
Селкеде дә сине, талкыды да
Илдән узып киткән һәр давыл.

Урамнарың авыр хатирәле:
Малай чакның айлы кичендә,
Фәсихә апа өе түбәсендә
Ире йөрде
Ак кулмәкле фәрештә төсендә.

Үксү катыш чакырулы аваз
Китә иде ерак үрләргә...
Ул елларның тирән газаплары
Оялады бик күп өйләрдә.

Бергә өч көн яшәп китте яры,
Ятып калды сугыш кырында.
Ә түбәдә тилерүле тавыш:
«Күрәм!.. Кайта!.. Район юлында!..»

Ах, ул нинди нәфис, гүзәл иде —
Бер кашык су белән йотарлык.
Шаһиншаһ Сарае тәхетенең
Шаһинәсе итеп тотарлык!

И авылым! Батыр уллар бирдең
Гел тынгысыз газиз Ватанга.
Онытылмас, бетмәс кайгың белән
Якынсындыр ла син бу җанга.

## ЗАМАН КИҢЛЕГЕНДӘ

Менә бу киңлек, ичмасам!
Күренеп тора бар да:
Кешеләр ярлыга, байга
Бүленеп ята анда.

Әниле ятимнәр тулган
Тормыш урамына.
Ач-ялангач кереп бара
Дөнья буранына.

Кулын сузган карчык тора
Чатта, туңып-өшеп.
Заман сыны булып баскан,
Тарихтан ул төшеп.

Шаулый базар, гөрли базар,
Елмая алыпсатар.
Алдау кәсебе үзләштерә
Монда «яңа татар».

Бер-берсенең җанын кыя —
Кемнәр кемгә үчле.
Әкиятләрдән күчеп килгән
Аждаһалар төсле...

Бу киңлектә, күзгедә күк,
Бар да күренеп тора.
Кояш күктә ярым борылып,
Йөзен чытып тора.

## ШУНЫ ТЕЛИМ

Бер могҗиза! Кышның иңнәренә
Зәңгәр күктән язлар ишелә.
Дөнья сүрән, яшәү бик тә кыен
Күңелендә язсыз кешегә.

Карлар елый, җырлый гөрләвекләр,
Язлы йөрәкләргә җыр тула.
Туган телен җуйган оятсызларның
Күңелендә җыры онтыла.

Ә җыр исә — тормыш чыганагы,
Кояш кебек кирәк һәркемгә.
Телсез, җырсыз, язсыз калганнарны
Җирдә хөрмәт итмәс беркем дә.

Бер манзара! Кышның күкрәгенә
Күк йөзеннән язлар ишелә.
Шуны телим: халык денен кертсен
Телен йоткан манкорт ишенә.

## КАЙСЫ ЖАН НИЧЕК

Әхмәдинең эте ияртеп кайтты
Ятим көчек — артык кашыкны.
Ә аларга хуҗа кеше зуррак
Оя ясау өчен ашыкты.

Эт көчеккә ояның түрен бирде,
И ялады битен, борынын.
Салкын төннәр килсә ачты аңа
Үзенең ихлас җылы куенын.

...Бала тудыру йорты.
Тәүге тавыш бирә
Нәфис затның йөрәк пәрәсе.
Бер яшь ана калдырды да китте
Шушы йортта
Яңа тапкан газиз баласын.

## САБАК

Янартаулар бәреп чыктымыни,
Тетрәде бар Америка җире.
Гүя тотты аны гөнаһлар,
Тотты гүя үзенең яман чире.

Болытларга ашкан биналары
Ком тавыдай ишелде дә төште.
Бер гөнаһсыз меңләгән җан китте,
Күккә качкан фәрештәләр төсле.

Сыкрады җир, барлык халыклардан
Бәддогалар яуды явызларга.
Террорчылар сабак укыттылар
Күкрәк суккан ачыгавызларга.

Җитди уйлаганда — зур фаҗига!
Планета буйлап үлем шуыша.

## ИМӘН

Гыйнвар. Шартлады кыш. Зыкы суык
Ялмап йөрде бөтен урманны.
Йөзьяшәрлек имән хәтерләми
Бәгыренә
Мондый суык кереп тулганны.

Килде язлар. Бөдрәләнде урман.
Имән генә яфрак ярмады:
Зәһәр салкын өткән тимер тәне
Язда тернәкләнә алмады.

Ләкин тамыры бик тирәндә иде,
Ә тамырлар — яшәү терәге.
Алар бирешмәде, чөнки аны
Җылытып торды җирнең йөрәге.

И күкрәде тамыр! Карт имәннең
Бөреләре ачты күзләрен.
Ул, үлемен җиңеп, җәй башында
Киеп куйды яшел күлмәген.

...Әгәр чирләп, яшәү кызыгы китсә,
Туып үскән якка ашыгам.
Туган туфрагымда тамырым калды,
Шуңа анда бик тиз савыгам.

## ЯЛГЫЗ АНА

Урамнарда буран котырына,
Өй түрендә шомлы моң ага.
Төн йокысы качкан... Кызын уйлап,
Тәрәзәгә баккан бер Ана.

...Ул киткәндә әле язлар иде,
Инде ничәнче кат
Кыш бураны туен төшерә.
Бердәнберен көтә ялгыз карчык,
Зарыгудан жаны күшегә.

Йөрәк жимешенең үзе түгел,
Килми хәтта сәлам хаты да.
Ах, бу жирдә азмы ваемсызлык,
Мәнсезлекләр ана Хакына.

Ә кыз, хистән пәрәвезләр үреп,
Зур калада итәк уйната.
Жиңел тормыш күкрәгенә басып,
Уйнак, дәртле күңелен юата.

Төссезләнгән нәфис иреннәре,
Йөзләреннән инде нур киткән.
Кирәк түгел аңа әнисе дә,
Татлы кичләр булса, шул житкән.

Урамнарда буран котырына,
Йә улый ул, йә бер көрсенә.
Газиз аналарын онытканнар
Бәхет тапканы юк берсе дә!

## ЙӨРӘК ӘЙТӘ

Язлар күкри! Сафлык, яшәрүләр!
Хис, хыяллар дөрли берьюлы.
Зур тупылда кәккүк аваз сала,
Ә ул аваз сәер, борчулы.

Кәккүк кабат-кабат кычкыра да
Тынып кала кинәт берара.
Җаның түрләренә үрсәләнеп,
Ниндидер бер сагыш, моң ага.

Өметсез һәм ялгыз тавышында
Үзәк өзгеч авыр әрнеш бар.
Әйтерсең лә дөнья йөрәгенә
Ыргытылган каты рәнҗеш бар.

Ник килгән соң әле ул авылга?
Яшәве бит аның урманда.
Үзенең парын әллә югалтканмы,
Эзли мәллә аны урамнан?

Тыңлап торам. Ул да җан иясе,
Кызганулы хисләр күңелдә...
Йөрәк әйтә: кызганырлык түгел,
Чит кош оясына йомыркасын
Салып йөри ич ул бүген дә.

## СЫЗЛАНУ

Җәйләр килсә, кичке зәңгәр күкләр
Йолдыз мәрҗәненә чигелә.
Күкләр мәңге матур! Җирдә генә
Кеше ашыга ямьсез чигенә.

Көзләр килсә, кара толып төсле,
Кара болыт баса иңнәргә.
Илдә эшсезлекләр арта бара,
Ил язмышы белән нишләргә?!

Кышлар җитсә, буран котырына,
Ач ерткычтай улый төннәрдә.
Ерткыч кебек миһербансыз үрчи,
Заман таянычы кемнәрдә?

Ах, арыдым!.. Гомерем буе
Төрле газап талкый күңелне.
Тик бер тыныч көнгә бирер идем
Артта калган бөтен гомерне.

## БУРАН

Улый буран, дулый буран,
Котыра төне буе.
Гүя күктән җиргә төшә
Шашынган пәри туе.

Алар бииләр шикелле
Кыекта һәм чормада.
Өй эченә керер иде,
Керә алмый — догада!

Әкрен генә курку били,
Балачак бит, балачак!
Тормыш иблисләре белән
Алыш алда булачак.

Алар белән көрәшләрдә
Йөрәгем таланачак.
Прометей төсле чукылып,
Бәгырем канаячак...

Улый буран, елый буран,
Төшә дә моржаларга.
Аннан үксеп, моңнар булып
Тарала чормаларга.

Мич башында җылы, рәхәт,
Тыңлап ятам тын гына.
Ә күңелем түрләрендә
Гаҗәеп бер моң гына.

## ЫРУГ

Шәҗәрәмнең агачыннан
Сорау бирә бабам:
— Нәселеңдә ничә бабаң,
Беләсеңме, балам?
Син туган нигездә алар
Тормыш итеп киткән.
Сиңа көч биргән кырларда
Күпме иген иккән,
Илен ашлы иткән.

Шәҗәрәңне белү өчен,
Бик күп зиһен китми.
Нәселенә илтифатсыз
Үзен хөрмәт итми,
Динен хөрмәт итми,
Җирен хөрмәт итми!..

Җавап бирә алмадым мин,
Өйрәнмәгән — нишлим?!
Тарих буйлап
Урыс кенәзләрен беләм,
Бабамнарны белмим.
Хәтта патша, юлбашчылар
Өйрәтелгән — истә!
Менә ыруым затлары
Соралмаган һич тә.
Шундый барлык ырулардан
Тора бит ул милләт!
Мәгарифтә аңламаган
Шуны күпме имгәк.

## ШИГЫРЬ

Таңга кадәр җырлар язып утырам,
Үтәп йөрәгемнең гозерен.
Сораулы уй йөгерә алгы көнгә:
Гомерең бармы синең, шигырем?

...Үткән меңьеллыкның башыннан ук
Барлап киләм кыйтга, кыйссадан —
Шигъри сүзләр илаһи көч булган,
Юлдаш, терәк булган һәр заман.

Колгалидән Туфангача шушы
Изге аралыкны узам да
Күрәм: шигырь исән, һаман яшь!
Әйләнсә дә кеше тузанга...

Шулчак каударланып, атылып, янып,
Башка килә утлы бер фикер:
Шигырь укымаган — тутык күңел,
Укыганның — күңеле саф, шөкер!

...Туар гасырлардан уем карый
Каршы чаба торган елларга.
Кеше килә, Кеше, таянган да
Җан азыгы шигырь-җырларга!

## ЯШӘГӘНДӘ БУЛСЫН

Кайвакытта бер нәрсәгә
Минем исем китә:
Ни өчендер,
Шагыйрьләрне корбан булу
Күбрәк данлы итә.

Герой булмас иде Җәлил,
Башын чапмасалар,
Бу хакта язылып калган
Җырын тапмасалар.

Бәлки, зурланмаслар иде
Кутуй, Кәрим, Алишның
Язган җырлары да,
Әгәр ятып калмасалар
Сугыш кырларында.

Туфанны ал! Бу әүлия
Күпме каһәрләнгән!
Җырчы бөеклеге килде,
Менгәч җәһәннәмнән.

Корбан булмаганы әнә
Яза, китә тора.
Исән чакта исеме яшь,
Аннан онытыла.

Нигә килә соң бөеклек,
Шагыйрь сүнгәч кенә—
Корбан булып,
Йә дөрләп бетеп,
Гүргә кергәч кенә?!

Кемгә кирәге бар аның,
Каплап алгач кабер?
Яшәгәндә булсын иде
Кешеләргә кадер!

## КЕШЕ

Кеше гомер тавын төшеп бара,
Тау итәген күзли карашы.
Әкияттәге төсле бигрәк кыска
Яшәү белән сүнү арасы.

Ул борылып карый, ә шулай да
Илгә файдалы юл үтелгән.
Күпме хатирәләр истә калган,
Ә күбесе чыккан исеннән.

Истә булганнары яңаралар:
Анда күпме хезмәт җимеше.
Алданылган өмет, ышанычлар,
Омтылышның сыкрап тибеше.

Матур хатирәләр белән бергә
Бәгырь телгәне дә уелган:
Күңелеңнең чиста күлләрендә
Хыянәтче яр да коенган.

Их, килә лә аның гомер тавын
Тагын бер кат менеп төшәсе.
Иске хаталарны кабатламый
Тыныч кына тормыш үтәсе.

Нигә әүлиядай булмадым, дип
Уйлый кеше соңгы сызыкта.
Юк, хәтта фәрештәләр —
Марут белән Һарут ялгышканнар.
Дөнья
Ялгышулар белән кызык та.

## СУКБАЙ

(Гаҗәеп талантлы булып та,
шул байлыкны файдалана белмәгән дусларга)

Көзге җилләр кала урамына
Болытларны куып китерде.
Зур йорт почмагында сукбай утыра,
Ташландык бер көчек шикелле.

Эчкә баткан пыяладай күзләр
Хәтерләтә мәет карашын.
Бу җан үтә сыман мизгел калган
Яшәү белән үлем арасын.

Кинәт ул соранып кулын суза,
Ялваргандай кешегә текәлә.
Әйтерсең лә хата-ялгышларын
Учларына салып күтәрә...

Аның да булгандыр чын тормышы,
Сөйгән балалары, хатыны.
Эшендә дә көчле дөрләгәндер
Йөрәгенең сүнмәс ялкыны.

Бүген аны эченә суырып алган
Хәмер баткагының сазлыгы.
«Яшел елан» йоткан ихтыярын,
Көчен, үзенә хөрмәт барлыгын.

«Шушы заман корбаны ул!» — дияр
Тормышына аек фикерле.
Юк, хәмердә үзен югалтканнар
Төрле заманда да бертөрле.

Көзге җилләр алып килгән болыт
Салкын яңгыр булып ишелде.
Йортка ышыкланып сукбай утыра,
Судан чыккан көчек шикелле.

## КИЕК КАЗЛАР КАЙТА

Киек казлар тагын кире кайтыр,
Туган якка тарткан — күңел ул!
Кеше гомере дә кире кайтса,
Икенче кат мин яшәмәс идем —
Кабатлану кызык түгел ул.

## ДУЛА, ДАВЫЛ!

Халәтемдә — давыл,
Күкрәгемдә — яшен,
Ник дулыйсың син, җан? Нишләдең?
Күрәсеңме,
Заманада тыныч почмак табып,
Посып ята синең ишләрең.

Чаптар атлар сыман каударланып
Ыргыласың фани дөньяда.
Очкан очкыннарың кабына да,
Узган эзләреңдә ут яна.

Әнә анда күпме эшлексезләр
Ул ут ялкыныннан җылына.
Син милләт дип оран салган чакта,
Алар гомер сөрә тын гына.

Яшь үзенә яңгыр тидермичә,
Давылларсыз, яшен, утларсыз.
Яулап алган бик аз иректән дә
Оста файдалана туктаусыз.

...Уйна, яшен! Дула, давыл, җанда!
Сез бит гамәлләргә яраклы.
Давылларда туа милли гимн,
Яшеннәрдә килә азатлык.

## БИК ЯКЫН СИН, ЯНШЫК КИЧЕ

Сандугачлар чут-чут итеп сайраганга,
Ак каеннар әкрен-әкрен шаулаганга,
Һавасына таралганга гөлләр исе,
Күңелемә бик-бик якын Яншык киче.
Урамында Ильич уты кабынганда,
Егетләрнең шат җырлары агылганда,
Биләп ала күңелемне шатлык хисе:
Нинди матур һәм гүзәл син,
Яншык киче!!
Кар-бураның биткә бәреп кыйнаса да,
Шаян җилләр җиңгә кереп уйнаса да
Гашыйк итә туган якның сихри көче:
Күңелемдә — нурлы, моңлы
Авылым киче.

## ТОРМЫШ ҖАВАП ЭЗЛӘТӘ

Кыйммәт тудырып килгән күңелебез
Тирәнрәк безнең диңгездән.
Аның тирәнлеге Илгә кирәк,
Ләкин...
Кирәклеген сорый кем бездән?

Йөрәкләрдә ирек давыллары
Көчле иде янар таулардан.
Үз вакытында форсат ычкындыр да,
Табасың, ди, аны кайлардан?

Кан тамырың шартлап ярылганда,
Табиб ярдәм итә ичмаса.
Илдә халык җаны сызлаганда,
Ачы сызлауларын кем баса?..

Бу тормышның салкын күкрәгендә
Шактый шундый сорау туа да,
Җавапларын табу өчен генә дә...
Китә кеше теге дөньяга!

## СОЛДАТ КҮҢЕЛЕ

Солдат күңеле — янар хыяллар ул,
Үтелмәгән авыр юллар ул.
Постта торган һәрбер минутында
Туган ягын сагыныр, уйлар ул.

Солдат күңеле — алсу чәчәкләрнең,
Яшел тугайларның исләре,
Янып эшләп үскән колхоз кыры,
Тальян моңы, авыл кичләре.

Солдат күңеле — яшьлек дусларының
Вәгъдәләре, өмет чишмәсе,
Көткән кызының сагыш-хыяллары,
Укылмаган китап чишмәсе.

Солдат күңеле — авыр чорыбызның
Ышанычы, көче, терәге,
Күз яшьләре тамган аналарның
Өметләре, керсез йөрәге.

## ЯЗНЫҢ ШАУЛЫ КҮКРӘҮЛӘРЕ

Ташулары белән язлар килде,
Табигатьне манды яшелгә.
Урман шавы күкри:
«Кеше, заман күлмәгенә төреп,
Ачы гөнаһларын яшерә!»

Иркә каеннарда язгы шаулар:
«Дөнья матур, дөнья күңелле!
Буыннардан килгән матурлыкны
Кеше сөртеп йөри түгелме?»

Татар тупыллары күкрәүләрдә:
«Уяу бул син, шанлы милләтем!
Кемдер сине бүлгәләргә тели,
Таркаттырма татар өммәтен».

Күкри басу-кырлар, ташу-сулар:
«Җирдә бар халыклар гел үзенчә
Гомер сөрүләргә ни хаклы!
Кан коймыйча гына, чын дусларча,
Туганнарча яшәү ни татлы!»

Бар табигать ак кояшка урли,
Алда игенле җәй киләсе...
Язлар алып килгән бу күкрәүләр
Әйтерсең лә Коръән сүрәсе.

## АЯНЫЧ

Ялгызлыгы аны җитәкли дә
Алып чыга шәһәр бакчасына.
Ул җитмештә...
Ялгыз күңеле, сабый бала төсле,
Иярә дә уйный
Моннан узып йөргән барчасына.

Кала иңенә сыенып таулар йоклый,
Башларында изри каурый болыт.
Күккә карый. Ә күк нинди зәңгәр!
Шунда илтер җанын соңгы минут...

Һәм һәр көнне ашыгып каршысыннан
Эшкә үтә япь-яшь чибәр ханым.
Аккош сыман горур сыны атлый,
Яхшы белеп чибәрлекнең санын.

Карт күзәтә: караш, йөз чалымы,
Атлап барулары нинди таныш!
Гүя яшьлегеннән тәүге ярын
Китергән дә куйган ачы язмыш.

Аһ, ул сөекле яр! Хатыны иде,
Аерылдылар. Харап итте ялгыш.
Хатын-кыздан бүтән мантымады,
Гомере узды сүрән, нурсыз — ялгыз!

Ә ялгызлык яшен камчысыдай
Теләә йөрәген дә, бәгырен дә.
Уе утлы: вакыты җитеп килә,
Кайсы мәрхәмәтле салыр каберенә?

Тәүге ярда калды нәни кызы.
...Алар бүген берсен берсе белми.
Шул үз кызы алларыннан үтә.
Ә карт ялгыз... Соңгы көнен көтә...

## АЧЫЛГАН СЕР

Мин яшердем аны зәңгәр күктән,
Урман-таулар, елга-күлләрдән.
Кызыксынып, җанны борчып йөргән
Бу тормышта әллә кемнәрдән.

Һәм сакладым утлы яшеннәрдән,
Гарасаттан, җилдән-давылдан.
Ул күңелнең ерак түрләрендә
Өч кат ишек белән ябылган.

Лаф оруны җенем сөймәгәнгә,
Тыйнаксызлык гел ят булганга,
Һаваланып, хис-серемне сөйләп,
Азык ясамадым дошманга.

Ансыз яшәвемнең мәгънәсе юк,
Аның белән якты күкләрем.
Шул хис ярдәмендә кышымда да
Көләч язлар булып күкрәдем.

Гомер уза. Күңел белән йөрәк,
Инде ул серне әйт, диделәр.
Дулкынланып, бүген шуны ачам:
— Мин яратам сезне, Кешеләр!

## ГҮЗӘЛЛЕК КӨЧЕ

Май урманын кошлар хоры күмгән —
Алар яшәү өчен кагына.
Тик ул гына, башын түбән иеп,
Уйларына баткан тын гына:

«Нигә килә кеше бу җиһанга,
Салып анда бөтен көчеңне,
Газап камытларын киеп аргач,
Сыкрап җирдән китү өченме?»

Шулчак кулына бер күбәләк кунды,
Аллы-гөлле, гүя сипкелле.
Гүзәллекнең тиңсез тажы булган
Табигатьнең үзе шикелле.

И кузгалды хисе! Күкрәгендә
Тотынды ла җаны яшьнәргә!
Бәхетсез булсаң да,
Тик Гүзәллек өчен генә җирдә
Кирәк, диде, кирәк яшәргә!

## АЙНЫ, ТАТАР!

Борылды да тарих әйтте беркөн:
— Сине көчле итеп
Мин тудырдым, татар баласы!
Уйламаган идем күкрәгемдә
Тик канлы эз булып каласың.

Сатып эчтең шәхси горурлыгың,
Саттың гореф-гадәт, йолаңны.
Таптап уздың бабаңнарның рухын,
Тереләй күмдең милли дөньяңны.

Үз телеңә төкереп карап,
Ят куенга акты хисләрең.
Милләт тикле милләт эреп бетте!
Нишләдең син, татар, нишләдең?!

Бүген, чын иманга дога юллап,
Мәчетләрдән чыгу урынына,
Чиркәүләрдән чыгып киләсең син,
Кургаш тәре тагып муеныңа.

...Бүген әле болар шикләр генә,
Жанның сыктап, сыкрап торуы.
Ә кем белә,
Әгәр татар тизрәк айнымаса,
Моның бик тә мөмкин булуы.

## КИРӘКЛЕЛӘР КИТӘ

(Илдар Юзеев вафатыннан соң)

Кеше китә... Жаның сызылып кала,
Язмышка без бик зур үпкәдә.
Ни аяныч, кирәклеләр китә,
Алар кирәк, ахры, Күктә дә.

Пәйгамбәрдәй затлы жаннар сүнә,
Ачынудан йөзләр саргая.
Әллә инде Тәңре тирәсендә
Пәйгамбәрләреме азая?..

Иртә сүнә шагыйрь, әдипләре,
Намус, вөҗданлысы сыкрап.
Шундый исәненең үкчәсенә
Заман басып килә, җан сорап.

Кала бирә вәхши, миһербансыз —
Тормаганы хәтта чүпкә дә.
Андый кавем кирәк түгелдер ул
Җирдә генә түгел, Күктә дә...

Китә кеше... Яхшылары китә,
Гүя йөрәк тамырын актарып.
Кирәкленең гомерен озайт, Аллам,
Сүнгәч, булмый Аны кайтарып.

## МӘДХИЯЛӘР КИРӘК ӘТИЛӘРГӘ

Ул ел язлар кинәт кенә килде,
Дәррәү кайтты җырлы кошлар да.
Кояш, таҗын киеп, ясин чыкты,
Карышып маташучы кышларга.

И күкрәде күкләр! Көлде яшен!
Бар табигать
Яшел ялкын булып дөрләде.
Сүндең, әти... Язлар белән сиңа
Үлем килде, яшәү килмәде.

Иртә куйдың фани бу дөньяны,
Сугыш яралары
Тиз китерде гомер азагың.
Үзең белән бергә алып киттең
Безгә дигән тормыш газабын...

Нигә мәдхия юк әтиләргә,
Хаклы җырланганда аналар?
Алар да бит күңел түрләрендә
Мәңгелек ут сыман яналар...

Җәйләр, әти, ул чак сырхавыңа
Дәва алып килде... Инде соң...
Килгән саен, җәйләр күзенә карыйм,
Ә аларда күпме сагыш, моң.

## ЯШӘҮ ҺӘМ ҮЗГӘРТҮ

Каурый болыт куып йөри җилләр,
Җилләр бит ул мәңге пырдымсыз.
Тормыш шавын тыңлап атлап киләм,
Яшәү матур, ләкин тынгысыз.

Анда әнә язлар шау чәчәктә,
Язлар күкрәгендә җыр тулы.
Күпләр йөрәгенең җыры таза,
Шактыенда — җырның «ертыгы».

Яшәү матур! Ә без кирегә үзгәрәбез...
Яман якка нәрсә үзгәртә?
Кемдер шатлык-бәхет көткән мәлдә,
Кемдер аңа кайгы күтәртә.

Үзгәрәбез яхшы, яманга да...
Үзгәртәме заман базары?
Намуслылар илнең йөген сөйри,
Азып ята әле азары.

Күбесендә — шәфкать, ярдәм хисе,
Күбесенең күңеле тутыккан.
Якты өметләрне шиккә салып,
Аҗаганнар уйный офыкта...

Ә шулай да яшәү нинди матур,
Кояш көлә анда, җир көлә!
...Һәм бар хилафлыкны себерә-түгә,
Яшәү кыры буйлап Ил килә.

## ЧОРЛАР АЛЫШЫНГАНДА

Җирдә ыгы-зыгы, шау-шу бара —
Яңа чорга күчү заманы.
Һәр яңа чор үзенә искене дә
Ала, тудырганда яңаны.

Узган меңьеллыкның күкрәгенә
Кылыч тотып басса кешелек,
Монысына әнә керен бара,
Ракеталарына төренеп.

Һәрбер чорның була үз мәсләге,
Үзенең рухы, әхлак, әдәбе.
Кайчак кеше үзе аңлый алмый
Чор әхлаксызлыгы сәбәбен.

...Ни булмасын, һәр чор — яңалык ул!
Дәверләрне алып эченә,
Иркен адымында таяна да
Кешеләрнең тиңсез көченә

Алгарышка таба атлап бара,
Вакыт белән ярышып бу җирдә.
Гамәлләре ошый, ошамыймы,
Аны туктаталмый беркем дә.

Һәрбер чорның була үз тавышы,
Һәрбер чорның була үз моңы.
Һәрбер чорның армас йөрәгеннән
Алгы көнгә яңгырый үз җыры,
Җырлый аны гавам, ил кыры...

...Син дә,
Нинди генә язмыш кичерсәң дә,
Киләчәктә яшә, и җырым!

## АШЫК, ПӘЙГАМБӘР!

Сезне коткарырга төшәрмен дип,
Күккә ашкансың син, и Гайсә!
Җирдә коткарырлык нәрсәләр күп,
Төшсәң, тизрәк төш син, алайса.

Әнә миллион еллар йоклап яткан
Боз таулары эри башлады.
Чөнки кеше сулар һавасына
Тонналап газ, сөрем ташлады.

Шуңа җылылык арта. Яшәешне
Океан ташып басар беркөнне.
Хәзер Нух пәйгамбәр кебекләр юк,
Беркем алып калмас беркемне.

Йә булмаса Кояш өтеп ташлар,
Озон катлавы да тишелә.
Адәм балалары шундый азды,
Үзенең күген үзе җимерә.

Әйдә, төш тә Хода бәндәсенең
Йөрәгенә салчы миһербан.
Җир бит гомере буе югалтуда,
Нигә тагын сансыз күп корбан?
Син аларны чистарт, тазарт әле,
Акылына килсен бозыклар.

## ӨЙРӘТТЕЛӘР

Гөнаһларым гәрчә булмаса да,
Кемнәрдер арттан күзәттеләр.
Дөрес сүз бит, әйт, дип типте йөрәк —
Хак сүз сөйләмәскә өйрәттеләр.

Тәңре миңа моңлы күңел биргән,
Моңнар җанда җырлар дөрләттеләр.
Ул җырларда халык зары иде —
Мине җырламаска өйрәттеләр.

Тормыш юлы шома баскыч төсле,
Ул баскычтан йөкләр күтәрттеләр.
Тәгәрәп лә елар чаклар булды,—
Мине еламаска өйрәттеләр...

Күтәрелде ташып яңа заман,
Заманга да иркенлекләр кирәк!
Аның мәйданында хак сүз сөйләп,
Иске кысаларны җимерә йөрәк.

## Ә ЯУ НИГӘ?

Авылдашларым Миңзифа һәм Гөлниса апаларның бердәнбер энеләре сугыш кырыннан кайтмады.

Ил чакыргач, киткән чакта алар
Ябып чыгып киткән капканы.
Начар йола...
Китәр кошлар ничәнче кат кайтты,
Уллар гына борылып кайтмады.

Утлы кылыч белән җыелган ил
Гомер бакый тынлык тапмады.
Йолаларга хәтта ышанырсың,
Сирәк булгач яудан кайтканы.

Илдә хокук дигән тиңсез кыйммәт
Бик еш чишелә корал аркылы.
Өстенлекне рухта яуларлар да,
Читтә кала сабак, акылы...

Тау илендә таулар йөзе кызыл,
Кызарткан мы уллар ал каны?..
Ә аналар һаман көтә әле,
Каерып ачкан ябык капканы.

## И ЗӨҺРӘ КЫЗ

Легендалар гомере яшәсәң дә,
Айда син ятимгә
Кыен түгелдер ул, Зөһрә кыз.
Сине җылытып, галәм киңлегеннән
Көлә сиңа миллион ак йолдыз.

Җирдә генә хәзер ишләреңә
Җылы да юк, кайнар куллар да.
Канатлары каерылган коштай
Сибелгәннәр кышкы урамга.

Алар матур иртәгегә мохтаҗ,
Күбесе яшәү өчен тартыша.
Ә заманның күкрәгенә басып,
Намус белән хәмер алыша.

Сәрхуш әниләре шушы ятимнәрнең
Җәһәннәмгә таба барышы.
Тик ил моңа гамьсез... Бер төшәр бит,
Өтеп алыр бала каргышы...

Айда хәсрәтсез син, и Зөһрә кыз,
Җаның җылыта миллион йолдызлар.
Җирдә менә михнәт буранында
Гомер сорый нәни язмышлар.

## СОЛТАНЛЫ МӘКТӘП

Кайда юнәлсәм дә, минем өчен
Кадерлерәк төбәк юк ла ул.
Мин онытмам Солтан мәктәбенең
Яшьлек эзем калган сукмагын.

Шушы сукмак алып чыкты безне
Олы юлга, еллар чатына.
Хатлар язган идем яшьлегемә,
Барып җитмәс ләкин хат кына...

Биләп ала кинәт хатирәләр:
Киң урамнар безгә тар иде.
Солтан кызларына, егетләнеп,
Күзне кыскан чаклар бар иде.

Чал төшсә дә сурелмәде ул дәрт,
Йөрәк һаман шул ук — яшь, кайнар.
Читләрдә дә олтан булмадык без,
Олтан буламыни Солтаннар?!

Олтан булмадык без, солтан булдык,
Шома булдык, нәсел — чуртаннан.
Рәнҗеткәннәр, гафу итсәгезче,
Бар булганны кабул итсәгезче,
Мин сезнеке инде, Солтаннар!

## УЙЛАР — ГАЗИЗ ТУФРАКТА

Салам түбәбезнең кыегында
Җәелеп ятып уйный шаян җил...
Ах, төш икән. Сагындырып шулай
Төшкә керәсең син, туган җир!

Сагынасын бит белеп китәбез дә
(Кем сагынмый туган җиркәен!),
Кайтыр идең, сине билләреңнән
Кысып алган туган илкәең.

Аның кырык төрле мәшәкате
Синең мәшәкатькә әйләнгән.
Бетмәс кайгыларын күтәрүдә
Баш-аягың белән бәйләнгән.

Ә иленә беркайчан да җитми
Тазалыгың, көчең, гомерең.
Ул дип җан атканда уйламыйсың
Шул гомернең күзе килерен.

Сары яфраклардай коела да
Артта кала алтын елларың.
Аннан, каударланып, туып үскән
Якта йөри татлы уйларың.

Кайтасың да, ә син онытылган
Бер баласы туган җир өчен...
Юк,
Газиз туфрагында яшәп кенә
Тырыш икән туган ил өчен.

## ИРЛӘР ЙӨРӘГЕ

Ирләр йөрәген таш, диләр,
Ташның да күп гасыр ятканы.
Утларда калды ул — янмады,
Суыкта калды ул — сынмады,
Сынмады, бары тик чатнады.
Заманны күтәргән җилкәләр
Әйтемнең хаклыгынаклады.
Корычтан коелган мәрмәрдәй
Бастырсаң юлларның чатына,
Чын ирләр йөрәге эрер күк
Бары тик мәхәббәт хакына,
Бары тик сабыйлар хакына.

## УТЛЫ МИЗГЕЛЛӘРДӘ

(Мөхәммәт Мәһдиевне уйлаганда)

Кемнәр генә килми бу дөньяга,
Кемнәр генә китеп бармыйдыр.
Киткәннәрне йә дөньясы алдый,
Йә аларны үлем алдыйдыр.

Аждаһадай йота гына тора
Дусларымны шомлы зиратлар.
Үз кадерен белмәүчеләр кала,
Кадерлеләр сүнә, чиратлап.

Чәчәк күзләрендә көмеш чыклар,
Бәлки, чыклар алар яшедер;
Үлемнең дә берәр сере бардыр —
Бәлки, үлгәч кеше яшидер?

Галәм гел мәңгелек булган кебек,
Бәлки, мәңгелектер кеше дә...
Шуңадыр ул Күкләр киткәннәрне
Оныттырмый — искә төшерә.

## ИСӘП-ХИСАП

Күкнең чите кинәт яктырды да,
Балкып ала төннең карасы.
Балкыш гүя мине үзенә чакыра,
Узылдымы әллә
Яшәү белән китү арасы?

Әй, сез, компроматчы, гайбәтчеләр,
Ник туктады сезнең тегермән?
Кергә кушып, күпме тарттырдыгыз
Бер гөнаһсыз, хаклы җиремнән.

Сез дә артык игелек итүемнән
Үзенә такыр сукмак салганнар!
Ник тындыгыз әле? Язмыш кырыма
Чәчтегез бит күпме ялганнар.

Китүем бар... Соңга каласыз ич,
Өстән, юынтык су сибәргә.
Ничек итеп тамак туйдырырсыз? —
Юк бит сездә башка һөнәр дә.

Бер мин генә түгел, күпләренә
Яудырдыгыз пычрак яңгыры.
Намуслының бәхете, уңышына
Йөзләрегез һәрчак кайгылы...

Сөенмәгез, сүнә икән бу, диип,
Юыла, диеп, кылган гөнаһлар.
Төнге балкыш гомер өстәп китте,
Алда сезгә исәп-хисап бар.

## ЯШӘҮ

Зәңгәр күктә, җәелеп, кояш көлә,
Җәй кочагы гүя ял йорты.
Кешеләргә гомер өстәү өчен,
Сихәтле бал җыя бал корты.

Урманнарда — кошлар симфониясе,
Кырда тургай нәсел ишәйтә.
Ак күгәрчен уйный һаваларда,
Яшәү өчен канат көчәйтә.

Океан-диңгезләрдә яшәү кайный,
Яшәү уты тауда, кыяда.
Һәр җан ак кояшка кулын сузган
Шушы җирдә һәрбер ояда...

Бар да яшәргә дип омтылганда,
Тудырганда аның чарасын,
Утлы корал, ракеталар төяп,
Ә син, Кешем, кая барасың?!

## ЯХШЫ-ЯМАНЫ

Ике затны беркөн җирләделәр,
Ни эшлисең, Хода зекере[1]...
Мондый чакта кешенең әрвахларга
Һәрвакытта уңай фикере.

Начар ягын һич тә искә алмас,
Әйбәт иде, дияр «эт»не дә.
Исеменнән тапны юу түгел,
Өреп төшерер хәтта төкне дә.

Тик табигать кенә алдый алмый,
Чөнки киткән аның баласы.
Сүнгәннәргә хаклы бәя бирер,
Аерыр яхшы-яман арасын.

[1] *Зекер — биредә:* Хода сүзе, әмер.

Беренчесе кешелекле иде,
Каберендә чәчәк-гөл үскән.
Икенчесе — вәхши, кыргый бер җан,
Кабере өемендә чүп-үлән.

## АП-АК, ДИЛӘР

Маңгай бөдрәләрең бәсләнгәннәр,
Кара иде, диләр, күптәнме?
Җыерчыксыз йөзгә салынганда,
Ак бөртекләр сөйли үткәнне.

Күптәнме әле? Тальян гармуннарда
Моңга салып сихри күңелне,
Соңгы җырлар утлы давылларда
Күз яшьләре белән күмелде.

Ул бөртекләр биргән вәгъдәләргә
Тугрылыклы булып агарган.
Ил кичергән еллар авырлыгы
Саклап калды мине яманнан.

Ул ак чәчләр — халкым өметләре,
Акландылар барсы азактан.
Аклансам да, һаман агаралар,
Шул көннәрне уйлап, газаптан.

Язмыш, никтер, сөеп иркәләми,
Безнең яшьтәшләрне гел какты.
Ап-ак чәчтән күргәч, авыл халкым
Аягүрә торып кул чапты...
(Мин сәхнәдә идем ул чакны.)

## ХАК СҮЗЛӘРГӘ КАРГЫШ ТӨШӘМЕНИ

Турысын әйттем — дуска ярамадым,
Баш имәдем — аңа суктылар.
Азмы әле илнең җилкәсендә
Хуҗа булып алган «сыткылар».

Бер денсезе, ялган вәгазь сөйләп,
Кеше ризыгын хәрәм ашады.
Намусына төртеп күрсәткәнгә,
Җир-Күкләре белән каргады:

— Җәннәт ишеге сиңа ябык булсын,
Тәмугына дөмек син,— диде.
Мондый әрәмтамак күтәралмый
Вөҗдан, дөреслектә бернине.

Мин болай да якты бу җиһанның
Тәмугларын шактый татыган.
Хак сүзләрне догам иткән өчен,
Ахирәттә кабат татымам.

## ТАРТЫЛУ

Тартылалар күкнең җисемнәре —
Галәм төзек, галәм түгәрәк.
Шушы төзеклекнең чылбырында
Түгәрәк җир йөри, тәгәрәп.

Ул да үзенә тарта балаларын,
Сибеп-коеп очмый Җир-ана.
Галәмнең бу физик тарту көчен
Мин үземчә тоям дөньяда:

Тарта мине бөтен матурлыклар,
Кече күңеллелек, игелек...
Игелек итү күбрәк булган саен,
Шәфкатьлерәк була кешелек.

Тарта язда ал чәчәкләр шавы,
Ләйсән яңгыр, күкләр күкрәве.
Сары диңгез төсле тук башаклар
Үскән басу-кырлар күкрәге.

Тартып тора саф йөрәкле җаннар,
Мәрхәмәтле, изге хисләләр.
Соңгы бәхетен кешегә өләшүче
Чын иманның үзе төсләләр...

Тартылалар күкнең җисемнәре —
Галәм төзек, галәм түгәрәк.
Кешеләр дә шулай тартылсыннар
Һәм бер-берсенә
Өйсен иде шатлык күбәләп!

## КЕМ БЕЛӘ...

Габдерәхим абзый колхозыннан
Соңгы атны алып кыйбатка,
Болыт сыман ялларыннан сыйпап,
Сүзен сөйләп тора шул атка:

— И чаптарлар, — ди ул,— очар канат,
Сез идегез илнең терәге.
Көрәш, хезмәттә дә сезнең белән
Бергә типте егет йөрәге.

Дәвер очкычларга атланды да
Чыгып китте галәм катына.
Абруегыз пыран-заран килде,
Кадер бетте тормыш атына.

Килер беркөн: бетәр нефть-газы,
Булмас бензин — туктар машина.
Шунда тагын илнең шактый йөге
Төшәр синдәй атлар башына.

Сез, дөньяга көтү-көтү кайтып,
Йөрерсез лә иркен кыр тулып,
Гүя гасырларның карынынннан
Чыккан яңа матур җыр булып...

...Еллар берсен берсе этә-төртә
Киләчәккә таба йөгерә.
Габдерәхим абзый сүзен уйлыйм,
Бәлки, ул хаклыдыр, кем белә?

## «ЙОСЫФ КЫЙССАСЫ»

Балачакта каян беләсең, ди,
Олылар бит берни әйтмәде.
Әти яшереп укыды, килгән кешеләр
Аны дога итеп ятлады.

Мич башыннан тыңлап яткан көйгә
Минем дә ул сеңде күңелгә.
Айлы кичтә гүя пәйгамбәрләр
Сулышын тойдым өйнең түрендә.

Балигъ булып, гыйлем эстәгәндә
Белдем аның
Бер әдәби әсәр икәнен.
Ләкин инде якты нуры белән
Күмелеп калган иде үткәнем.

«Тышкы дөнья», аны оныт, диде,
Эчке дөньям кушты киресен.
Бүген дә әле тиңсез яктысыннан
Йөрәккә көч өстәп йөрешем.

Гасырларның күкрәгеннән килеп,
Үтеп кара еллар аркылы.
Колгалинең «Йосыф-Зөләйха»сы
Сөю, иман булып балкыды.

## ҮТКӘННӘР

Үткәнебез, матур әкият кебек,
Үзенә дәшә сыман, чакыра.
Уй йомгагы сүтелеп китеп бара
Узгандагы хыял чатына.

Ах ул хыял! Ак канатлы хыял!
Алар өчен һич юк киртәләр.
Алар белән юллар җиңеләя,
Алсу туа төссез иртәләр.

Үткәннәрдә — яшьлек! Хисләр туе
Давыллана күңел ярында.
Күңел сыйдыра бөтен авырлыкны,
Кара ягын, агын — барын да.

Анда карурманнар! Төпләрендә
Сүнмәгән күк минем учак та.
Яшь кызларның янар йөрәкләре
Бәргәләнә кайнар кочакта.

Анда тормыш! Томырылып тарта
Илнең йөген гаярь пар атлар.
Чабаталы социализм җырын
Җырлый юкә, мәгърур наратлар...

Ялкыннарга төренеп, еллар елый,
Ватан күген баскан күз яше.
Аяк-кулсыз кайтып ауганнарның
Ярасына тама ил яше...

Әнә яшьлек хыяллары инде
Киң галәмгә чыккан, атылып.
Ай каршылый кыю йөрәкләрне,
Җирнең таганында атынып.

Алар әле ерак планеталар
Күкрәгенә барып җитәчәк.
Үткәннәрсез булмый бүгенгесе,
Бүгенгесез булмый киләчәк.

## ХАТИРӘ ЙОМГАГЫННАН

(Авылым Яншыкта булган хәл)

Әкиятләрдән чыккан малай кебек,
Шундый тере, бик җор идең син.
Арабызда дуслык җылылыгын
Бөркеп торган бер җыр идең син.

Төнлә белән тайлар көткән чакта
Уртак бер җан идең төркемдә.
Синдәй оста учак яга белгән
Авылда юк иде беркем дә.

Учак ялкыннарың, төнне ерып,
Күккә ашты,
Йөрәк ялкыннарың шикелле.
Киләчәктә колхоз кырларында
Иген игү иде уйларың...

Ах, нигә дип кердең борчак җиренә,
Ник кызыктың дүрт-биш кузакка?
Ә Ватанга «халык дошманы»ның
Саны кирәк иде ул чакта.

Бөтерде дә алды кара язмыш,
Вакыт йотты синең исемне.
Әллә фәрештәләр канат җәйде —
Еллар үткәч күрдем үзеңне.

Малай чагың гадәтләре калган,
Һаман тере, һаман җор идең.
Ә чәчеңә ак болытлар кунган,
Һәм бөтенләй башка җыр идең.

Һәрнәрсәгә ниндидер бер шикле,
Үтә кырыс иде карашың.
Аңлыйм, шулай була кеше үтсә
Җәһәннәм һәм яшәү арасын.

Сыкрады да күңел бер кычкырды,
Оран салып, бөтен көченә:
— Мондый вәхшилекне, газиз илем,
Башка китермә син кешегә!

## ГОМЕР БАКЫЙ БҮЛЕШ

Кешеләргә нигә салынмаган
Иң дә гадел сорау: «Кемнеке?»
Яшәешнең кайнар башыннан ук
Җирдә нәрсә күрсә яулаган да
Кычкырган ул һәрчак: «Минеке!»

Яңа таулар, диңгез-океаннар
Ачып йөргән гаярь кешеләр,
Аңа сугып куйган үз мөһерен,
Гүя алар Хода ишеләр.

Шулай килгән...
Менә башларына һич килмәгән:
«Бу соң каян? Була кемнеке?»
Диңгез-океаннарда җил улаган:
«Кешеләр! Бу була Җирнеке,
Түгел синеке йә минеке!

Бүлешмәгез!
Ул барыгызга тигез бирелгән.
Аның өчен ызгыш-сугыш гөнаһ,
Күктән шундый әмер иңелгән!»
Юк, кешелек башка юлдан киткән,
Җирнең һәр почмагын бүлешкән.
Моны хәтта тыныч хәл итмәгән,
Күпме җаннар кыеп сугышкан.

Иң аяныч, —
Гомер бакый шушы талаш-бүлеш
Сеңеп калган безнең тормышка...
Ә бит дөнья, тормыш нинди матур,
Бигрәк матур... карап торышка.

## ТАТАР ХОЛКЫ

Кая барсам, татар хакын хаклыйм,
Алай итәм, болай иттерәм.
Аның шанлы халык булганына
Меңәрләгән дәлил китерәм.

Бар да ышаналар! Тик бер ягын
Хуплап бетермиләр берсе дә:
Гаярьлектә, көчтә тиң булса да,
Ник җайлаша икән көчлегә?

Тарихтагы эзен дәвам итеп
Ыргыла да яңа адымга,
Аннан, хәлсезләнгән юлбарыстай,
Кушылып китә гомум агымга.

Рәсәй йөзе нинди «төскә» керсә,
Татар ала шуның барысын.
Аның хаталары-ялгышына
Буяп куя үзенең язмышын.

Тәңре аңа Акыл, Зирәклекне
Поты-поты белән бирсә дә,
Узган чордан калган күндәмлеге
Баса-баса килә үкчәгә...

Тагын, бәлки, «төсен» үзгәртер ил,
Булыр, бәлки, көрәш, давыл да.
Нинди хәлләрдә дә үз йөзеңне,
Нинди агымда да үз кыйблаңны
Кирәктер ул саклап калырга.

## КОРБАН

(Репрессиянең яшь корбаннары ядкаре)

Еллар! Ник сез шулай мәрхәмәтсез,
Искә төшерәсез миңа Аны.
Әллә оныткан дип уйлыйсызмы?
Сызлатасыз сызлап торган җанны.

Вакыт! Син дә усал булма алай,
Хәтерләтмә һаман. Яна күкрәгемдә!
Ышанмасаң, менә ачып кара:
Ул бит балачактан йөрәгемдә!..

Илдә афәт йөргән еллар иде,
(Дәһрилеге өчен каргагандыр Ходай.)
Бүгенге ил! Ишетәсеңме мине? —
Бер уч башак өчен ул чак, үксеп,
Себер китте ундүрт яшьлек малай.

Ул кайтмады...
Заман! Сук барабан, шаулат литавралар!
Яңгырасын бөтен якка набат!
Тавышы китсен киләр дәверләргә,
Бу кыргыйлык булмасын, дип, кабат.

## ЯЛГЫЗ АККОШ КАЙДА ОЧА?

Туган җиргә язлар килгән,
Сиреньнәр чәчәк аткан.
Ялгыз аккош кына оча
Без юлга чыккан яктан.
(Кемне эзлисең, якташ?)

Әйләнә күлләр өстеннән,
Яшьме, яңгырмы тама?
Сагышка, моңга кушылып,
Сулар ага да ага...
Каеннар яфрак яра.

Таң кырында кыр казлары,
Парлашып, канат кага.
Ялгыз аккош, күкне иңләп,
Кемнәргә аваз сала?
Яшь-яңгыр һаман тама.

Әйтегезче, наныйларым:
— Сез очып кайткан җирдән,
Без барасы юл ерак,— дип,
«Тәскирә» көенә җырлап
Үтмәделәрме ирләр?

Йөрәк янды, канат талды,
Җавап ала алмады.
Тик үзара серләштеләр
Сихри күлнең таллары.

## САГЫШ

Ах, бу сагыш!..
Туганнарым, дуслар иртә китте,
Якын зыялылар тормыштан.
Чәчәкле җәй тулы күңелемә
Сары көзләр килде сагыштан.

Беренче яр дәшә офыклардан —
Кулын изи кояш баештан.
Гомерем буе бардым, җиталмадым, —
Йөрәк гүя үзе сагыштан.

Бу җанымда шаулый туган якның
Юкәләре, җырлы камышлар.
Беркайчан да җирдә юк һәм булмас
Мине биләгән ул сагышлар.

...Чир ул чиргә йокмый дию хактыр,
Мин сынадым аны язмышта.
Һәм миңа да хәзер сагыш йокмый,
Чөнки үзем тоташ сагыштан.

## ХАКЛЫ ШИК

Бер шагыйрьгә[1] җырланылды:
Сүнгәч тә, син мәңге яшәрсең.
Ак мәрмәрдән сиңа сын куелыр,
Шуннан торып, безгә дәшәрсең.

Хезмәтләрең илне зурладылар,
Алар аны данлы итәрләр!!!
Шагыйрь кулын күккә суздьі:
«Тәңрем, бирче миңа озын гомер,
Белеп китим,
Үлгәнемне кемнәр көтәрләр».

[1] *Шагыйрь* — Мансур Шиһапов үзе.

## ҮЗЕНӘ ДӘ ТӨШТЕ

(Хатирә)

Ярлы иде, кигән чалбары да,
Ышанмассың,— кырык ямаулы.
Бары бу тормышка зур мәхәббәт
Яшәткәндер зирәк малайны.

Авыл халкы әйтә торган иде:
«Башлы үзе, әйбәт укучы,
Киләчәктә яңа фикерләрдән
Булыр шәп ачышлар тукучы...»

Берчак ачтан үлмәс өчен, кырда
Кулын сузган бер уч киндергә.
Актив Газиз моны күреп алып
Озаттырды ерак Себергә.

Ул чактагы вәхши кануннарга
Кече-зуры һич юк язмышның.
Барысы да бер казанда сүнде,
Ямен күрә алмый тормышның.

Ул кайтмады...
Еллар аша актив Газизне дә
Каһәрләре
Тотып алды бугай малайның:
Бер сәбәпсез кереп асылынды
Мунчасына Билал бабайның...

Ә ул көнне... күкләр каралды,
Яшен күкрәде дә, болыт таралды...

## ХӘЗЕРГЕ ТОЛЛАР

Гомер бакый хатын-кызның хисен
Зурлый торган зәңгәр төннәр бар.
Хәзерге буында хыянәттән
Тол калганны аңлар кемнәр бар?!

Урамнарда балкый яшь-яшь толлар,
Житәкләгән йөрәк парәсен.
Берсе — гөнаһлы жан, ә парәсе
Соңрак аңлар гөнаһ ярасын.

Ах, исемә төшеп, бәгырь телә
Сугыш елларының толлары.
Һәм аларның
Сагыну тулы юксынулы жырын
Халык иле белән жырлады...

Каеннарга асылып, жилләр елый,
Кемнәргәдер сыкрап эндәшә.
Яшь-яшь толлар аны ишетмиләр —
Акылы белән нәфесе көрәшә.

## УЙЛАНУ

Кул таягы башы
бүрек кигән:
Аякларны сагынып
сыкрый идән.
Жир-ананың газаплары
кими төсле,
Тол аналар зары, белмим,
бетәр микән?

## КҮКРӘҮЛӘР

Нинди күкрәү соң бу? Яңгыр көтсәң,
Яумас иде әле кирәктә.
Юк, бу ниндидер бер сәер күкрәү —
Әллә күктә, әллә күкрәктә.

Күкрәүләрне бик күп кичердек шул,
Аңламассың, кайсы күкләрдән?
Ил белән дә, ялгыз гына да бит
Без аларны азмы күтәргән.

Ватан киңлегендә һич тынмады
Афәтләрнең төрле-төрлесе.
Күпме уллар калды күкрәүләрдә,
Чираттадыр әле күпмесе...

О, бу күкрәү яңгыр алып килде,
Бәрәкәтле булсын яңгыры.
Җиңел сулыш алсын тетрәүләрдән
Яраланып калган ил кыры.

## БУРАННАР

Эх, бураны белән кышлар килде,
Андый кышны көтеп алам мин.
Буран улавында бу җаныма
Тынгылыклар, ләззәт табам мин.

Бураннарда — шомнар, димәсеннәр,
Киресенчә,
Алар моңлы, алар җырлылар!
Анда хәтта кура, камышлар да
Гүя яшәү җыры җырлыйлар.

Урам, кырда буран симфониясе!
Урман шавы моңын күтәрә...
Тормыш көчсезләрне, көч җыйсынга,
Үз бураны аша үткәрә.

Язда буран китә, эзе кала:
Күкри яшел уҗым, мул уңыш.
Шуның белән яна Яшәешнең
Йөрәгендә алга омтылыш.

Күпләр бураннарны каһәрлиләр,
Лаек микән алар каһәргә?
Нинди бураннар бит...
Ут бураны гомер кисеп йөри,
Кышкы буран чакыра яшәргә!

## КҮКЛӘР АЛДАМАДЫ

Ни өчендер, күкләр хупламады
Яшьлектәге ашкын хыялны.
Ә хыялда
Тиңсез матурлыклар, бәхет эзләп
Үтү иде озын юлларны.

Чакырып торды Урал биеклеге,
Ангараның ярсу шаулары.
Ләкин мине тартты Кама-елга,
Балачакның Бәтке таулары.

Хыялымда үзенә кул изәде
Төрки дала, Татар бугазы.
Әмма юлым гүзәл Иделемнең
Ярларыннан ерак узмады.

Күкләр гүя миңа бәйләп куйды
Кендек каным тамган җиремне.
Ах, туган як!
Синең киңлегеңнән бу дөньяның
Бөтен матурлыгы күренде.

Юк, күкләрем мине алдамады,
Үскән туфрак булган тәхетем.
Ят тарафта таба алмас идем,
Туган җирдә таптым бәхетем.

## АХУН БАБАЙ

(Зиратта каберен күргәч)

Кешелекле, игелекле иде
Хода биргән озын гомерең.
Халкыбызның күркәм сыйфатларын
Җыйган иде изге күңелең.

Бөтен авыл сиңа килә иде,
Тишек чиләк, чәйнек күтәреп.
Шундый оста яман бирә идең,
Утлы кургаш белән үткәреп.

Ярма яргычны да син ясадың,
Үзе җиңел иде, ипле ул.
Бәйрәмнәрдә ярма ярдырганда,
Бар авылга хезмәт итте ул.

Ә гөсләңме! Уңган бармакларның
Көйле-көйле җыйды кылларын.
Милли җырдан торган зур сәнгатьне
Җанга салды аның моңнары.

Үзең җыйган гармун моңнары да
Иң дәһшәтле утлы елларда
Йорт-курадан кайгыларны куды,
Өмет бирел килер елларга.

Безнең халкыбыз бит алтын куллы,
Талантлы шәхесләр күп алар.
Ләкин кирәк халык һөнәрләрен
Яшәтүче синдәй осталар.

...Син — мәңгелек йортта... Баш очында —
Бөдрә каеннарның шаулары.
Ә урамда гүя сине эзли
Гөсләң, гармуныңның моңнары.

## ТОРМЫШ БУСАГАСЫНДА

Ул ел язлар иртә, дәррәү килде,
Бозлар сукалады ярларны.
Кояш күктән сузылып ялап йөрде
Анда-монда калган карларны.

Биштәреңне асып карап тордың,
Җәелеп, ургып ага, дип, инеш...
Китеп бардың. Арттан сөйләделәр:
«Бер кайтырмын дигән, ди, имеш».

Ни эшлисең, тормыш кыенлыгы
Бик күпләрне
Туган җирләреннән аера.
Аеруын аера, көчсез булсаң,
Канатны да бик тиз каера.

Вакыт киереп үзенең ак җилкәнен
Ага торды алгы елларга.
Казан урамында очраштык без,
Син тормышны
Бик өлгергән идең сынарга.

«Авылдашым, диден, бу дөньяда
Язмыш мине каты талкыды.
Бәхетне дә юньләп табалмадым,
Китеп рәнҗеткәнгә халкымны».

## КЕШЕ ЯШИ СҮНГӘЧ ТӘ

Сүнгәннәр яшәми, диләр,
Сүнгәч тә яши кеше.
Аны үлемсез итә бит
Калдырып киткән эше.

Ул — үзе утырткан агач,
Урманнар булып үсә.
Тирен түккән бакчаларда
Җимешләр булып пешә.

Чишмәләр булып ага ул,
Китkәнгә юлын ачып.
Яңа төзелгән калалар
Булып тора ул басып.

Алмашларның һәр эшендә
Зур тормыш төсле яна.
Менә җыен әшәкедән
Тик тузан гына кала.

Галимнәр — ачышларында,
Шагыйрьләр — поэмада,
Язучылар романнарда
Гомер сөрә дөньяда...

Мин дә җырларым калдырам,
Беләм, бер сүнәчәкмен...
Үлгәндә дә үлмәсемә
Ышанып китәчәкмен.

## НИК?

Кинәт кенә күңелсезлек килә,
Кайчак югалта ул чамасын.
Кайгылары үзе эзләп таба,
Ә бәхетне эзләп табасы.

Яшькә күмеп якын кешең китә
Өрлек кебек таза чагында.
Барыр юлын яхшы белгәннәр дә
Кайвакытта юлын югалта.

Әмма кеше яңалыкка бара,
Аны тудыру өчен җан ата.
Күпсенмәче, Тәңрем, кеше гомерен,
Корып куйма аңа каршылык...
Син яраткан Җирдә ул булмаса,
Ник Кояшың кирәк, Яктылык?!

## УЙЛАП ТОРСАҢ

Тарих түрләреннән килә-килә
Бүгенгегә җитеп,
Чал Карт тора Идел ярында.
Йә күкләрдән нидер ялвара ул,
Йә үксүе ургый җанында.

Күкләрдән соң шулай нәрсә сорый,
Узган хаталарын йоламы?
Үксү белән генә инандырып
Булмыйдыр ул Бөек Ходаны.

Ялгышлары җитди: Илһам ханы
Ак кенәзбикәне яр итте.
Милли хисле, денле хан Сараен
Иман, изгелеккә тар итте.

Көрәшләрдә билен бирмәсә дә,
Сынмаса да булат кылычы,
Булгәләде, таркаулады аны
Эчке талашларның сулышы.

Туган җире өчен баш салырлык
Алыпларын читкә тибәрде.
Иле өчен янган ханбикәсен
Ят кавемгә биреп җибәрде.

Ханбикәсе белән бергә китте
Бәйсезлеге, абруй-шөһрәте...
Һәм хәзер дә иске хаталардан
Хали түгел татар милләте.

## КАПМА-КАРШЫ

Тиледер мин. Игелек итү өчен
Талпынды да торды бу күңел.
Әмма арт ягын да күрсәтте ул —
Игелек кылу җиңел эш түгел.

Малай чакта күрше Габделхәй дус,
Каты авырып,
Алма теләп яткан бер көндә,
Ахун картның бакчасына кереп,
Алма чәлеп бирдем ак төндә.

Мин иқәнен белеп, Ахун бабай
Күлмәк якасыннан алды да,
Кәҗә бәтиедәй сөйрәп килеп,
Зәһәр кычыткангa салды да.

Балигъ булдым... Казан. Трамвайда
Карак кисте кеше кесәсен.
Кулын тоттым. Шуның өчен кинәт
Хәнҗәр ярды кәчтүм җиңсәсен...

Бу кылганнар, бәлки, вак-төяктер,
Нигездә бит алар игелек!
Тормыш өчен шундый вак-төякләр
Әзерләде мине иң элек.

Ә тормыш ул — чуар. Кемсәләр күп.
Шактыйлары атты таш белән.
Оныттылар алларына күпме
Савыт куйганымны аш белән.

Дөньяга да янар гөлләр чәчтем,
Ә чәчемне сукты кыравы.
Шат җиһанны үлеп яратсам да,
Иңнәремдә һаман сынавы...

Кайчак уйлыйм: әгәр шулай барса,
Этлеккә бит калам күмелеп.
Йөрәк куша:
Игелеккә дөрләт мине, җирдә
Хакыйкатьтән да өстен Игелек!

## УФТАНМАГЫЗ!

Иң яраткан кеше... Шулай язган —
Бер көн сүнә гомер агышы.
Сөйләшәсе килә алар белән,
Их, ишетәсе килә тавышын.

Бер сорыйсы килә: «Ахирәттә
Нинди хәлләр бар соң, кадерлем?
Кай дөньяда күбрәк беләләр соң
Кеше дигән затның кадерен?

Изге китапларда әйтелгәнчә,
Яшәү чынлап бармы анда да?
Сагынасыңмы? Әгәр яшәү булса,
Сагышларсыз булмый кайда да».

Нигә кире кайтып китүләр юк,
Вакытлыча гына булса да?
Чиксез зарыгулар кимер иде,
Нигезендә бер кич кунса да...

Юк кайтулар... Күккә юлласаң да
Бөтен кешелекнең гозерен.
Беркем ача алмас Мәңгелекнең
Мәңге ачылмаган бу серен...

Уфтанмагыз, алда көтә, диеп,
Мәңгелеккә күчү сызыгы.
Әгәр гомер кабатланыр булса,
Калмас иде яшәү кызыгы.

## СЕРЛЕ ӨННӘР

Йолдыз салкын. Әмма минем җаным
Алар яктысыннан җылына.
Йолдызлардан килгән серле өннәр
Күңелемә кереп сыена.

Һәм ачалар миңа үз серләрен:
Матурлыклар килә галәмнән.
Гүзәллекне саклау, аны яклау —
Шул сорала җирдә адәмнән.

Шуннан килә мәрхәмәтлек, вөҗдан,
Миһербанлык, намус, хәләле.
Тик кешеләр генә яшәештә
Бар итәләр төрле хәрәмне.

Кайнар Хисне, илаһ Сөюне дә
Галәм Кодрәтчесе яраткан.
Ә тормышта исә инсани зат
Аны уйнаш итеп тараткан.

Күпме булса җирдә файдалысы,
Бөтенесе — Тәңре җимеше.
Аңа капма-каршы кире якны
Уйлап таба бары ул — Кеше!

## НИЛӘР СӨЙЛИ БУРАН?..

Урамнарда буран котырына,
Бала сыман елый чормада.
Нинди килер хәсрәтләрне сөйли
Мин яраткан матур дөньяга.

Нинди бәлаләрдән кисәтә ул,
Ак киемле Хозыр шикелле?
Без болай да төрле афәтләрне
Бик җитәрлек күрдек бит инде.

Улый буран. Иртәгесе көнгә
Туган ак хыяллар урнына,
Тәрәзәләргә килеп бәрә-бәрә,
Кара шомнар гына тузына.

Ярый да бит милләт балалары
Калмасалар көчле буранда,
Карлар артык киртә кормасалар
Алар бара торган юлларда.

Хәер, каршылыкка күнеккәнбез,—
Бернәрсә дә җиңел бирелми.
Еллар азмы башны кыеп китте,
Ә безнең баш һаман иелми!

## ЯЛГЫШ

Ни дип кенә киттең урманнарга,
Нинди генә уйлар этәрде?
Көтмәгәндә кара аждаһадай
Кара болыт басты күкләрне.

Кырда давыл үкреп дулаганда,
Нигә ташлап чыктың урманны?
Чалтырады яшен. Аның уты
Йөрәгеңә килеп уралды.

Берчак булмагандыр югалтудан
Бәгыремнең болай сызганы.
Минем өчен,
Әйтерсең лә синең белән бергә,
Яшен сукты бөтен дөньяны.

Ничек шулай күкләр ялгыштылар?
Син гөнаһсыз идең! Чиста җан!
Язмыш гөнаһсызга бик еш үчле,
Гөнаһлыга иркен бу җиһан.

## АРТЫК АКЫЛ

Ак болытлар төсле кабарды да,
Канатларын җәеп, ак хыял
Алып чыгып авыл капкасыннан,
Әйдә, диде,
Җирдә артык акыл җыеп кал!

Калды авылдашлар, каеннарым,
Карт карама йодрык төйнәде.
Төйнәде дә йөзен читкә борды,
Ашыгасың, үсмер, димәде.

Үз акылым бик тә таман иде,
Сәләт дигәне дә җиткәндер.
Бәлки, хыял, тормыш иту өчен,
Акыл күбрәк кирәк, дигәндер.

Үтә барды еллар, уздым юллар,
Казан урамнарын таптадым.
Ләкин берчак, дөнья көтү өчен,
Әзер артык акыл тапмадым.

...Һаваларда — тургай. Кырда — хезмәт,
Миңа каршы йөгерә ак каен.
Карт карама ябалдашын җәйгән:
«Артык акыл миндә, дускаем!»

Басуларда — алтын башак шавы,
И юлаучы, туктап дога кыл!
Башак дулкыныннан күтәрелеп
Кулын изәп тора Зур Акыл.

## ЯШЕН

Ялтырады яшен, гүя керер
Утлы аждаһалар төсенә.
Кинәт суга инеш ярларына
Тирес аударучы кешегә.

Болытларны мамык кебек тетә,
Аннан бик аз тынып тора да
Бәрә күккә корым ыргытучы
Юан, биек тимер торбага.

...Кышның уртасында яңгыр коя,
Җәйнең уртасында кар ява.
Адәм табигатьне пычратканга,
Бу күк җәзасыдыр дөньяга.

Кеше агу ата һаваларга,
Агулый ул елга-суларны.
Сулышы кысылганга, яшен әллә
Шуңа күрә аны сугамы?

## БОЛЫТЛАРДА

Манкортлашу дәвам итә.

*Газеталардан*

Җилләр белән теткәләнә болыт,
Алар тынгач, кабат җыела.
Мөлдерәгән кара күзләреннән
Сорау булып яше коела.

Болытларда җаннар бәргәләнә —
Нинди шәҗәрәләр газабы?
Сорау гади: халык чуарлана,
Кайчан булыр моның азагы?

Җир-күк арасында зарлы моңнар,
Ул моңнарда тоташ шом гына.
Болытларда җаннар кайгыртуы,
Җирдә исә
Милләт сүнә бара тын гына.

Салкын җилләр бутый болытларны,
Йомгак очы төсле чуалта.
Чуалтылган, чуарланган татар
Төсен, йөзен, рухын югалта.

## ГАЗИЗ ӘНКӘМ ЙОРТЫНА

Кар сулары җырлар җырлый,
Моң агыла тын гына.
Язгы кичләр, кайнар хисләр
Сабый чак назларын эзләп
Тарта әнкәм йортына,
Газиз әнкәм йортына.

Сиреньнәр ак шәлен япкан,
Күңел кая омтыла?
Яшьлегем эзләрен эзләп
Тарта әнкәм йортына,
Газиз әнкәм йортына.

Гүзәл илем юлларыннан
Поезд алга ыргыла.
Чәчләремә бәсләр төшкәч,
Ялгышканда киңәш сорап
Кайтам әнкәй йортына,
Газиз әнкәм йортына.

Керфегеннән яшь кипмәгән,
Таңнарда уты яна.
Тик әнкәй сагынып көтә,
Барсын әнкәй гафу итә,
Без әнкәйгә гел бала,
Без аңа мәңге бала.

## БАСЫП ТОРАМ ЧАТТА

Балкый җиһан! Менә туган авыл,
Таныш урам, таныш сукмаклар.
Бездән калган җырны җырлый кебек
Шыңгый ярындагы учаклар.

Яшь пәрдәсе каплый керфекләрне,
Диңгез сыман кайный бу күңел.
Каян килгән ят кеше соң, диеп
Карап торасыңмы, и сеңел?

Юк, мин изге Хозыр-Ильяс төсле
Алларыңа күктән төшмәдем.
Син тәгәрәп үскән урамнарда
Мин дә тәгәрәп бит үскәнмен.

Кем нәселе? «Кәҗә Гаязыннан»
Күрәм, аның нурлы карашы...
Ул, авылда калып, бәхет тапты,
Мин бәхетсез — авыл ярасы.

Балкый җиһан! Балкый авыл күге,
Хәтта каз үләне сөйкемле.
Тик мин генә басып торам чатта,
Чит-ят бер юлаучы шикелле.

## БӘХЕТ НИДӘ?

Гомер бакый кеше бәхет эзли,
Тик бәхетне аңлый төрлечә.
Кемдер аны байлыкларда күрә,
Кемдер яшәвендә кешечә.

Мин бәхетле, дияр имансызы —
Каергаты этлек җилкәнен.
Хәтта халыкларны канга батырып,
Кылыч уйнатуда җиңгәне.

Эшчәннәр дә бәхетләрен эзли,
Таба аны тырыш хезмәттә.
Бары үзен генә кайгырткannар
Таба алмый хәтта эшләп тә.

Ул ишелеп килә, кешелекле,
Шәфкатьле гамәлләр кылганда.
Һәрберсенә шуны белү фарыз:
Кешеләрнең бәхете — Иманда!

## КЕМНӘР ШУЛАЙ...

Күкрәп, яшьнәп яңгыр болыты килсә,
Оеп кала бөтен басу-кыр.
Туган якта күкләр күкрәве дә,
Яшен яшьнәве дә үзе җыр.

Туган җир ул китаплардан гына,
Әкиятләрдән генә түгел лә,
Сабый чактан ана сөте белән
Кереп кала һәрбер күңелгә.

Исеңдәме минем бала чагым,
И Урайның йомшак җилләре!
Гомерем салкыннары читтә булса,
Монда калды җылы көннәре.

Шул көннәрдә бераз яшим, диеп
Кайттым менә, зифа талларым!
Ах, кая соң сездә керәшәләр,
Инешемнең текә ярлары?

Кыекларга кунмый карлыгачлар,
Сыерчыклар кайтмый ояга,
Сукаланган хәтфә болыннар да...
...Кемнәр шулай мәрхәмәтсез булган
Малай чагым калган дөньяга?

## АЛДАНМА

Тормыш каршылыклы, ике яклы —
Дөнья аны шулай яраткан.
Әгәр шатлык килсә, туарылма,
Хәсрәтләре килер азактан.

Минем дуслар хыянәтчел түгел,
Алар миңа тугры, димәгез.
Шулар арасыннан бер дошманы
Илтеп терәр ярга көймәгез.

Кемдер төче, купшы сүзләр әйтсә,
Күңелне киң тотып алданма.
Купшы сүздә үз мәнфәгатьләрен
Истә тоткан матур ялган бар.

Хаклык үзе идеаль кебек тә бит,
Ул да арынмаган ялганнан.
Хак сүз сөйләп йөргән бәндәләрдән
Мин тормышта йөз кат алданган.

## БӘХЕТ КЫЙБЛАСЫ

Гомер юлым офыкларга таба,
Ә ул һаман артка чигенде.
Чытырманлы карурманнар үттем,
Аз ертмадым тормыш күгемне.

Текә үрләр, елга-сулар кичтем,
Кыя-таулар басты каршыга.
Кешегә бәхет эзләп барган йөрәк
Шундый бит ул: талмый, ашыга!

Кышкы мәрхәмәтсез бураннарда,
Чалуларда калдым егылып.
Кеше бәхетен урлап йөрүчеләр
Узып китте дәшми, томырылып.

Тарих битләреннән төшкәнмени:
Рәнҗеттеләр татар булганга.
Үз фикерем белән юлга чыгу
Ошамады урыс туганга.

Ә омтылыш офыкларга иде,
Җиңә барып барлык киртәне,
Менә беркөн сөенеп каршыладым
Яңа заман дигән иртәне.

Әле дә офыкларга атлыйм. Бәхет жыям.
Заман кырыс. Җаның күшегә...
Ә күңелдә язлар! Чөнки бәхет
Өләшәм бит бүген кешегә.

## КЕШЕЛЕК СЕРЕ

Таулы юллар кешегә авыр, диеп,
Таулар итәгеннән юл салдым.
Усаллары аны сукалады —
Кешелеге юк бит усалның.

Тормыш тугаена мин утырткан
Алмагачлар үсеп беттәде.
Азмы әле җирдә мәрхәмәтсез —
Барын тамыры белән төпләде.

Канатымны салып болытларга,
Изге эшләр өчен чарладым.
Ак хыялым шундый матур иде,
Анысында...
Кызыл тажлы Ватан алдады.

Ашыр өметләргә ялкын өстәп
Омтылдым гел алга һаман да.
Этлекләре элеккедән битәр,
Килеп керсәм яңа заманга.

Яшерен генә илне талап ята
«Яңа урыс», «Яңа татар»ы.
Бар көченә гөжли, гөрли генә
Намусларны сату базары.

Кешелекклелек, дуслык, туганлыкның
Хисе түгел, хәтта исе юк.
Һәрберсе дә үзе өчен яши,
Ач-ялангачта аның эше юк.

Ә шулай да яшәү нинди матур,
Нинди рәхәт дөнья яктысы!
Ни булмасын, заман кочагында
Начарыннан артык яхшысы.

## ӘҮЛИЯЛАР

Борынгылар мирас киштәсеннән
Килә әүлиялар тавышы:
Чорлар үтеп, ике полюс ачылыр,
Җир күчәре китәр авышып.

Ярларыннан чыгар елга, диңгез,
Сулар басар шактый кыйтганы.
Батмый калыр бары Рәсәй җире,
Ул шаһиты булыр
Яңа яралучы дөньяның.

Җирнең әнә хәзер күп өлешен
Вакыт-вакыт туфан каплыйдыр.
Күчәреме әллә авыша бара,
Әүлиялар, бәлки, хаклыдыр?

Рәхмәт инде сезгә, борынгылар!
Менә
Безнең куркуларны бастыгыз.
Бата-калка тормыш иткән илгә
Алда яшәү өмете ачтыгыз.

Тик бер сорау туа, әүлияләр,
Болай гына... Яхшы нияттән:
Ничек халык зарына баткан Рәсәй
Тәңребезнең
Миһербанлыгына эләккән?

## САБАНТУЙ КӨННӘРЕНДӘ

Арышлар серкә очыра,
Сабантуйлар көне җиткән,
Электән калган гадәт дип,
Егетләр яшьлек дусларын
Урап кайталар кичтән.

Кодалар да килеп төшә
«Волга» дигән ап-ак атта,
Елмаялар, якланалар...
Кыз киткәнгә шатланалар —
Шундый йола безнең якта.

Сөлге җыя яшь-җилкенчәк,
Тальян моңы урам яра.
Килен йөзе
Әйтерсең лә йолдыз яна,
Ә күзләре шомырт кара.

Урамдагы ак каеннар
Юксыналар яшьтәш кызны.
Таң атканчы, зур туй бара,
Яше-карты тәбрик итеп,
Сузып җырлый тәүге җырны.

Пар бармаклар пар балдакны
Кабул итсен җиңел кулдан,
Пар сандугач парлап сайрап,
Гөрләп үтсен язмыш дигән,
Тормыш дигән олы юлдан.

## АК БУРАННАР

Кышкы күктә давыл туй төшерә,
Кардан тунын бөрки урамнар.
Тарих буйлап килгән миллилекне
Җырлап йөри ап-ак бураннар.

Давыл — гадел. Черек түбәләрне
Тарта, йолкый бөтен көченә:
«Хрущёвка»лары сыймый икән
Чал Казанның чып-чын йөзенә.

И яңара кала! Үсеш, алгарышлар
Һәрвакытта кеше иркендә.
Кыя сыман «Пирамида» баскан,
Чүл сулышы Казан өстендә.

Гомер бакый бездә фиргавеннәр
Булганы юк иде югыйсә.
Ят сулышны куып, урманнарда
Ак бураннар булып җил исә.

Безнең рухлы бураннарның җырын
Тыңлап торам басып таң калып.
Яңар, күтәрел син, и Башкала!
Ләкин булсын иде
Милли төсмер тулы яңалык.

## КОЯШКА МИН ЫШАНАМ

(Авылымда мәчеткә йөрер кеше калмаган)

Үткәннәрдә өшеп туңган жанны
Бары халкым гына жылытты,
Чөнки дәһрилекнең черек тамыры
Иман агачларын корытты.

Бүген асылыбызга кайтышыбыз,
Манарадан әнә Ай көлә.
Тик нәрсәдер борчып тынгы бирми,
Күңелемдә шөбһә-шик туа.

Бацилла күк манкорт кавем үрчи,
Үз теленә, диненә төкереп.
Үскән ягыннан да яшьләр китә,
Туган жире кала, каңгырап.
Болай барса,
Авыл мәчетендә дога түгел,
Матәм генә торыр яңгырап.

Кемнәр саклар иман кәлимәсе
Языла торган тормыш дәфтәрен?
Булып калмасмы соң Изге йортлар
Халкыбызның мирас һәйкәле?

Жилләр куа кара болытларны,
Дөнья ачыла. Уйдан бушанам.
Кояш барлап йөри мәчетләрне...
Ә Кояшка,
Кояшка мин һәрчак ышанам.

## АЕРМА

Тезелеп китте кошлар көзләрендә,
Тарта дөньяның кайсы яклары?
Язларында күбесе кире кайтты,
Ә күбесе кире кайтмады.

Югалганын нинди упкын йотты,
Нинди давыл канат каерды?
Шундый матур күктән, шат җиһаннан
Юл афәте мәңге аерды.

...Тезелеп китте ана балалары,
Тик җаннары гына тартмады.
Бик күпләре калды ят туфракта,
Туган җирләренә кайтмады.

Кошлар белән кеше язмышлары
Охшаш диеп языла шигырьләр.
Алай микән?
Моны бары, тирән хискә бирелеп,
Язалардыр нечкә шагыйрьләр.

Кошлар китә үз теләге белән,
Күкләр
Табигатен шундый иткәннәр.
Ана балалары?! «Кайнар нокта»ларга
Ил әмере белән киткәннәр.

Кешелекнең бүгенгегә юлын
Түшәп килгән күпме корбаннар.
Тау иләндә таулар әйтерсең лә
Корбаннардан торган курганнар.

## БЕРДӘНБЕРЕ ИДЕМ ҖИДЕНЕҢ

Мин заманның кадерсезе идем,
Бер үксезе идем чорымның.
Таптап китү белән баш калкыткан
Тузганагы идем болынның.

Ятиме идем басу капкасыннан
Яулык болгап калган авылның.
Кисү белән яңа шытым биргән
Бер төлгәше идем каенның.

Әмма ләкин бер бөртеге идем
Мин әнкәйнең ап-ак чәченең.
Бер бөртеге идем җан биргәндә
Таммый калган кайнар яшенең.

Мин әнкәйнең бер керфеге идем,
Алсулыгы бер як битенең.
Кадерлесе идем, күз алмасы,
Бердәнбере идем җиденең.

Әнкәемнең зур өмете идем,
Киләчәге идем, иманы.
Җиргә биргән, сулыш өргән өчен,
Изге итеп күрәм мин аны.

## ҮЗГӘРМИ КЕШЕ

Яралганнан Җир үзгәргән —
Әллә ниләр булган.
Аның йөрәген айкатып
Аткан бик күп вулкан.

Океан, диңгезләр калыккан,
Йөргән алар күчеп.
Чүлләр урынын алыштырган,
Кар-боз яуган ишеп.

Җир өзлексез гел үсешкә,
Камиллеккә барган.
Чорлар үтеп, өслегендә
Кешелеккә тарган.

Ул бүген дә янарышта—
Матурлыкка бара.
Чиксез галәм йолдызының
Берсе булып яна...

Җирдә бар нәрсә үзгәрә,
Үзгәрми тик Кеше.
Гомер бакый сугыш уены,
Төзү-җимерү эше.

## ИЛ БЕЛӘН

Ут ялмады кешеләрнең күген,
Юк, ул һич килмәде җил белән.
Дошман басып керде. Аңлаттылар,
Без аңладык: бу хәл ил белән.

Ут давылы тынды. Җиңү килде
Май кояшы көлгән көн белән.
Тормыш авыр иде,
Аңа дан җырланды —
Моны аңламадык ил белән.

Еллар ага торды...
Корама Ватан берчак ишеләсен,
Хәл җиңеләймәсен кем белгән?
Яңа заман килде. Анда да шул:
Хәерчеләр йөри ил белән.

## МИН БӘХЕТСЕЗ, ДИЕП ЕЛАМАГЫЗ

Бәхетсезләр, елап бушаныгыз,
Җиңел була, дигән затларны
Тыңламагыз! Мондый киңәш тоткан
Язмышында кырыс алданды.

Нәфис затка, бәлки, шулайдыр ул,
Алар көчсез... Яшен коя да,
Хәлсезләнеп, өмет белән карый
Бәхетен урлап яткан дөньяга.

Ә ир-атның хәтта гарасатта,
Яхшы беләм, елый сирәге.
Елак жанның юлы — ахирәткә,
Чыдый алмый аның йөрәге.

Үземдә дә бәхет дигән сылу
Бик көлмәде аткан таңымда.
Мин бәхетле идем, йөрәк тамыры
Шартламыйча калган чагында.

Кешеләрнең гомер тулпарына
Бәхетсезлек шактый ияргән.
Бәхет өчен көрәшергә кирәк!
Күз-яшь түксәң егылырсың
Яшәү дигән затлы иярдән.

## КҮҢЕЛДӘГЕ МОҢНАР

Авыл. Шыңгый яры. Туган нигез.
Ярдан тавыш бирә керәшә.
Гүя йөгереп чыгасың күк, әнкәй,
Күңел синең белән сөйләшә:

Күзләреңдә яшьләр... Сагындыңмы?..
Тик каргама мине, каргама.
Миндәй күпләр газиз туфрагыннан,
Нигезеннән китеп алдана.

Минем дә бит менә сагынуларым
Алларыңа кайтып ишелде.
Дәшәм... Беләм... Авыр...
Югалдым шул
Синең соңгы казың шикелле.

Соңгы бәбкәң кебек юкка чыктым,
Тормыш дигән тилгән урлады.
Ләкин ышан, бервакытта да син
Йөрәгемнән чыгып тормадың.

## КЫШКЫ МОҢНАР

Төне буе буран җырын сузды,
Кышкы җиһан тулды моңнарга.
Кубарылды халәт!
Нечкә моңнар гүя алып китте
Үткәннәрдә калган елларга.

Таңга кадәр буран — җыр йомгагы
Сүтелде дә һаман сүтелде.
Әйтерсең лә дөнья күкрәгеннән
Моңлы бала чагым үтелде.

Малай чактан киттем, моңнар төяп,
Тормыш кыры сүрән, чырайсыз.
Һәр почмагы — сугыш хәрабәсе,
Яшь алмас төсле моңнарсыз.

Йөрәгемдә буран җыры иде,
Юлларыма чәчтем моңнарны.
Алар белән кеше таза рухлы,
Моң үстерә зирәк улларны.

Бик күпләрне җырлы табигате
Алып кала әҗәл кулыннан.
Моңнар белән аның хәсрәтләре,
Кара кайгылары юылган...

Сүтелеп бетте буран — җыр йомгагы,
Дөнья оеды — калды тын гына.
Ә тынлыктан өннәр пышылдавы:
«Кешене камил иткән моң гына».

## ЯЗМЫШ ҖӘЗАСЫ

Кыен чакларыңда кил, диден син,
Чакырмаган көнең күрмәдем.
Менә минем сиңа хис дуласа,
Белә торып, кил син, димәдең.

Башкаеңа зилзиләләр төшсә,
Килеп җитче, диден, арала.
Араладым... Шундук кинәт кенә
Мин-минлегең керде арага.

Уйнар кош идең шул түрәләрдә,
Шуңа бик һавалы булгансың.
Син бу җиргә игелек өчен түгел,
Сөяркәлек өчен тугансың.

Ә түрәләр көлеп таралдылар...
Күзләреңә кереп барасың.
Тагын чакырасың... Юаргамы
Йөрәгеңнең
Җиңел акыллылык ярасын?
Аны җирдә беркем юа алмый,
Ул тирәндә ята —
Үтеп киткән тормыш төбендә.
Тапланган язмышың җәзасы ул
Картлыгыңа барган көнеңдә.

## ТАШЛАМА, ШИГЪРИЯТ!

Язмыш мине салып кыйнаганда,
Йөрәгемдә янды бер ният:
Юлда бәхет ташлап китсә китсен,
Тик юлдашым булсын Шигърият!

И Шигърият! Гомерем кышларында
Булдың миңа кайнар учагым.
Тормыш суыклары өткән чакта,
Урын бирде җылы почмагың.

Айлы төнем, якты көнем идең,
Өмет өрдең шомлы таңыма.
Яшәү ялкыннары өстәп тордың
Кыйналудан арган җаныма.

Рәхмәт Сиңа — кире кабул иттең,
Һич сорамыйм шигъри тәхет тә.
Нурланышы булып моңнарымның
Син әйләндең көткән бәхеткә.

Һәрбер туган таңым һәм көннәрем
Шул моңнарым белән башлана.
Языласы күпме җырым дәшә,
Шигърияттем, мине ташлама!

## МИРАС

Тормыш тавы сыкрата да куя,
Кайвакытта тиен теңкәгә:
Менгән чакта, йөгең артка сөйри,
Төшкән чакта төртә җилкәңә.

Ә табигать тавы рәхимлерәк:
Әгәр калсаң анда адашып,
Авазыңны ерак яңгырата,
Кемдер килеп таба, җан атып.

Тормыш тавы алдый. Син белмисең
Менгән мәлдә нәрсә буласын.
Хыянәтчел: кайчак упкынына
Баш-аягың белән чумасың.

Минем әле, шөкер, егылган юк,
Үтеп барыш тормыш тавыннан.
Чөнки монда нәсел-шәҗәрәмнең
Мин таймаслык юлы салынган.

## КАБЕР ТАШЫНА ЯЗЫЛАЧАК ШИГЫРЬ

(Васыять)

Бу зиратка килеп керсәң, әй якташым,
Туктап кал да укып кара кабер ташын!
Туган илне сагынып кайтып, тән иңдерде
Гомер буе читтә йөргән авылдашың.

## БИЛГЕСЕЗЛӘР

Мәңгелек ут. Аста — Билгесезләр...
Үз чорында
Илнең умырткасы, терәге!
Җир куенынннан Мәңгелек ут булып
Янып ята алар йөрәге.

И Билгесез солдат! Корал алып,
Байрак тотып көчле кулыңа,
Ватаныңа кергән дошманыңның
Үлем булып бастың юлына.

Бөек җиңү өчен көрәшләрдә
Аягүрә аудың, дан булып.
Ялкыннарда исемең югалса да,
Мәңге калдың
Тарих битләренә язылып.

Билгесезлектән дә Билгесезләр рухы —
Илнең сынмас рухи терәге.
Җир куенынннан Мәңгелек ут булып
Янып ята алар йөрәге.


## ТУГАН ЯКНЫҢ ЯКТЫ ИРТӘСЕ

Туган якның язгы иртәсе,
Күләгәдә кырау җемелди.
Чыркылдаша шаян чыпчыклар,
Күгәрченнәр дәртле җыр көйли.

Ә арырак — бакча артында —
Якты балкып урман аланы
Кызыктырып дәшә үзенә,
Чакыргандай нәни баланы.

Ирексездән чыгам шунда мин,
Тик дәү инде: ат-ат уйнамыйм;
Бары ак бәс төшкән болынга
Әкрен басып атлыйм бер көйгә.

Алтын бала чагын сагынып
Йөрми микән шулай кайсыбыз?
Артка карыйм, анда бары тик
Бормаланып ята яшел эз.



# Күңеләңә гөл утырткан идем

Мин яшәдем сихри бер дөньяда –
Ул яз иле, утлы наз иле!
Анда сөю, анда ләззәти көч,
Тагын әллә ниләр бар иде.

## ТОРМЫШ ҮЗЕ МАТУР

Яшьлегемне күпме кыерсыттың,
Күпме матур мизгел югалттым.
Күпме хыялларны сүндердең дә,
Кабат кабыныр, дип юаттың.

Гомерлек яр түзми ташлап китте,
Артык яраткангa мин сине.
Кимсетүләр бирдең, кимсенүләр —
Алар сүнүемә тиң иде.

Кайчагында болытларың басты
Зәңгәр көннәремнең яктысын.
Шатлык-сөенечләр китердең дә
Тартып ала тордың яртысын.

Мәдхияләр яздым, сине мактап,
Миңа түгел, сиңа кирәккә.
Синең өчен һаман җан атуым
Сырхау булып ятты йөрәккә.

Кайчак зурлаган да чагың булды,
Ярдәмең дә тиде — яшермим!
Әмма кайнар, утлы кочагыңның
Җылысына туймый яшим мин.

Шаһинәләр төсле гүзәл дә син,
Ханбикәләр кебек кырыс та...
Әнә шундый кайбер үпкә белән
Карап торам матур Тормышка.

## МӘХӘББӘТ УРАМЫ

Караттырдың мине,
Яраттырдың мине,
Язгы кичләр иде урамда.
Җитәкләшеп кереп киттек икәү
Мәхәббәттән торган буранга.

Дулаганы булды,
Азрак тынган чагы
Янар хисле илаһ буранның.
Ни булмасын, минем язмышыма
Син көчлерәк кереп уралдың.

Җирдә, күктә,
Каурый болытларда
Ак хыяллар булып йөздем мин.
Ул хыялда җәннәт бакчасыннан
Синең өчен чәчәк өздем мин.

Бу дөньяда, сиңа охшаганга,
Бөтен матурлыкны яраттым.
Ах, ул сөю,
Тоташ яну-көю,
Ялкыннары өтте канатым.

## ҖЫЛЫ ҖИЛЛӘР ИСӘ

Җылы җилләр исә,
Җылы җилләр,
Җылы җилдә битең иркәлә.
Җылы җилләр,
Тапшырыгыз әле
Кайнар хисләремне иркәмә.

Җылы җилләр исә,
Җылы җилләр
Толымыңны кагып уйныйлар.
Алар шулай, сине назлый-назлый,
Бәхет таңы сиңа юрыйлар.

Җылы җилләр исә,
Җылы җилләр
Яулыгыңны алып китмәсен.
Җылы җилләр,
Алай шаярмагыз —
Бер кыз бала көтә иркәсен.

## БЕЗНЕҢ АРА ЕРАКЛАШКАН САЕН

Аңлыйсыңмы, ялгыз елларыбыз
Офыкларга таба омтыла.
Безнең ара ераклашкан саен,
Синдә миңа кышлар котыра.

Язлар булып килеп кергән идең
Күңел бакчасының түренә.
Шаһинәдәй күреп, чәчәкләрдән
Сарай салдым анда үзеңә.

Тормышның бер капылт борылышында
Без нәрсәне сизә алмадык?
Кинәт кенә янар хисләреңне
Зәмһәрирдәй суык ялмады.

Күреп йөрим, бик еш үкенүле
Әрнешүгә бирелеп куясың.
Беләсеңме,
Кышларыңнан кабат язларыңа
Килә синең белән чыгасым.

## ТУГАН ЯК ЧИШМӘЛӘРЕ

Тормыш кысан. Яшәү алга дәшә.
Күп юлларны ятим итмәдем.
Дөнья кырындагы юлларда мин
Хәстәрләдем хәләл икмәгем.

Төрле җирдә төрле чишмә күрдем,
Казылганын, таудан типкәнен.
«Фазыл чишмәсе»дәй, мәхәббәттә
Мәңге үлмәс җырга күчкәнен.

Арып-талган чакта һәммәсенең
Көмеш салкын суын татыдым.
Тик берсе дә алар тәме белән
Басалмады сусау ялкынын.

И туган як! Чишмәләрең суын
Эчкәч кенә бетте аруым.
Алар шундый татлы, шифалылар,
Әйтерсең лә әҗәл даруы.

Үз чишмәсе аккан ярда гына
Зифа булып үсә тирәк тә...
Туган җирнең йөрәгеннән чыккан
Дәва булып ята йөрәккә.

## АКЧАРЛАКЛАР ҮКСИ ҺАВАЛАРДА

Чәчәкләрдән
Такыя үрдем Сиңа — сөйгәнемә,
Элеп куйдым Кама күкрәгенә.
Һич борчылма — безнең учак яна!
Күчердем мин аны йөрәгемә...
Акчарлаклар үкси һаваларда,
Канатына моңны алалар да.
Күңелемне сызлатып ла
сызылдырып
Яшисең син минем яраларда...
Акчарлаклар үкси һаваларда.

## КАРУРМАН

Җирдә генә үсми карурманнар,
Кеше күңеле дә карурман.
Кайберсендә аның ерткыч йөри,
Кайсысына сагыш, моң тулган.

Сагыш-моңым төяп барган чакта,
Карурманда юлым саташтым.
Ләкин саташмадым... Менә синең
Карурманга кереп адаштым.

Күпме вакыт сукыр пәйгамбәрдәй
Йөрим һаман бәреләсугыла.
Сулга барсам — салкын йөрәгеңнән,
Уңда мәкереңнән егылам.

Чыгар идем, сукмак таба алмыйм,
Ах, караңгы синең урманда.
Мин эзләгән зәңгәр чәчәкләр дә,
Сайрар кошлары да юк анда.

Минем урманымда чәчәкләрнең,
Кошларның да һич юк исәбе...
Ике карурманда — ике дөнья,
Нишләдең син, Сөю, нишләдең?

## ҖАН АВАЗЫ

Чишмәлектә язын бик тә моңсу,
Тирәлектә сайрый таң кошы.
Сагынып еларсыңмы су алганда,
Чагылып китсә гәүдәм балкышы.

Кушымта:

Васыятемне җырлап йөрерсеңме,
Җыр калдырсам синең турында?

Ташкын булып аккан хисләреңә
Сагыш алып килсә кар-сулар,
Иренем тәмен искә алырсыңмы,
Җаның сусаганда ярсудан?

Кушымта.

Төшләреңә туй көннәре керсә,
Йөрәгеңдә калсын сер булып.
Язгы тауда сулар сибәрсеңме,
Тишелеп чыкса җаным гөл булып.

Кушымта.

## КӨЗГЕ МОҢНАР

Алтынланган матур көзләр килә,
Табигатькә төшеп оялый.
Көз — сагыш ул! Тышкы матурлыкка
Беркайчан да булма хыялый.
Кайчак көз ул сихри бер манзара,
Бу сихрилек тик ясалма гына,—
Ясалмалык һәрчак алдалый.

Мин көзләрне артык яратсам да,
Шактый сынады ул язмышны...
Артык яратулар кабатлата
Кабатламам дигән ялгышны.

Сары яфрак коела. Сер бүлештем
Сихрилеге ашкан яр белән.
Йөрәгемә кереп эреде дә
Китеп барды минем җан белән...

Ясалмалы сихри карашлылар
Үз «корбанын» оста күрәләр.
Аң булыгыз, хистән ташыганнар
Йөрәгеңә керә беләләр.

## ҖИМЕРЕЛГӘН ЯЗМЫШ

Тунга төреп, мәче тизлегендә
Җилдерделәр салып чанада.
Атлар тоягыннан тик өермә
Тузгып калды кичке һавада.

Елап-иңрәп, мин артыңнан чаптым,
Сөрән салып бөтен урамга.
Балачакның әрнүләре акты
Атлар җилеп барган юлларга.

Хәйләкәр зат нәни йөрәгемә
Утка манган очлы ук атты.
Миннән тышка дәшеп чыгартты да,
Яраткан апамны урлаттым.

Фәрештәсез калган ул заманның
Күпләрендә
Юк иде шул иман-догасы,
Азмы чибәрләрне түбәнсетте
Татарның ул кыргый йоласы.

Тик хәбәрең килде башкаладан...
Еллар аша
Эзләп таптым сине Казанда.
Картайсаң да, шундый матур идең,
Гүя кыз чагың күк һаман да.

Минем малай чакның ялгыш адымын
Кичердем мин инде, дисең син.
Алларымда яшьтән канатлары
Каерылган коштай идең син.

Нигә ир-ат бары үз хисләрен
Алга куя икән атлыгып?
Тормышта бит
Уртак мәхәббәттә — дөнья яме,
Яшәү гаме, яшәү шатлыгы!

## ТУЙ КҮЛМӘГЕ

Килү белән язлар, һәр кич назлап,
Пар сандугач җырын тыңладык.
Язлар бәхет бүләк итте безгә,
Туй күлмәген алдык нәкъ шул көздә,
Тик кияргә насыйп булмады.

Мин еш киләм чишмә аккан җиргә —
Яшьлек эзем, татлы хыялга.
Чишмә ага чакрымнарын иңләп,
Минем хисләр без танышкан җирдә,
Ник килмисең, иркәм, шул ярга?

Яшьлегемә кире кайтыр идем,
Кабатланмас булса ялгышлар.
Башкаларны йөрәк кабул итми,
Күз алдымнан буй-сыннарың китми,
Күңелемдә — әрнү, сагышлар.

Чишмә җыры бик ямансу була,
Бигрәк моңсу була көзләрен.
Януларым, көюләрем белән
Сагынганда туй күлмәген киям
Һәм юлларда була күзләрем.

## ТАТАР КЫЗЫ

Изгеләрдән изге җан иясе,
Толымыңнан таҗлар үрмәсәң.
Җирдә сөю барын белмәс идем,
Татар кызы, сине күрмәсәм.

Кушымта:

Татар кызы — кара кашлар, янар күзләр,
Энҗе тешләр арасында — тәмле сүзләр.
Җир йөзенең фәрештәсе — нечкә билдән,
Ай Зөһрәсе, милли гүзәл, күктән иңгән.

Җир шарыннан шуып төшеп калдым,
Айга менәм, имеш, яныңа.
Татар кызы, саф-пакь сөю өрдең,
Керләнмәгән изге җаныма.

Кушымта.

Язмышымда ялгыш китәр иде,
Эзләп табып сөям димәсәм.
Яшәү тәмен һич тә белмәс идем,
Татар кызы, сине күрмәсәм.

Кушымта.

## БӘХИЛЛӘШМИМ — САУБУЛЛАШАМ

Мин дөньяга килү белән,
Анам кат-кат юган чишмә...
Саубуллашырга дип килдем
Язгы кичтә, чумып хискә.

Саубуллашам ярлар белән,
Ярда үскән таллар белән,
Тәпи баскан, нурга күмеп,
Юл яктырткан таңнар белән.

Беренче хис хатирәсе —
Юл чатында ялгыз каен.
Каен кебек тәлгәшләрем
Булды башым игән аем.
Ялгыз яндым көннәр-төннәр,
Тик сынмадым, сыгылмадым.
Бәхилләшмим — саубуллашам,
Бала чагым, туган ягым.

Яшәү көче биргән әнкәм,
Җан җылысын өрә-өрә,
Ак күлмәктән, ак чәчәктән
Пакь җан булып төшкә керә.
Кызыл, зәңгәр, ак, шәмәхә
Чәчәкләрдән чәчәк туган,
Бәхилләшмим — саубуллашып
Китеп барам кайтыр юлдан.

Пар ат җигеп, язмыш юлын
Парлап үткән тормыш дустым,
Яраланган яшьлегемә
Канат биргән очар кошым,
Яшь-җилкәнчәк тә көнләшсен,
Сөю хисен чәчик әле,
Тагын йөз ел, бәхилләшми,
Җир җимертеп яшик әле.

## ЯЗГЫ МӘХӘББӘТ

Лебер-лебер сөйләшәләр,
Серләшәләр каеннар.
Каеннар күк гашыйк булып,
Башым игән аем бар.

Кушымта:

Бер өрүдә зур сөюнең
Шәмнәре сүнә микән?
Язын килгән мәхәббәтнең
Шаукымы бүтән икән.

Көянтәдә — сандугачлар,
Ничек билләре түзә.
Беренче килгән олы хис
Язын үзәкне өзә.

Кушымта.

Җил булып елап йөрмәсен
Зур сөю язгы таңда.
Кил күңелгә өмет өстәп,
Бәхетләр теләп җанга!

Кушымта.

## ӘЙТЕЛМӘГӘН СҮЗ

Ниндидер сүз яшерә идең миннән,
Сиздем аны, тойдым күрәгеn.
Иң кадерле нәрсә җитмәгәндәй
Борсалана иде йөрәгем.

Каеннарда җәйнең күкрәүләре,
Гөлләр керфегендә — таң чыгы.
Иртә югалтулы шушы җәйдә
Колагымда гүя җан чыңы.

Кырлар күкрәгендә тургай моңы,
Җилләр йөри моңга үртәлеп...
Җеназаңда үзең белән бергә
Әйтелмичә калган
Шул сүзеңне илттем күтәреп.

Каеннарда инде көз күкрәве,
Сары яфраклардан
Ул сүзләрең тамды беркөнне:
«Бу дөньяда синнән артыграк
Яратмадым мин бит беркемне...»

## ТӨШТӘ ГЕНӘ

Кичә генә ак төшемә кердең —
Чәчләремнән сыйпап яраттың.
Юксынуның үзәк өзүләрен
Иркәләвең белән тараттың.

Мин яшәдем сихри бер дөньяда —
Ул яз иле, утлы наз иле!
Анда Сөю, анда ләззәти көч,
Тагын әллә ниләр бар иде.

Каурый болыт, йөртеп канатында,
Кабат безне җиргә төшерде.
Сак белән Сок төсле икебезне
Таһир белән Зөһрә иттерде.

Бу дөньяның киңлегендә гүя
Тик без иң бәхетле икәнбез...
Уяндым да...
Тормыш баскычының салкынында
Юксынуым белән икәү без.

## ФӘЙРҮЗӘ

Күңелемнең түрләрендә
Гөлләр, чәчәкләр үсә.
Шул чәчәктән букет бирсәм,
Алырсыңмы, Фәйрүзә?
Яз тургае Фәйрүзә!
Карашың бәгырьне өзә,
Йөрәгем ничек түзә?

Маңгай бөдрәләрең сыйпап,
Иркәләп, җилләр исә.
Таралсын йөрәктә сагыш,
Бер елмайчы, Фәйрүзә.
Яз тургае Фәйрүзә!
Карашың бәгырьне өзә,
Йөрәгем ничек түзә?

Каршыбызда бәхет таңы
Юлларга гөлләр тезә.
Киләчәктә пар йолдыздай
Балкып яныйк, Фәйрүзә.
Яз тургае Фәйрүзә!
Карашың бәгырьне өзә,
Йөрәгем ничек түзә?

## ТӨШЕНҮ

Бер-беребезне күреп туймый идек,
Тугры идек назга, сафлыкка.
Арабыздан Иблис үттемени,
Сүрәнләндең соңгы вакытта.

Бер-беребезне күреп туймый идек,
Татлы иде зәңгәр кичләр дә.
Кояшыңның йөзе чытыкланды
Безне төреп торган хисләргә...

Соң, алайса, ялгыз яшәп кара,
Бәлки, кабат чәчәк атарсың.
Йөрәгеңә миннән артыграк
Наз салучы җанны табарсың.

Ах, карашың нинди мөлдерәмә,
Үзәгемә үтә яшерен зар!
Гафу! Мин бит
Бу дөньяны артык яратканга,
Киметкәнмен Сиңа игътибар.

## ЯШЬЛЕГЕМ ЭЗЛӘРЕ

Җил белән серләшкән каеннар
Яңарта яшьлегем хисләрен.
Шомыртлар ак шәлен ябынса
Сагынам авылым кичләрен.
Сагынам, сагынам, өзелеп,
Ялкынлы яшьлегем эзләрен.

Назлы җил, салмак җил китерә
Чәчәкле болынның исләрен.
Мин тоям, тоям мин җилләрнең
Яшьлектән наз булып искәнен.
Сагынам, сагынам, өзелеп,
Шул назлы яшьлегем эзләрен.

Бирелеп хыялга, уйларга,
Тыңлыйм мин агышын чишмәнең.
Чишмәләр җырлыйлар моң итеп,
Җырлыйлар яшьлегем хисләрен.
Мәңгегә сакласын авылым
Давыллы яшьлегем эзләрен.

## АЛДАНУ

Һич көтмәдем андый очрашуны —
Ул мизгелләр өнсез иттерде.
Тиңсез гүзәллектәй пәйда булдың
Пушкинның нәкъ Керны шикелле.

Хис һәм сөю, омтылыш һәм газап
Барсы бергә дөрләп кабынды.
Шул минуттан мин тик бернәрсәгә —
Бары сиңа гына табындым.

Язмыш миңа мәрхәмәтсез булды:
Мәхәббәтем күген
Болытлары белән каплады.
Син дә ул вакытлы чатырыңда
Йөрәгемне салып таптадың.

Ә шулай да хәзергегә кадәр
Тәүге очрашуның
Мизгелләре белән яшимен.
Бүген дә әле алдану һәм үпкә,
Юксынуның ачы яше мин.

## ТОЛ ХАНЫМ

Кабан күлендә дулкыннар
Серен сорый моңсу ярның.
Суга карап, уйга чумган
Әле бик яшь бер тол ханым.

Кушымта:

Ялгызлыкта ялгыз янып
Кимсенмә син, әй тол ханым.
Парың тапсаң юаныр ла
Рәнҗеп арган изге җаның.

Салмак җил иркәли аны,
Яңгыр юа толымнарын.
Ник соң яшьли ул тол калган,
Ни гаебе бар соң аның?

Кушымта.

Казан таңда хискә чумган,
Сандугачы сайрый талның.
Ак мендәрдә ялгыз ята
Әле бик яшь бер тол ханым.

Кушымта.

## ЛЮЦИЯКӘЙ

Люциякәй, каршы очраганда,
Мин эшдәшсәм, миңа дәш, яме!
Син бит — минем күңелем кырларында
Янар чәчәкләрнең бәйләме.

Люциякәй, алларыңа килеп,
Башым исәм, кабул ит, яме!
Син бит минем барыр юлларымда
Яшьлек көче, яшьлек бәйрәме.

Люциякәй, алларыңа килеп,
Кулым бирсәм, аны ал, яме!
Син бит — минем, —
Бары минем генә! —
Гомер сукмагымның бер яме!

## АГАР СУ БУЛСАМ ИДЕ

Салкын чишмә суы булып
Аксам теләгән җиргә,
Кайтыр идем, юллар ярып,
Иң элек туган илгә.

Борма-борма эз калдырып,
Далалардан бермәлне
Үтәрмен мин тамырына
Шиңеп калган гөлләрнең.

Урармын урман-болыннан,
Сандугач моңын тыңлап,
Ялгыз аккош уйнар иде
Суымда җырлар җырлап.

Янган тамагын чылатсын
Җаны көйгән дошманым.
Көмеш кебек саф-пакь суым
Эчә килсен дусларым.

Зур Иделгә кушылырга
Ашкына минем күңел.
Ярыңда сөйгәнем калды,
Нигә соң мин су түгел?

## НӘРСӘ ӘЙТИМ?

Йөрәгеңне кайчак тыңлап кара,
Сизәсеңме, салкыная ара.
Талкый булса кирәк сине миннән
Җылы сүзләр көткән хаксыз яраң.

Язның чәчәкле таҗ кигән чагы,
Күңелемдә тынмас хисләр давы.
Син дә минем шундый бер таҗым бит, —
Нәрсә әйтим сиңа шуннан ары.

Мин дә көтәм синнән кайнар сүзләр,
Күзләреңә төбәлгәннәр күзләр.
Син — янар хис, мәхәббәтем хөкемдары, —
Шуннан артык нәрсә әйтим тагы.

## БЕР КАБАТ

Шәфәкъ җиргә бизәк булып төште,
Тирә-якта кызгылт нур гына.
Карашыбыз шушы манзарада,
Ә йөрәктә сөю, моң гына.

Кичке болын — зәңгәр чәчәк төе,
Зәңгәрлеге сиңа сарылган.
Зәңгәр күлмәк кигән фәрештәдәй,
Уйчан атлыйсың син янымнан.

И дөньяның гүзәл шаһинәсе!
Күпләр әле белми, белмәсә:
Сездән башка бу Җир кояшсыз бит,
Ә кояшсыз Җир ул — буш нәрсә.

Кинәт актарылды эчке дөнья,
Безнең ялкыннарга түзмәде.
Утлы иренебез, шашып, йотылып,
Бер-берсеннән ләззәт эзләде.

Хисләремә шигең юкка булуын
Тормыш инандырды күп тапкыр...
...Кеше җиргә тик бер тапкыр килә
Һәм чын ярата ул бер тапкыр.

## САГЫНУ

Кошлар китсә, илдән парлап китсен,
Башы язын ялгыз кайтмасын.
Ялгыз кошым, кара күзләреңне,
Сагыш баскан ап-ак йөзләреңне
Минем өчен кояш назласын.

Көткәннәргә бик ямансу була
Шомырт чәчәк аткан иртәләр.
Шул иртәдә бәсле чәчләреңне,
Керфегеңдә калган яшьләреңне
Минем өчен җилләр иркәләр.

Сагынганда, җәй айлары озын,
Хыялый ай алтын нур сибә.
Адашудан, ялгышудан саклан,
Ялгыш уйлар башка гел килә,
Беренче яр була бер генә.

## МӘҢГЕЛЕК УТ

Җыйнап, сугыш серен
Мәңгелек ут сөйли,
Сүзсез сөйли тарих ялкыны:
Исән калды микән,
Дөрләп янды микән
Ап-ак шәлен япкан яу кызы,
Алтын йолдыз таккан таң кызы?

Чәчләрдәге бәсләр,
Күзләрдәге яшьләр
Югалганнар, өмет өзмим мин.
Утлы юллар узган
Таң нурыдай кызлар,
Яз җилләре иссә, түзмим мин,
Чәчәкләрдән сезне эзлим мин.

Мәңгелек ут дөрли,
Кояш җиргә сөйли.
Шаһит дөнья яман ярсулы.
Бәхет өмет иткән,
Туйлар вәгъдә иткән,
Хыялдагы туйны күрми киткән —
Мәңгелек ут — җаннар ярсуы.

## БҮЛӘК ИТ СИН

Бүләк итмә ал чәчәкле алан,
Буш аланда ялгыз каен сыман
Саргаялар алар көзләрен.
Синсез калсам мин соң нишләрмен?

Кушымта:

Бүләк ит син миңа җан җылысы,
Саф-пакь сөю, кайнар хисләрең.
Шул хисләрсез калу — илсез калу,
Ә мин илсез, синсез нишләрмен?

Күктән йолдыз чүпләп бүләк итмә,
Ялтырый да оча кичләрен.
Таң атканда, янар соңгы йолдыз,
Син дә сүнсәң, мин соң нишләрмен?

Кушымта.

Бүләк итмә ялгыз сандугачны,
Сихри күлләр тынып калмасын.
Иректә ул үз тиңдәшен тапсын,
Безгә бәхет теләп сайрасын.

Кушымта.

## ТЫЛСЫМЛЫ

И рәхмәтлемен, язмышым:
Карады күзләремә!
Карады да, басып киттем
Ялкынлы эзләренә.

Ул бара да борылып карый,
Ихтыярсыз мин барам.
Әллә йөрәге кояшмы —
Нурыннан дөрләп янам.

Нур, җелегемне эретеп,
Ләззәт бирә җаныма.
И Күкләр! Нинди сөюне
Салдыгыз сез каныма!

Нинди утлар өстәдегез
Дулаган хисләремә...
Ялкынлы сукмак китерде
Ятаклы кичләренә.

Ә тормыш — кырыс хөкемдар,
Кайнап тора казаны.
Шундый тәмуг казанында
Мәхәббәтнең азаны!

## ДИЯРСЕҢ

Ах, бу көзге кичнең зәңгәрлеге!
Урманнарга сихри моң тулган.
Зәңгәр кичтә балкып килер идем,
Диярсең дә, ул чак мин булмам.

Шаулы язда нинди могҗиза бу,
Язлар итәгендә ак томан?
Томаннардан эзләп табар идем,
Диярсең бер, инде мин булмам.

Ялгызлыктан өшегән чагың булыр,
Ялварырсың: «Дустым, мин туңам!»
Йөрәк җылысы белән җылыта иде,
Диярсең дә сыкрап, мин булмам...

## ӘЙ, ГАФУ ИТСӘНӘ, ЙӨРӘГЕМ

Чәчәкле болында
Пар йолдыз нурында
Ай кызы аңлатты серләрен.
Бу, диде, пакь кичем,
Беренче саф хисем.
Бәхетле киләчәк теләдем,
Аңламый ялгышты йөрәгем.

Сайрады таң тугач
Тирәктә сандугач,
Әрни ул сагыштан, беләмен,
Уйланып ялгызым,
Сагынсам таң кызын,
Мин аңа киңәшкә киләмен.
Әй, гафу итсәнә, йөрәгем.

Ә күңел әрнүле,
Офтана, сызлана
Чын сөю югалткан сагыштан.
Ярдәм ит, йөрәгем,
Иң соңгы теләгем —
Беренче ярымны табышсаң,
Нишлим соң, узмыш юк язмыштан.

## ГАРМУН МОҢЫ

Авыл тын. Утлар сүнгәннәр.
Ай җиргә сибә нурын.
Тик бер гармун су буенда
Тарата яшьлек моңын.

Моң ай нурына күмелеп
Тибрәтә күңелләрне.
Сызылып барып кочып ала
Сихри зәңгәр күлләрне.

Дулкынлата ул күлләрне,
Тибрәтә ул тирәкне.
Нигә соң били алмый моң
Бары бер яшь йөрәкне?

## СЕР

(Этюд)

Бер яшь усак, оялгандай,
Назланып, башын салган.
Бөдрәләнгән чәчләренә
Тәлгәш эленеп калган.

Йолдызлар җиргә сер сөйли,
Алар күзәткән күктән:
Имеш, төнлә усак кызын
Миләш егете үпкән.

## КӨТ МИНЕ

Язгы кичләр юмарт була
Сагышка, моңга.
Сагыш-моң йөрәккә үтеп,
Әйләнеп җырга,
Язгы кичләр күңелеңне
Дәшсәләр юлга,
Көтәрмен дигән антың бар,
Ялгышма, уйла!

Яр буендагы каеннар
Яфраклар ярса,
Ал чәчәк атса,
Тәрәз каршында бер шаян
Тальянын тартса,
Яман уйлар җанда уйнар,
Вәгъдәңне сакла.

Юллары ямансу, диләр,
Ялгыз чишмәнең,
Зәңгәр томаннар капласа,
Яшьлек эзләрен.
Кинәт кәккүк тавыш бирсә,
Ак бәхет теләп.
Көт мине, яшәү бүләк ит
Көтүең белән.

Вакытлыча болыт каплау
Язмышың күген —
Бу бит әле мәңгелеккә
Аерылу түгел.

Сагынулардан чәчләренә
Бәсләр төшсәләр,
Көт мине, мәңге ышанмам,
Көтми, дисәләр.

## МӘХӘББӘТ СЫНАВЫ

Таң аткач, тыңлап таң калдым
Сандугач елаганын.
Хәлем аннан авыр иде,
Ләкин мин еламадым.

К у ш ы м т а:

Үз-үземә җавап бирәм,
Йөрәгем сызлаганда.
Ирләр гомердә бер елый:
Мәхәббәт сынаганда.

Язын күргәнең бардыр, әй,
Кыз бала елаганын.
Сөю килгән, күңел тулган,
Уңайсыз, сорамадым.

К у ш ы м т а.

Көзен күзәткәнем бар, әй,
Кыр казы тавышларын.
Юлда калган парын эзләп
Очканын, сагышланып.

К у ш ы м т а.

## ТУЙ БАЛДАГЫ

Яшь парлар балдак алыша,
Моң агыла тын гына.
Кыңгыраулар бәхет җырлый,
Атлар алга ыргыла.

Кушымта:

Ах, шәм шикелле ун бармак,
Пар бармакта пар балдак.
Туй балдагы — вәгъдә бирү
Ата-бабадан калган.

Юртаклар юлны яралар,
Дага эзе ак карда.
Күпме хис килен йөзендә,
Күпме сөю бу җанда!

Кушымта.

Мәңгелек ут дөрләп яна,
Гашыйклар чәчәк сала.
Сафлык анты — туй балдагы
Тулган ай кебек яна.

Кушымта.

Соңгы кат кияү егете
Кочаклап яшьлек дустын,
Тальян чыңы җырлап, елап
Озатты авыл кызын.

Кушымта.

## СУ ҺАМАН ШАУЛАП АГА...

Авылым күге өстендә
Һәр кич пар йолдыз яна.
Йолдыз нурына төренеп,
Пар каен яфрак яра.
Без икәү килгән чишмәдә
Су һаман шаулап ага,
Су һаман җырлап ага.

Әйтерсең лә бәхет теләп,
Сандугач канат кага:
Мин ялгызым моңланганда,
Сандугач аваз сала.
Беренче яр, ди, йөрәкнең
Мәңге түрендә кала.
Су һаман шаулап ага...

Без парлап килгән чишмәнең
Кемдер каенын кискән.
Күкне да болыт каплаган,
Йолдыз нур сипми кичтән.
Төшләремә һәр көн кермә —
Кабат яңара хисләр,
Һич тә чыкмыйсың истән.

## МОҢНАР

Еламсырап, җылы яңгыр ява,
Гөрләвекләр йөгерә елгага.
Яңгыр түгел, әйтерсең лә күктән
Үзәк өзгеч татлы моң ага.

Моңнар үткәннәргә кире китә —
Икебезнең яшьлек дөньяга.
Һәм кайчандыр безне үзенә кочкан
Каеннардан сорый: «Ул кая?»

Җилләр елый урам киңлегендә,
Агыла гүя Ширин тавышы.
Җилләр белә: безнең язмышларда
Ширин белән Фәрһад язмышы.

Син дип ташлы тауны ярганым бар,
Узганым бар авыр сынаулар.
Күзләремнең нуры кими бара,
Чигәләрдә бәсле кыраулар.

Һәр көн йортың күзлим. Тәрәзәңә
Томан булып моңнар эленгән.
Алар тели ике ялгыз җанны
Күтәрергә тәкъдир төбеннән.

## КАЙТУ

Тагын әле менә искә төштең,
Уйлап йөрим синең хакыңда.
Ара якын. Ләкин ни өчендер
Син — яз, ә мин кышлар артында.

Синнән башка туңам, өшим, катам,
Ачы кабат язың капкасын.
Әнә күкләр нинди сихри зәңгәр,
Куалаган болыт япмасын.

Күңеленә гөл утырткан идем,
Алар инде күкрәп үскәндер.
Әллә аны салкын кулы белән
Өзеп ташладымы кемнәрдер?

Юк, юк, булмас!
Тургайларның җыры
Китермәде андый хәбәрне.
Искә яшьлекне ал һәм хәтерлә
Унҗидедә булган хәлләрне.

## АЧЫК ХАТ

Шигырьдә күк юк, эзләмим сине
Офыклардан, томан, таулардан.
Тавышыңның да көтмим ишетелүен
Урман арты — әллә кайлардан.

Юксынулар аша әйткән чакта,
Мин үзеңне синең көтәмен.
Көтү хисе татлы бер сагыш ул —
Ләззәтләнеп, сагыш сүтәмен.

Шаулап үсә безнең бөдрә каен,
Төпләрендә синең эзләр бар.
Ул эзләрне саклап кадерләүче
Минем кебек, белмим, кемнәр бар?

Бер мин генә сагынмыймдыр сине,
Сагыналар инеш таллары.
Син киткәннән бирле алар моңсу,
Талларның да бар бит җаннары.

Сагыналар сине суын эчкән,
Җырлап аккан көмеш чишмәләр.
Алар җырлавыннан туктар иде,
Әгәр син оныткан, дисәләр.

Минем дә юк шөбһәм онытуыңа.
Фәрһад белән Ширин шикелле,
Арадагы уртак яратулар
Безне тоташ бер җан иттерде.

Үпкәләрең ташла уйнак җилгә,
Мәхәббәттә юктыр кирәге...
Сине көн дә каударланып көтә
Миндә калган ярты йөрәгең.

## ЭХ, ГОМЕРНЕҢ АГЫШЫ

Кама дулкыннары, ярга сикереп,
Каршыбызда шашып биеде.
Зурладылар ике йөрәктәге
Кайнап торган ике сөюне.

Галәм йолдызлары бакчасыннан
Алдыбызга йолдыз коелды.
Икебез дә янып ашкан хиснең
Ялкынлы күлендә коендык.

Гомер үтте... Күзебез дә җитте...
Йолдызлар да коела элеккечә,
Дулкыннар да шулай биюдә.
Ә без инде, җылынып, тик яшибез
Картлык бүләгенә —
Тычкан уты хәтле сөюгә.

## ӨЛЕШЕМӘ ТИГӘН, ӘЙ КӨМЕШЕМ!

Таллыктагы ялгыз сандугачның
Язгы җырын тыңлап юанам.
Әй өлешем, чишмә ярына кил,
Көмеш сулар булып мин агам.

Кушымта:

Көянтәне асып, басмаларга басып,
Сине җырга кушып су алам!
Таң атканда, йолдызларга кара,
Җан җылысы булып мин янам.

Аяз кичтә күктән күзең алма,
Балкып кына калмам, дөрләрмен.
Башка йолдызлардан нурлар алсаң,
Дөрләп кенә калмам, көнләрмен.

Кушымта.

Тиңдәшемне эзләп, ничә көзләр
Ай кызына карап уйландым.
Өлешемә тигән, әй көмешем,
Алтыным бул яшьлек дөньямның.

Кушымта.

## ЗӘҢГӘР НУР

Купты давыл. Актарылды дөнья.
Әйтерсең лә көн-төн буталды.
Давыл селкесә дә, тупылымда
Синнән тамган зәңгәр нур калды.

Ә ул нурда синең күктәй күзләр,
Ике сихри тулым күренә.
Диңгез төсле тирән карашыңнан
Гүя янар хисең түгелә.

Еллар аша нурың күңелемнең
Тупылларын ныграк бизәде.
Кысканда да мине язмыш кулы,
Изгәндә дә тормыш бизмәне.

Арабызда таулар. Үткән кайтмый.
Йөрәк һаман сине юксына.
Мәхәббәткә илаһ бер җыр булып,
Яшьлектәге зәңгәр нур тора.

## АЛМА-АТАНЫҢ АЛМАСЫ

Кояш нуры кызарта
Алма-Атаның алмасын.
Саф күңелемнең бүләген
Ал, йөрәгең янмасын.

Кушымта:

Йөзең пешкән алмадай,
Ай күк тора нурланып.
Таң йолдызым, кайтырмын,
Яшь түкмә син моңланып.

Янмасын йөрәкләрең,
Ал, бәгърем, бүләкләрем.
Алтын алмадай сакла —
Шул соңгы теләкләрем.

Кушымта.

## ТӘҢКӘ КАРЛАР

Тәңкә карлар ява,
Тәңкә карлар
Нәфис кенә куна битләргә.
Тәңкә карлар кунган чигәләрең
Кызлар үпсә — белмим нишләргә?!
Тәңкә карлар ява,
Тәңкә карлар
Мәрҗәннәр күк юлга түшәлә.
Яшьләр сөеп әле оныта ала,
Картлар сөйсә ничек түзала?
Тәңкә карлар ява,
Тәңкә карлар,
Ап-ак канат — чыршы ылысы.
Беренче сөю — дөрләп сүнгән утлар,
Ә соңгысы — гомер җылысы.

## ТӘҢРЕ ХАКЫ

Карашыбыз кинәт очрашты да,
Ике йөрәк
Бер-берсенә шундый тартылды,
Давылланып тинкән күкрәгемә
Сөю уты булып атылдың.

Тәңре безне
Бер-беребезгә белеп яраткандыр,
Бу иманым камил бик аңа:
Сине тудырмаса, Ул мине дә
Һич тудырмас иде дөньяга.

Икебез дә моны яхшы аңлап
Кердек уртак еллар таңына.
Кайнар хисләр, назлар, илаһ сөю,
Серләр бүлешү — булды бары да...

Бүген менә сукмак аерыла,
Арабызда күзгә иртәләр.
Уйлыйсыңмы, безне ялгыз итә
Урынсыз һәм мәнсез үпкәләр.

## СИНЕҢ ТУРЫНДА

Иртәнге чык чишмәләргә
Моң булып тамса,
Кыр чәчәкләре, алланып,
Бөресен ачса,
Зәңгәр күктән җыр агылса
Кояш нурында,
Бар гүзәллек сөйли кебек
Синең турында.

Пар аккошлар туй ясарга
Кайтсалар илгә,
Яшел яфрак ярган каен
Шауласа җилдә,
Бәхетле яшьлек гөрләсә
Идел буенда,
Нәкъ шул вакыт җырлар туа
Синең турында.

Сихри күлнең талларына
Сандугач кунып

Сайраганда, яшьләр түкмә
Күңелең тулып.
Бәхет алып килгән көмеш
Гомер юлымда
Онытырга мөмкин түгел
Синең турында.

## МОҢСЫЗ ТУМЫЙ БЕРКЕМ ДӘ

Һәр күңелнең җирдә үз моңы бар.

Моңсызлар да була, диеп яздым
Күңел кырыс мәлдә җырымда.
Фикеремнән бүген кире кайтам,
Изге Китап тотып кулыма.

Йолдызлардан моңнар килә җиргә,
Ерак булса да бик арасы.
Галәм моңсызларны тудырмый ул,
Юк,
Моңсыз булмый адәм баласы.

Бишегендә сабый елаганда,
Үзәк өзгеч моңнар тоям мин.
Кешеләрнең зарын тыңлаганда,
Йөрәгемә моңнар коям мин.

Мәхәббәт тә хистән, моңнан тора,
Ярату ул
Янар хисле моңнар тарата.
Ә бу җирдә һәркем сөеп-сөелә,
Моңсыз булса, ничек ярата?

## ЯЗГЫ ҖЫР

Җылы нурлар җир өстеннән бөркелә,
Йөрәкләрне җилкендереп, яз килә.

Кушымта:

Язны котлап җырлыйк, дуслар,
Безгә кушылып сайрый кошлар.
Зәңгәр күктә сөенешеп
Янсын серле йолдызлар.
Ла-ла-ла-ла, ла-ла-ла-ла (2 тапкыр),
Зәңгәр күктә сөенешеп
Янсын йолдызлар.

Кояшка таба үрелә саф гөлләр,
Хезмәт җырына күмелә күңелләр.

Кушымта.

Бәхет балкый һәр кешенең йөзендә,
Яз сагынып килә безне үзе дә!..

Кушымта.

Язны котлап җырлыйк, дуслар,
Безгә кушылып сайрый кошлар!..

Кушымта.

## КИЛЕП ЧЫГАР ӘЛЕ КАРШЫМА

Күлнең сандугачы илдән киткән,
Ярсып шаулый шомлы тал гына.
Кара чәчен артка тарап салып
Килеп чыгар төсле каршыма.

Яшьлек көтә язмыш кайтавазын,
Гафу итмәс кебек җан гына.
Гафу итмәс җаным өмет итә,
Килеп чыгар, диеп каршыма.

Соңлап кайткан кәккүк тавыш бирә,
Сагынудан янма, ярсыма.
Күзләреңә өмет нуры өстәп,
Килеп чык син, җаным, каршыма!

## УРАЙ УРМАНЫ

Урай, Урай! Синең кочагыңда
Каеннарны беләм, юкәне.
Яшь егетләр, кызлар юлларыңнан
Чәчәк тотып һаман үтәме?

Көннәр буе эшчән бал кортлары
Аланыңда чәчәк саныймы?
Көмеш чыклы үлән арасыннан
Ромашкалар көлеп карыймы?

Әйтче, урман, нәни куакларда
Алсуланып пешә чияме?
Сине мактап, кошлар җыр сузадыр,
Талгын җилләр назлап сөяме?

Күңел тарта, никтер, синең якка—
Җәйләрең дә тарта, көзең дә...
Урай, Урай! Синең юлларыңда
Суынгандыр инде эзем дә...

## СЫЗЛАНАМ

Еллар каплап киткән мәхәббәттән
Нигә күтәрелдең кинәттән?
Айкадың да куйдың бар дөньямны,
Инде сагыш менә йөрәктә.

Язгы җилләр күңел учагында
Тагын дөрләттеләр зур ялкын.
Хәзер аера алмый азапланам,
Улмы, әллә синме бик якын?

Сулга баксам — хисле елмаюың,
Уңда — Аның назлы карашы.
Кайсы гына якны үз итсәм дә,
Ике уттан тора арасы.

Нәрсәгә дип чыктың хатирәдән,
Мин кызганам Аны, кызганам.
Ул бит тоя, сизә, бәргәләнә,
Аңа карап мин дә сызланам.

## ТУГАН ҖИРСЕЗ ЯШӘҮ ЮК СЫМАН

Ямьле авыл таңын,
Каеннарның шавын,
Май кояшы нурын юксынам.
Мин кырларга гашыйк,
Авылым сагынам шашып,
Туган җирсез яшәү юк сыман.

Тугайларның нурын,
Тургайларның моңын
Сагына йөрәк, гомер тиз ага.
Шәһәр — бәхет нуры,
Ә мин — авыл улы,
Җирне сагынып, күңел сызлана.

Көрәшләрдә күпме
Данлы еллар үтте
Буразнада үскән батырлар.
Алар җырын җырлап,
Туган җирне зурлап
Шаулашалар моңсу каеннар.

## АЛМАЛАРЫ ПЕШӘР ӘЛЕ

Алмалары пешәр әле,
Җыеп алырсың әле.
Аерылып киттең еракка,
Исеңә төшәр әле.

Алмалары пешәр әле,
Җыеп сакларсың әле.
Хәзер сагынмыйм, дисәң дә,
Бер сагынырсың әле.

Алмалары пешәр әле,
Җыеп алырсың әле.
Алмагачлы юллар буйлап
Бергә атларбыз әле.

## ЙӨРӘГЕМ БИТ ҺАМАН ЯШЬ ӘЛЕ

Кабан күлендәге сердәш аккошларның
Берсе кайткан ялгыз, пары юк инде.
Ярларына басып, сиңа җырлар идем,
Кушылмассың, беләм, соң инде.

Кушымта:

Соң икәнен беләм, беләм, соң булсын,
Соң булса да, әйдә, әйдә, уң булсын.
Урамнарда күрсәң, күрсәң дәш әле,
Йөрәгем бит һаман яшь әле.

Бөдрә чәчен артка җилләр тарап салган
Каен кызы, сөйлә сереңне.
Җан җылыңны бирел, кабат яратырга
Аңлыйм, җаный, аңлыйм, соң инде.

Кушымта.

Кабан күле өстен куе томан сарган,
Ярларында хәзер синсез моң инде.
Башым иеп, әгәр синең янга килсәм,
Кичермәссең, беләм, соң инде.

Кушымта.

## ТАБИГАТЬ ҺӘМ МОҢ

Тыңлап торсаң, таулар ыңгыраша,
Ыңгырашуында моңнар бар.
Карурманның җилдә шаулавында
Әллә нинди моңнар, җырлар бар.

Чишмәләр дә җырлый, камышлар да,
Һәм үзенчә җырлый дулкын, яр.
Аларда да җаның елаганда
Тоела торган серле аһәң бар...

Миндә дә бар сөю-хисләр тавы,
Яшьлегемнең янар чишмәсе.
Кайнар суы — синең мәхәббәтең,
Чишмә корса, миңа нишләсе?!

## СҮНДЕ ШАГЫЙРЬ

Сүнде шагыйрь, җырлар язмый, диләр.
Яңа моңлы сүзләр яумый күктән.
Җырлар туар өчен сөю кирәк,
Ә чын сөю тора гел хистән —
Хисләр сүнеп бара...

## АКЧАРЛАГЫН ЭЗЛИ ДАВЫЛЫМ

Күңел-диңгез төптән актарыла,
Белсәң иде минем халәтем.
Дөньям күкләреннән егылырмын да
Сындырырмын төсле канатым.

Диңгеземнең шаулы киңлегеннән
Сиңа китә
Ялварулы чакыру тавышым.
Янар хисем, яшерен Сөюем булып
Шул киңлеккә кереп барышың.

Актарылып шаулап торса да ул,
Анда юк һәлакәт, упкыннар.
Мәхәббәтнең алиһәсе итеп,
Сине көтә кайнар дулкыннар.

Котыра давыл күңел-диңгеземдә,
Акчарлагын эзли — югалткан!
Һәм Син булып аңа аваз сала
Ул Акчарлак ярдан еракта н.

## НИЧӘНЧЕ ЕЛ ЯЛГЫЗ АККОШ КАЙТА

Ничәнче ел ялгыз аккош кайта,
Ничәнче ел моңсу язларын,
Күлгә төшкән серле йолдыз кебек,
Юлда калган беренчесен көтеп,
Ялгыз каршы ала таңнарын.

Ничәнче җәй ялгыз аккош йөзә,
Ялгыз башын чайкап суларга.
Ә бәхетлеләр, сабыйларын сөеп,
Тигез шатлык кичеп, парлашып
Китеп бара ерак юлларга...

Тал төбенә җан җылысын өреп,
Кышлап калды ялгыз аккошым.
Хәтерләтеп: гүзәл җирне иңләп,
Миллион еллар үз тиңдәшен эзләп,
Күкне айкап йөргән ай кызын.

Язлар җитәр, сихри бозлар китәр,
Тагын сагыш басар ялгызны.
Туган күлен, хисен алышмаган
Ялгыз аккош язмышына тиңлим
Беренчесен көткән пакь кызны.

## СОҢГЫ ҮПКӘ

Айлы кичнең йолдызлары,
Җем-җем итеп ялгызлары,
Ялгызлары оча күктән.
Йолдыз кебек очар идем,
Иркәләнеп кочар идем,
Онытылса соңгы үпкәм.
Соңгы үпкәм.
Соңгы үпкәм...

Кушымта:

Йолдызлар! Ачыгыз аңа йөрәгем серен.
Аннан башка бер ямь дә юк,
Аннан башка яшәү дә юк —
Шул серләргә яшеренгән бәхетем минем.

Йолдызларның парлысына,
Сафлысына, пакьлесенә
Безне тиңләп карыйм, иркәм.
Яшьлек бәхетең кайтсын, дисәң,
Беренче кат башың исәң,
Еллар йөрткән серле үпкәм
Бетмәс микән,
Бетмәс микән.

Кушымта.

## СЫНМАДЫМ-СЫГЫЛМАДЫМ

Юл чатында ап-ак шәлдән
Чиккән яулык болгадың.
Себер урманнарын ярып,
Тальян булып чыңладым.
Дошман сынды, ә мәхәббәт
Сыналды, сыгылмады.

Зилзиләле давылларда
Илдән хәбәр тыңладым.
Тамырларымны куптарды,
Ләкин үзем сынмадым.
Туган яктан җыр агылса,
Дус-ишләрне уйладым.

Күпме язлар, кошлар кайтты,
Мин юк идем, дускаем.
Салават күпере чыкса,
Кавышуга юрадың,
Яшьләр түктең, рәхмәт, көттең,
Сынмадың-сыгылмадың.

## КЫРЫС ҖИЛЛӘР

Кырыс җилләр
Агач башларына
Сагышларын элеп калдырган.
Агачы да усал,
Шул сагышны
Минем күңелемә тамдырган.

Кырыс җилләр хәзер,
Пыр тузынып,
Көлеп уйный минем тирәмдә.
Ә арыгач,
Рәхәтләнеп сузылып
Ял итәләр яшел келәмдә.

Кырыс җилләр
Азат сагышлардан...
Мин сагышлы — көтәм берәүне.
Кара чәчкә көмеш яңгыр яугач,
Гашыйк булдым — кара юләрне!

## ТИҢСЕЗ ЯРАТУ

Юлларыңда кыенлыклар туса,
Күңелең минем белән булганда,
Әрнүләрем эри томан сыман,
Яратуың тиңсез булганда.

Алларыңда таулар күтәрелсә,
Үтә алмам диеп уйлама.
Алар сиңа яшәү урыны булыр,
Яратуың тиңсез булганда.

Көрәш кырларында ялкын сыман,
Өермәләр сине буганда,
Ике йөрәк барын җиңеп чыга,
Яратуың тиңсез булганда.

## КИЧЕР, ТӘКЪДИР!

Күл өстендә кичке шәфәкъ
Дулкын белән серләшә.
Камышларда тартар тавышы —
Сөйгәнемә эндәшә.

Ах, ни күрәм! Су кызыдай
Чыктың син камышлардан.
Уздырдың мине, чибәркәй,
Язылган язмышлардан.

Мин җәемнең уртасында,
Ә син әле язында.
Танышырга өлгермәдек,
Ирек бирдең назыңа.

Кичләре таңга тоташты,
Ә таңнары — кичләргә,
Онытылдык, онытылдык
Ләззәт тулы хисләрдә...

Кичер, тәкъдир, диюләрдән
Бүтән чара калмады.
Син үз-үзеңне алдадың,
Мине еллар алдады.

## МӘХӘББӘТЕМ БАР

Җил-давыллар кузгалып,
Мине күмсә кар,
Ул карларны эретерлек
Мәхәббәтем бар.

Боз таулары өскә килсә,
Ара булса тар,
Боз тауларын туктатырлык
Мәхәббәтем бар.

Дөнья матурлыгыннан да
Матур минем яр.
Аңа галәм кебек чиксез
Мәхәббәтем бар.

## ҮЗЕҢ ӨЧЕН ГЕНӘ ӨЗ СИН МИНЕ

Серле күзнең
Серле тамчылары
Кушылып агар кебек яңгырга.
Яңгыр булып ю да өз син мине,
Урам гөле итеп калдырма.

Өз син мине
Үзең өчен генә,
Алларыңа куеп иркәлә.
Таңда каплар болыт,
Өз син бүген —
Соңга калуың бар иртәгә.

Күңел йолдызларын,
Йөрәк сагышларын
Барыр юлларыма сипкәннәр.
Ай Зөһрәсе булып каш сикертеп ала
Төшләремә кереп үткәннәр.

## КЫР КАЗЛАРЫН БЕРГӘ КАРШЫЛЫЙК

Кыр казларын бергә каршылыйк
Күл өстендә яткан басмада.
Казлар белән язлар ташып килә,
Беренче хис, сөю башлана.

Кушымта:

Кыр казлары булып күлгә төшсен
Күктән, бик биектән язмышым.
Тагын ничә еллар каршыларммын
Бу басмада язны ялгызым?

Казлар туй ясыйлар күл читендә,
Уйга талган сихри таллыкта.
Туй җырында күңелләрдә әрнү,
Туй моңына йөрәк талпына.

Кушымта.

Казлар белән, ап-ак болыт булып,
Туган якка кайт син, яшьлегем!
Ага шаулап гөрләвекләр түгел,
Сагынулардан тамган яшь минем.

Кушымта.

## ХИСЛӘР УПКЫНЫ

Карлы кышлар килә,
Ләкин язлар минем көткәнем.
Чөнки бары алар гына белә
Безнең йөрәк якын икәнен.

Туйлар ясар тургай, ә кырларда
Сузылып ятар чәчәк дулкыны.
Тарта мине, һаман үзенә суыра
Сиңа булган хисләр упкыны.

Күзләреңдә дөнья матурлыгы,
Күңелең дә сафтыр — аңлыйм мин.
Син төшергән хисләр упкынынннан
Никтер күтәрелә алмыйм мин.

## ЯЛГЫЗ АЙ ТИНДӘШЕН ЭЗЛИ

Иске елның соңгы киче.
Ай, никтер, тонык янып
Әйләнә җирнең тирәсен,
Уйланып, сагышланып.

Яңа ел туар кичендә
Теләкләр тели-тели,
Ай күк әйләнеп, күңелем
Сезнең якларда йөри.

Өй түрендәге чыршыда
Мин йолдыз булып янам;
Тәрәздән искән серле җил —
Чәчеңнән сыйпап багам.

Талган күзеңнең нурларын
Җан җылым белән төреп,
Керфегеңдә калган яшьне
Киптердем өреп-өреп.

Үзеңә авыр булса да
Сораштың минем хәлне.
Яңа елда, бәхет теләп,
Сәгать сукты бермәлне.

Парлылар җырлап уздылар,
Тибрәтеп йөрәк түрен.
Ялгыз ай тиңдәшен эзли,
Айкап дөньяның күген.

## САГЫНЫР ӨЧЕН

Челтерәп аккан чишмәле,
Айлы, кояшлы ягым.
Кем генә сагынмый икән
Әкияттәй бала чагын.

К у ш ы м т а:

Авылымнан киттем, авылны
Шашып сагыныр өчен,
Язгы ташкын булып кайтып,
Таңда, каршына тезләнеп,
Аңа табыныр өчен.

Чалгы яный чишмәлектә
Кем булсын — әткәй җаным.
Әнкәй судан кайтып килә,
Талир тәңкәләр тагып.

К у ш ы м т а.

Күкләреннән йолдыз чүпләп,
Күзләрне күзгә багып,
Ничек сагынмасын күңел
Сөекле авыл таңын.

Кушымта.

## КӨТТЕРМӘГЕЗ!

Озын юлда парын җуйган
Бер сандугач тирәктә.
Кичтән таңга кадәр сайрап,
Ялкын өсти йөрәккә.

Кушымта:

Сандугач кебек өзелеп
Сагынмыйбыз кайсыбыз?
Көтегез, дип киткән җаннар,
Көттермәгез, кайтыгыз!

Тирәкләрне тибрәндереп,
Канатын кага иртән,
Күңел серен уртаклашып,
Киңәшләр сорый җилдән.

Кушымта.

Ай нуры белән төргәләп,
Юлларны айкый-айкый,
Керфегеннән тамган яшь тә
Сагышын баса алмый.

Кушымта.

Шомыртлар ак шәлен япкан,
Сиреньнәр чәчәк аткан.
Юлда югалган сандугач
Яшьлеген эзләп тапкан.

Кушымта:

Сандугач күк кавышырга
Хыялланмый кайсыбыз?
Көткәннәргә бик тә авыр,
Көттермәгез, кайтыгыз!

## СИН ГЕНӘ...

Күк йөзендә янган йолдызларның
Иң нурлысы була бер генә.
Таң йолдызы кебек юлларыма
Яшәү яме сипкән син генә.
Күңелеңнең саф-пакьлеген өстәп,
Яшәү тәме биргән — син генә.

## МИН ЯШӘРГӘ ТИЕШ ШУЛ ХАККА

Яз кояшы көлеп карар вакыт,
Биргән вәгъдәләрне син сакла.
Кайгы-шатлыкларны бүлгән кешем,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.
Язгы таңда басып ялгыз талга
Сайрап куйса бер кош, шул чакта
Сагышлардан яшь бөртегең тамса,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.

Сирень агачлары чәчәк атар,
Яшел нурлар төшәр яфракка.
Янар яшьлек бүләк иткән кешем,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.
Барыр юлым иксез-чиксез әле,
Язмыш илтеп куяр кай якка?
Кайтыр юлда бәхет гөле булсаң,
Мин яшәргә тиеш шул хакка.

## СЫЗЛАНУ ҺӘМ ЮАНУ

Шатлык килде —
Бар дусларга
Уртак булдем;
Кайгы килде —
Алар качты,
Ялгыз идем.

Бәхет кунды —
Барысына
Тигез булдем.
Сагыш кунды —
Мин һаман да
Ялгыз идем.

Газапларны
Учларымда
Ялгыз сыктым.
Мин берүзем
Тирән юллар
Сызып чыктым.

Минем белән
Бары кара
Күзләр иде.
Йөрәгенең
Җылысын ул
Миңа бирде.

## ИРКӘЛӘНЕР КӨННӘР АЛДА ӘЛЕ

Каен тәлгәшеннән моңнар тамып,
Сагыш басса, яшьләр түкмә әле!
Уртаклашыр серләр, бүленгән хис,
Аңлашасы сүзләр күпме әле!

Дуамал җил, көтмә, диеп шаулар,
Белмәс кичне, белмәс иртәне.
Ярын җуйган ялгыз аккош сыман
Ярдан ташланырга иртә әле.

Йөрәгемнең балкыр нурларында
Бүләк итәр җылы калды әле.
Миләш кызын үпкән тирәк сыман
Иркәләнер көннәр алда әле.

## БУ ҖИР ЯЛ ЙОРТЫ ТҮГЕЛ

Яшеллекнең сабый чагы,
Кая тартыла күңел?
Янса-көйсә, ашкынса да,
Күңелгә үпкәләрем юк, —
Бу җир ял йорты түгел.

Каеннарның егет чагы,
Миләш кызына карап,
Алар гашыйк булган кичтә
Яшьлегем эзләрен эзләп,
Дөбъяз ягына барам.

Алатның гүзәл тавында
Сандугач моңын тыңлап,
Олы җанлы, киң күңелле,
Иң акыллы кызы белән
Таңнарда йөрдек җырлап.

Гел безне генә яктыртып,
Йолдыз нур сипте күктән.
Иреннәр иренгә тигәч,
Усак егете, көнләшеп,
Тал кызын кат-кат үпкән.

Йөрәкне таш түгел, диләр,
Нечкәрде хисләр бүген.
Бәхет алып килгән кешем,
Сине уйлыйм иртән-кичен,
Ничек сагынмасын күңел, —
Бу җир ял йорты түгел.

Янып торган күзләреңне
Баксам да күрмәгәнмен.
Мине өзелеп сөйгәнеңне,
Шатланганың, көйгәнеңне
Ничек соң белмәгәнмен?

Белмәгәнмен күңелеңдә
Пакь һәм саф хисләр барын.
Яныңнан киткәч аңладым:
Күпме кайнар хисләр яткан
Изге җаныңда тагын!

Бер-беребезне бәяләргә
Бу көннәр кирәк булган.
Син басып калган юл чаты
Күз яше белән тулган.
Бер шәүлә килә юлдан...

## СИҢА БАРАМ

Моңсу гына ябалак кар ява,
Ак чәчәктәмени урамнар!
Җирдә аклык! Ә күңелне гүя
Юксынулар белән юганнар.

К у ш ы м т а:

Ага ташкын, ургый юшкын,
Упкын шавы — язлар килде.
Яр өстендә пар гашыйклар,
Мин өченче ялгыз инде,
Ә ялгызлык — язмыш инде.

Омтылышым чиксез. Сиңа барам
Ябалак кар яуган ак көндә.
Аңлап барам мине көтмәгәнен,
Каршы алмаганын беркем дә.

К у ш ы м т а.

## НИГӘ БАШНЫ САЛГА САЛЫРГА

Алсу таңда, минем язмыш булып,
Бер сандугач елый тирәктә.
Сулык-сулык сулыш алмый елый,
Ходай түзем бирсен йөрәккә.

Яшь күрсәтмә, яшьлек сандугачы,
Без сынарлык-сыгылырлык түгел.
Нигә башын салга салсын әле
Алтмыш яшьтә сөю көткән күңел?!

## МИН СИҢА ҮПКӘЛӘМИМ

Ай Зөһрәсе, айкап күкне,
Үз тиңдәшен эзли күпме!
Бирешми вак хисләргә.
Үпкәләмим барсы өчен,
Унсигез тулыр-тулмаста
Сөю алып килгән кешем
Ай калыккан кичләрдә.

Хәтереңдәме: сагыштанмы,
Яшьлектәнме, ялгыштанмы,
Яшь түгеп көткәннәрең?
Синең алда ап-ак саф юл,
Кабатланмас горурлыгым,
Тик ялгышма, бәхетле бул,
Мин сиңа үпкәләмим.

Күңелләре китек, диләр,
Өметләре өзек, диләр,
Ярларны көткәннәрнең.
Олы җанлы, киң күңелле,
Хезмәткә дәрт, яшәү көче
Бүләк иткән син түгелме?
Юк, мәңгегә үпкәләмим!

## СӨЕЛӘСЕ ИЗГЕ БЕР ҖАН КАЛДЫ

Ят кешеләр барда җаным уйный,
Таба гына алмыйм ишләрем.
...Сөеләсе изге бер җан калды,
Нишләдең син, язмыш, нишләдең?

## УНЖИДЕ ЯШЕМ

Язгы ямь белән йөрәк серләшә,
Каеннар шавы — киләчәк дәшә.
Кулда — таныклык, чәчәк бәйләме,
Бу — безнең язмыш, яшьлек бәйрәме.

Кушымта:

Нәрсәгә тиңлим унжиде яшем?
Ул — кояш нуры, ул — көчле яшен.
Ул — саф таңнары без барыр юлның,
Туачак моңы без җырлар җырның.

Күктән сокланып тулган ай карый,
Йомшак май җиле бөдрәләр тарый.
Бөдрәләр бизи сылу йөзләрне,
Зөһрә йолдыздай нурлы күзләрне.

Кушымта.

Әйләнә яшьлек ургылып хискә,
Бу — онытылмас бәхетле кичләр.
Күңелдә — шатлык, йөрәктә — көю,
Беренче хатлар, беренче сөю.

Кушымта.

## ЧИСТАРУ

Бу тормышның ыгы-зыгысына
Ис китмәде безнең,
Ис китмәде.

Хис күленең аккошлары идек,
Ни җитмәде сиңа,
Ни җитмәде?
Миндә — янар таулар кайнарлыгы,
Синдә иде ак кояшның нуры.
Икебезнең дә шашкын йөрәкләрне
Наз дулкыны юды...
Бергә яккан сөю учагында
Хәзер сүнде ялкын.
Арабызда эзен салды шомлы,
Җан өшеткеч салкын.
Дөнья гүзәл!
Аның күкләренә йолдыз итеп
Сөенечләрем атам...
Син — вакытында язмышымнан киткән
Минем иң зур хатам!

## МОГҖИЗА ИДЕҢ

Һаваларда нурлар,
Нурга коена урман,
Үләннәре билдән киң алан.
Хуш исләрен сулап чәчәкләрнең
Каерып-каерып печән мин чабам.

Кинәт пәйда булдың. Ах, син нинди
Күзне алмаслык сөйкемле,
Бар чәчәкнең матурлыгын җыйган
Гүзәллекнең үзе шикелле!

Горур гына яннан үтеп киттең,
Бер алдыңа төштем, артыңа.
Тәүге күрүдә үк тезләндергән
Утлы мәхәббәтем хакына.

Күтәрелеп хәтта карамыйсың,
Җиләк сайлавыңны беләсең:
Елмаюлы чигенү...
Ихлас хисләремнең
Ялкыннары өтте, күрәсең.

Һаваларда — нурлар,
Индә — синең куллар,
Хисләремә: Ул, дим, Ул риза!..
...Еллар аша безне яшәртә күк
Искә төшеп шушы могҗиза.

## БИРСӘНӘ ТҮЗЕМ!

Татлы төннәрдә
Киләм кулләргә.
Ялгыз сандугач үзәкне өзеп
Сайрый таңнарда,
Кунып талларга.
Сагынганнарга бирсәнә түзем!

Айның нурлары
Айкый юлларны.
Назлы кар ява, капланган эзең.
Яну да көю,
Шулдыр чын сөю.
Сөю хакына бирсәнә түзем!

Иске ай бата,
Яңасы калка.
Балкып китәр күк сагышлы йөзең.
Тагын ничә җәй,
Тагын ничә көз,
Язы, кышы бар, бирсәнә түзем!

Күкләргә карыйм,
Йолдызлар саныйм.
Ул балкышлары нәкъ синең күзең.
Таралыр сагыш,
Тарамас өмет.
Барыбер көтәм, бирсәнә түзем!

## КАР СУЫНДА ШӘЛ АГА

Кар башына кар җитә дип,
Язгы тәңкәләр ява.
Кызлар күңелен җилкетеп,
Тамчы булып моң тама.

Су ташкыны ярны ашый,
Шул моңны җырга салып.
Чишмәдә кер чайкаучы кыз
Җыр тыңлый, уйга калып.

Шатлыктан елмайган кояш
Җиргә нурларын сибә.
Кар суына пакьлек өстәп,
Бер ак шәл йөзеп килә.

Басмага баскан бер егет
Тальянын сузып-сузып
Уйнады да уйга салды
Ярдагы каен кызын.

Каен егете көнләшеп
Куйды да авыр сулап,
Язгы җил белән чайкалып,
Шәл алды бозлы судан.

Кар башына кар җитә дип,
Язгы тәңкәләр ява.
Яр буйлатып шәл артыннан
Шәм шикелле кыз чаба.

Каен егете, мутланып,
Кызга сузды ак шәлне.
Басмадагы тальян моңы
Туктап калды шул мәлне.

## ҮПКӘЛӘМӘ

Үпкәләмә, сеңлем, бер үпкәнгә —
Шагыйрьләр бит алар хисләләр.
Күрәсеңме, уймак иреннәрең
Ничек алсуланып киттеләр!..

Үпкәләмә, сеңлем, бер үпкәнгә —
Хис ялкыны булып тамдың син.
Ә ул миңа илһам өстәде дә
Һәм җырыма кереп калдың син.

## КӨЙМӘ ЧАЙКАЛА

Идел ярында дулкыннар
Шаулый, айкала.
Толымнарын җил иркәли,
Көймә чайкала.

Кушымта:

Тибрәнә көймә,
Яшьлек, дулкыннардай ярсып,
Ярларны сөймә!

Ярсу дулкын кочагында —
Чибәр язмышы.
Сагышларын моңга салып
Җырлый таң кызы.

Кушымта.

Сихри җырдан ак каеннар
Кинәт тын кала.
Чал яр упкын тоткыныннан
Таң кызын ала.

Кушымта.

Яшькә чумган серле күздә
Ай нурлары бар.
Гашыйклардан мәрхәмәтле
Хәтта җансыз яр.

Кушымта.

## ӘЙЛӘНЕП КАЙТЫГЫЗ!

Агыла тын гына,
Җыр булып моң гына,
Кемнәрдер кайларга китәләр...
Сагыштан янганнар,
Яшьләре тамганнар
Юлларда өзелеп көтәләр.

Кушымта:

Күңелдә йөргән яр,
Төшләргә кергән яр,
Кайсыбыз сагынмый, әйтегез?
Яшьлекнең таңында,
Вәгъдәләр хакына
Тизрәк әйләнеп кайтыгыз.

Парлылар бергәләп,
Йөрәкне телгәләп,
Күңелне әрнетеп үтәләр.
Олы юл чатында
Күрешү көннәрен
Ялгызлар зарыгып көтәләр.

Кушымта.

Туган җир тарта ул,
Исәннәр кайта ул,
Кавышу көннәрен беләләр.
Хәбәрсез югалган
Дусларын юллардан
Тол кызлар һаман да көтәләр.

Кушымта.

## ҖИЛ

Борылып, борылып ага кар суы...

*Халык җыры*

Тәрәзәдән керә дә җил,
Хәлемне сорый минем,
Пар канатын кага-кага,
Туган илдән сәламнәр, ди.
Мең рәхмәт, туган, димен.

Тәрәзәдән керә дә җил,
Адәм күк уйга калып,
Сызгыра «Тәскирә» көен,
Мәңге иелмәс башымны
Сагышка, моңга салып.

Моң, кар суы булып агып,
Йөрәк ярларын кагып,
Беренче хисне яңартты,
Ничек түзәргә тагын?

Мәңге истән чыкмас инде
Гомеремнең шул таңы.
Халык белеп җырлый икән:
Авыр, диеп, яннарында
Җан сөйгәннәр булмавы.

## СӨЮ КИЛГӘН КЫЗ БАЛА

Сары-сары, сап-сары
Язның гүзәл чаклары.
Алсу йөзгә сипкел төшкәч,
Сөю какты капканы.

Күңелләргә шомнар салып,
Гөрләвекләр акканы...
Сөю килгән кыз баланың
Йокы күрми ятканы.

Яралар булып уелган
Зур сөю килер-китәр...
Сары төшкән йөзләреңне
Күбәләк сыйпап үтәр.

Кыр казлары аваз салыр
Ак болыт арасыннан.
Гашыйклар көзен саргая
Мәхәббәт ярасыннан.

## МӘҢГЕЛЕК СЕР

Әкиятләрдә бөтен Алыплар да
Җиңеп чыга Гыйфрит, Диюне.
Тик берсе дә җиңә алмаган һич
Эчтә дөрләп янган Сөюне.

Кеше тормышта да акылы белән
Тезләндергән кара көчләрне.
Аңа буйсынган да ачалмаган
Тылсым көчен утлы хисләрнең.

Мәшһүр ханнар, гаярь патшалар да
Мәхәббәттән янып-көюдән
Ярты ханлык, патшалыгын биргән
Нечкә билле бөек Сөюгә...

Юк иткән дә, кеше ясаган да,
Шанлы иткән дә Ул адәмне.
Менә беркем берчак аңлатмас
Шушы сөю серен Галәмнең.

Сөю — илаһ! Бары бер тартылыш
Итеп карыйбыз без ник аңа?..
Әгәр сөюләрсез генә калса,
Зур фаҗига килер Дөньяга.

## ЯШЬЛЕГЕМ ҮТКӘН УРАМ

Бер сандугач, ярын эзләп,
Таңнарда талга кунган.
Шул гашыйкның җырын тыңлап,
Синә унҗиде тулган.
Язын безне таныштырган,
Яшьлегем үткән урам.

Бер аккош, кулларне иңләп,
Эзләнә — дустын җуйган.
Бәхетләр моңын тыңлап,
Миңа егерме тулган.
Көзен безне кавыштырган
Яшьлегем үткән урам.

Юлларны кичтем әйләнеп,
Гомерне булмый урап.
Пар сандугач сайраганда,
Үткән көннәрне уйлап,
Истән чыкмый вәгъдәм калган,
Яшьлегем үткән урам.

## АККОШ БЕЛӘН СЕРЛӘШҮ

Язгы таңда күңелемдә калды
Ялгыз очкан аккош тавышы.
Аккош мине яшьлегемә илтте,
Уртак, диде, йөрәк сагышы.

Кушымта:

Аккош өмет өзми,
Яшьлек ярын эзли.
Олы хисләр уртак түгелме?
Син дә — ялгыз аккош,
Мин дә — ялгыз аккош,
Кем юатыр безнең күңелне?

Белми идем әле аккошларның
Мәхәббәттән дөрләп янганын.
Керсез дустын, саф бәхетен эзләп,
Керфегеннән яшьләр тамганын.

Кушымта.

Синең җанда аккош каны бар, дип,
Җавап бирде ялгыз аккошым.
Сагышларың түгел, ялгышларың —
Теләп алган ачы язмышың.

Кушымта:

Аккош өмет өзми,
Яшьлек ярын эзли.
Олы хисләр уртак түгелме?
Ялгышыммы, аккош,
Язмышыммы, аккош,
Юат җанны, юат күңелне!

## МОҢСЫЗ КАЛСАМ

Бу тормышның күпме авырлыгын
Иңнәремә салып яшәдем.
Шуңадыр ул җиңел чакта чыга,
Авыр чакта чыкмый яшьләрем.

Сабыр төбе — сары алтын, диеп
Өйрәттеләр мине олылар.
Сабырлыкта бары шомнар гына,
Кыенлыкның аның моңы бар.

Шуңа күрә кыенлыксыз гына
Яши алмыймдыр мин бу җирдә.
Кечкенәдән моң баласы идем,
Моңсыз калсам, кирәк мин кемгә?

## НИЧЕК АҢЛАРГА?

Бу күзләрең мине эзләп тапты,
Бу иреннәр мине үптеләр.
Шушы күзләр, шул ук иреннәрең
Яшьлегемнән мәхрүм иттеләр.

Бу кулларың, хисләреңә манып,
Йөздерделәр татлы дулкында.
Аннан күпме төшереп, күпме алды
Тормыш төбендәге упкыннан.

Бу йөрәгең, ялкынына урап,
Ничә үтереп, ничә терелтте.
Иреннәрең кабат үптеләр дә,
Берни булмагандай үз иттең.

Бу сынавың нигә кирәк булды?
Дөнья мине изде болай да...
Хатын-кызны ничек аңларга соң? —
Моңа җавап бары Ходайда.

## ТИҢЛӘДЕМ

Кич булып йолдызлар калкуга,
Безгә тиң пар йолдыз эзләдем.
Салават күпере балкышын,
Таллыкта сайраган таң кошын,
Чылтырап агышын чишмәнең
Мин безнең сагынуга тиңләдем.

## СИХРИ КӨЧ

Әкрен генә йөзе төссезләнә...
Яшәү белән йөрәк алыша.
Йөрәк, туктыймын, ди... Яшәү исә,
Ул яшәсен, диеп тартыша.

Күзләреннән нурлар китеп бара,
Ә аларда күпме әрнеш, моң!
Яшәү әйди тормыш кырларына,
Йөрәк карыша: аңа инде соң.

Табиблар да, бар да аптырауда:
Авыруга башка юк дәва...
Чү, нәрсә бу? Кинәт ишек ачыла,
Палатага тоташ нур ява.

Фәрештәдәй яныма килеп бастың,
Аh, Синдә ул нинди гүзәллек!
Сиздермичә сүнеп барган җанга
Кабат гомер булып күчәрлек.

Буйсынды да йөрәк гүзәллеккә,
Яшәү, кабынып итте тантана.
...Их, хатын-кыз! Авырлыкны җиңү
Сезне яратудан башлана.

## БЕЗНЕҢ ЯШЬЛЕК НИДӘН БАШЛАНДЫ?

Безнең яшьлек нидән башланды?
Ирләр утка кергән дәвердән.
Ятимнәргә назлы җылы биргән
Әнкәемнең мамык шәленнән.
Бәлкем, башлангандыр әткәй булып
Колхоз кырын сөргән таңнардан.
Унҗидедә чишмә буйларында
Сөю бүләк иткән язлардан.

Бәлкем, башлангандыр чик буенда
Илгә биргән антны үтәүдән.
Безнең яшьлек, утны-суны кичеп,
Татарстан данын күтәргән.
Безнең яшьлек әле үтелмәгән,
Үтеләчәк авыр юлга тиң.
Безнең яшьлек әле язылмаган,
Җырланачак моңлы җырга тиң.

## МАЙ АЕНДА КАР ЯВА

Шомыртлар ап-ак чәчәктә,
Ай күлгә төшкән, яна.
Карлы суда ялгыз басма
Айкала да чайкала.

Кушымта:

Йөз елга бер генә тапкыр,
Бер генә тапкыр
Май аенда кар ява.
Нигә һәр көн сызлый икән
Сөю китергән яра?

Сандугачның моңын эзлим,
Тынлыкта миңа пар ул.
Икәү йөрсәң — бәхет төсе,
Ялгызга — гади кар ул.

Кушымта.

Айкалган-чайкалган дөнья,
Үзәннәр толымы мин?
Басмада ялгыз тирбәлгән
Мәхәббәт колымы мин?

Кушымта.

## МИНЕМ ӨЧЕН СИН ГЕНӘ

Җир йөзендә үскән чәчәкләрнең
Иң матуры була бер генә.
Күз нурларым алган гүзәллекнең
Икенчесе бары син генә.

Күз нурларым алган гүзәллекнең
Икенчесе бары син генә.

Күк йөзендә янган йолдызларның
Иң нурлысы була бер генә.
Таң йолдызы кебек юлларыма
Яшәү яме сипкән син генә.

Күңелнең саф, пакьлеген өстәп,
Яшәү тәме биргән син генә.

## СИНЕҢ КҮЗЛӘРЕҢ

Язгы таң кояшы балкыгач,
Безгә тиң пар чәчәк эзләдем.
Нурланып ачылган бөрене
Мин синең күзләргә тиңләдем.
Шул нурга төренгән
Сихерле чәчәкләр —
Әйтерсең ул синең күзләрең!
Әйтерсең ул синең күзләрең!

Кич җитеп йолдызлар калыккач,
Безгә тиң пар йолдыз эзләдем.
Күктәге һәр йолдыз балкышын
Мин синең күзләргә тиңләдем.
Шул моңга төренгән
Тылсымлы йолдызлар —
Әйтерсең ул синең күзләрең!
Әйтерсең ул синең күзләрең!

## БЕР ШАГЫЙРЬГӘ ИЯРЕП

Ачуланма, минем хакта
Җыр чыгармый, дип, сөеп.
Җырларсыз да мөмкин икән
Яшәргә янып-көеп.

Яшерен сөю ул — горурлык,
Ул — егетлек, ул — түзем.
Җырлар да йөрәктән чыгалар,
Йөрәгем бит — син үзең.

## КҮЗЛӘРЕМНӘН КИЛЕП КАРА

Истән чыкмый Болак буе,
Икәүләп үткән сукмак.
Гөрләвекләр җырын тыңлап
Йөрим ярлары буйлап.

*Кушымта:*

Күзләремнән килеп кара:
Ямансулык, әй моңсулык.
Күл өстендә мин — акчарлак,
Ялгыз очам нәүмиз булып.

Сулар ташый, карлар ашый,
Боз эри, сөю түгел.
Киткән кадәр китсәң әгәр,
«Кайтыр» дип алдый күңел.

*Кушымта.*

Йөрәгемдә калган юлчым,
Чуалтмың йомгак очын.
Юатырсың, елатырсың —
Күрешик, зинһар өчен.

Кушымта.

## СЕРЛЕ ЙОЛДЫЗ — АЛИЯ

Гөлстанда чибәрләр күп,
Кемнәр янымнан үтми;
Татар кызының карашы
Күз алларымнан китми.

Кушымта:

Серле йолдыз — Алия!
Мин түгел, алсу йөзеңә
Ай, кояш та баш ия.

Каршыбызда — гөл-чәчәкләр,
Бульварларда — гүзәллек.
Гүзәллекләрдән гүзәл син,
Белмим, ничек түзәрмен?

Кушымта.

Ул сүзләрең — тарту көче,
Елмаюың нур өсти.
Матурлар күп бакчаларда —
Татар кызына җитми.

Кушымта.

## МИШӘР КЫЗЫ

Сихерле карашың белән
Йөрәгемә ут салдың.
Серле карап, бер елмаеп,
Йөрәктә урын алдың.

Кушымта:

Мишәр кызы чая телле,
Үзе шундый сөйкемле.
Эх, егетләр, сак булыгыз!
Исән калу икеле...

Күз карашы туры карый,
Йөрәкләрне үтәли...
Сөю уты кабындырып,
Бәгырьләрне телгәли.

Кушымта.

Нечкә билле, очкын күзле,
Иреннең иң татлысы.
Кызларның да иң уңганы,
Татарның иң затлысы.

Кушымта.

Сөйсә дә, ул, сөям, димәс,
Сөймәсә якын килмәс.
Яндырыр, көлгә калдырыр,
Башкага сине бирмәс.

Кушымта.

## КЛАРА

Гөлләрнең, ай, гүзәл төрләре күп,
Сиңа тиңдәше бар, ул — яран.
Йөрәк яраларын кат-кат бәйләп,
Яшәү дәрте биргән Кларам.

К у ш ы м т а:

Рәхмәт инде сөйгән-көйгән өчен,
Кара кашлы, нурлы кара күз.
Күпне күрдең инде, түздең инде,
Калган елларда да нык бул, түз.

Язгы кичтә яңа чыккан аем,
Күккә карап, йолдыз юл яра.
Шул юллардан айкап-чайкамыйча,
Мине әйдәп килгән Клара.

К у ш ы м т а.

Читкә китсәм, җанга кемдер җитми,
Җитми бердәнберем — Кларам.
Йөзләгән җыр язып, кичер мине,
Сиңа багышланган җыр калган.

К у ш ы м т а.

## СУЛАР ҮРГӘ АКМЫЙ, ДИЛӘР

Сулар үргә акмый, диләр,
Минем яшьлеккә ага.
Беренче сөю китергән
Чишмә юлына таба.

Басмада — көянтә, чиләк,
Көтеп калган кыз бала.
Йөрәк түрендә янар хис
Үрдән тауларга ага...

Сулар үргә акмый, диләр,
Күңелдә ага икән.
Сагынып арган күзләре
Сүнә дә яна микән?


Сулар үргә акмый, диләр,
Үрләрдә күлләр бар бит.
Син минем йөзек кашымда
Уелып калган яр бит.

## КАЙТЫР ИДЕМ

Кайтыр идем туган авылыма,
Күрер идем моңсу ярларын.
Аланында сузылып, сузылып, кырын ятып
Тыңлар идем камыш шауларын.

Чылтырап аккан чишмәләрнең җырын
Тыңлар идем, басып ташына.
Кайтыр идем, туган авылым, сиңа,
Кайтыр өчен йөрәк ашкына.

Кайтыр идем туган авылыма,
Буйлар идем елга буйларын.
Бик сагындым, авылым, туган авылым, сине,
Сиңа кайта һаман уйларым.



# Җырлы мәдхиягә лаеклылар

Казан безне майлы кашык биреп,
Ботка тотып каршы алмады...
Ләкин көтте шигырь Иделенең
Җыр дулкыны тулы ярлары.

## ЭЗЛИМ

(Әнием Шакир кызы Нәфисәгә багышлыйм)

Ничә еллар менә эзләп йөрим,
Ялгызак каз сыман каңгырап.
Күңел тавышым җирдә, һаваларда,
Йолдызларда китә яңгырап.

Эзлим сине инеш буйларыннан,
Чишмәдәге аккан сулардан,
Син арышын урган басулардан,
Йөрәк маең тамган кырлардан.

Туган нигеземнән эзлим сине —
Син калдырып киткән язында.
Син язлардан да бит якты идең
Һәм җылырак идең тагын да.

Күпме мәдхияләр язылса да,
Аз әйтелгән синең хакында.
Никадәр син кирәк тормышымның
Һәрбер борылышы чатында!

Аһ, нәрсә ул каурый болытлардан
Миңа таба карый иелеп?..
Рәхмәт, әни!
Мин әнә шул җылы карашыңны
Ничә еллар эзлим тилмереп.

## ГӨБЕРЧӘКНЕ МОҢСУ ТОМАН БАСКАН

(Мөхәммәт Мәһдиевкә)

Казанбашта камыш шавы тынган,
Шаулап аккан суы саеккан.
Кояш, никтер, ул көн иртә чыгып,
Алсу таң атканда баеган.
Гөберчәкне моңсу томан баскан,
Бер сандугач җылый бакчада.
Мөхәммәтнең җаны тавыш бирә:
«Эзләүчеләр булса башкалада —
Мин оҗмахта, дуслар, Арчада!
Туган якта музей салып ятам,
Шомырт чәчәк аткан бакчада!»

## КҮККӘ ЮЛЛАНГАН УЙЛАР

(Хуҗаәхмәт һәм Рәшит абыйларыма бер дога)

Кайвакытта, җанны учка кысып,
Күккә карап алган көннәр бар.
Йөрәгемне сызлаттың да киттең,
Ул дөньяда, абый, ниләр бар?

Бармы анда җиде җәннәтләре,
Хур кызлары тиңсез сөйкемле,
Уты кайнап торган тәмуглары —
Монда безнең тормыш шикелле?

Юктыр, димен, анда кан коюлар,
Мәкер, явызлыклар, хыянәт.
Җирдә генә бит ул күзгә карап
Эшләнелә күпме җинаять.

Сездә кәеф кору тыелгандыр,
Тәңребезнең кулы катыдыр!
Дөньялыкта әле гел искечә:
Кубесендә иман — «ярты»дыр.

Хокукларда сезне кысмыйлардыр,
Барыгыз да анда тигездер.
Синең чактагы күк, биредә һаман
Ялган белән хокук игездер.

Кайчагында, җанны учка кысып,
Күккә карап алган көннәр бар.
Киек Каз Юлының йолдызыннан:
«Уең дөрес!» — дигән өннәр бар.

## ЭНЕКӘШ

(Энем Илсурга)

Хәсрәтләрне бушатырга теләп,
Йөрәк таләп итсә бер сердәш,
Өшеп калган җанны җылытырга
Ярый син бар әле, энекәш.

Башларыма уй-кайгылар төшсә,
Сорап киләм сиңа бер киңәш.
Дөрләп-гөрләп сөйләшерлек кеше,
Ярый әле син бар, энекәш.

Чал чәчләре аның әткәйдәндер,
Нурлы йөзе — әнкәй, мәңге яшь.
Затлы нәселемнең дәвамы бул,
Бердәнберем, төпчек энекәш.

## КАЙТЫЙК ӘЛЕ!

(Якташым шагыйрь Роберт Әхмәтҗанга
Г.Тукай бүләге бирелү уңаеннан)

Яншык — Арыш[1] — икесе куш дөнья,
Арада тик Мирәт тау гына.
Шушы изге таудан килеп төштек
Дәшеп торган тормыш шавына.

Казан безне майлы кашык биреп,
Ботка тотып каршы алмады...
Ләкин көтте шигырь Иделенең
Җыр дулкыны тулы ярлары.

И яктырды аның киңлекләре!
Төшсә, энә эзләп табарлык.
Әмма никтер моңа ваклык белән
Түли килде мәнсез татарлык.

Соң булса да, уң булсын дигәндәй
Таныдылар шигъри Кыяны.
Танымый калу мөмкин түгел иде
Прометеен җырлы Дөньяның...

Язлар белән
Кайтыйк әле Мирәт буйларына,
Яшьлекне дә бер яд итәрбез.
Чал Мирәттә каен кызын кочып,
Сөю җыры язып китәрбез.

---

[1] *Иске Арыш* — Р.Әхмәтҗан, *Яншык* — М.Шиһапов туган авыллар.

## САГЫНДЫМ

(Республиканың халык артисты
Ләлә Миңнуллинага 50 яшь тулу уңае белән)

Сәнгать туфрагыннан калкып чыккан
Умырзая идең, акыллым;
Сәхнә өчен үскән зифа гәүдәң,
Янар күзләр, тапкыр сүзләреңне,
Сихри моңнарыңны сагындым.
Ирләр булып түгел, кеше булып
Талантыңа кат-кат табындым;
«Галимә»нең  моңсу тавышларын,
«Мөнәвәрә» ханым сагышларын,
«Туй күлмәге» җырын сагындым.
Кара толымнардан төшкә керен,
Йөрәк кылларыма кагылдың.
Синең йөздә бөек Волжская,
Камская, Ильская кебек
Сәхнә йолдызларын сагындым.

## ЯКЫН ДУС ТА...

(Укытучы-шагыйрь Мостафа Ногманга)

Еллар аша матур хатирәләр
Бүген мине монда китерде.
Яшьлек Мәккәбезнең залларында
Кабат Сине искә төшердем.

Белем кыясына менгән чакта
Булдың безгә
Якын дус та, ныклы терәк тә.
Мәгърифәтнең нурлы дәрьясыннан
Нурлар салдың даулы йөрәккә.

Урыслаштырыла барган милләтеңнең
Килешмәүчән зары идең Син.
Факультетның каны гына түгел,
Студентлар җаны идең Син.

Әдәбият дигән зур дөньяга
Бездә янар хисләр кузгаттың.
Туган телнең фәрештәсе идең,
Пәйгамбәре безнең иҗатның.

Университет диварлары...
Еллар аша биредә тагын күпме
Матур хатирәләр калыкты.
Халкыбызның Синдәй егетләре
Җырлы мәдхиягә лаеклы.

## ГҮЯ ҮЗЕҢ БУЛЫП...

(Авылдашым Каюм
Мөхәммәтҗанов ядкаре)

Синең хакта якты хатирәләр
Нигезеңә кабат китерде.
Бакчаңдагы нарат шавын тыңлыйм,
Җыр тыңлаган бала шикелле.

Ул шаулардан гүя ишетелә
Малай чакның еллар агышы.
Таң калдырып, безгә әкият сөйләп,
Җанны тылсымлаган тавышың.

Сихерләде »Камыр батыр»ларың,
Ә «Алпамша»ң әсир иттерде.
Һәр әкиятең күңел түрләренә
Мәгърифәтнең нурын җиткерде.

Их, саега милли мирасларны
Алмашка тапшыру йоласы.
Юктыр бүген безнең арабызда
Аның синдәй Хозыр Ильясы.
Төсең булып калган наратларың
Янына киләм, кайткач илләргә.
Алар миңа гүя үзең булып
Әкият сөйли сыман җилләрдә.

* * *

(Илдар Юзеевкә
дусларча шаярту)

Язучыдан бөеклеккә
Менәргә төрле юл бар.
Еникинең[1] йөрешләрен
Подражать итә Илдар.
Башың түбән салып йөрмә,
Алга тарт Пегас йөген.
Бөеклегең һич кенә дә
Әмирханнан ким түгел.

## ҖЫР ПӘЙГАМБӘРЕ

(Мәрхүм җырчыбыз Сөләйман Йосыповка)

Тавыш өләшкән чагында
Иң алдан килдең мәллә,
«Иң затлысын җәлләмичә
Бирегез!» дидең мәллә?

---

[1] Халык язучысы Әмирхан Еники.

Күп тавышлар арасында
Синеке — бигрәк көчле:
«Җиз кыңгырау»[1] моңы аккан
Язгы бер ташу төсле.

Шаляпинга тиңләр идек
Һич тә шаярмый-көлми,
Шаляпин бит тезеп-тезеп,
Сөләйман күк үзәкне өзеп,
Татарча җырлый белми.

Ничек инде котламыйсың
Шундый күркәм бәйрәмне,
Җаныбызны дәвалаган
Сөләйман пәйгамбәрне!

## «ӘТИ» ҮЛДЕ

Тинчуринда[2] олы кайгы,
Артисларны хәсрәт уты яшькә күмде.
Җеназага асылынып, әй җылыйлар —
Әбүл[3] үлде — әти үлде, әти үлде!
Ә Камалда[4] табут ята,
Ә табутта Алып ята.

---

[1] «Җиз кыңгырау моңнары» җырын беренче башкаручы.
[2] Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры.
[3] Әбүл Мәметов — К.Тинчурин исемендәге театрның элеккеге директоры.
[4] Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

Мәңге үлмәс һәм сүрелмәс —
Гүргә кергән!
Ярларыннан ташый-ташый Кабан ургый,
Ятим калдык — әти үлгән, әти үлгән!
Матәм көен көйли-көйли халык барды,
Халык белән Сөю барды, Нәфрәт барды.
Кисекбашның башын кискән юл чатында
Үкси-үкси артискалар елап калды.

* * *

(Ләбиб Леронга)

Күп пародия яздың,
Син, туган, тәмам аздың.
Атказанган исемне дә
Чират тормыйча алдың.

* * *

Җир астыннан юллар булмас,
Исән чакта күрешик.

*Җырчы Зөфәр Билалов репертуарыннан*

Ашкынмагыз, күрешерсез,
Вакыт бит болай да бар.
Нишләп юллар ябык булсын,
Җир астында метро бар.

Инде оҗмахка эләксәң,
Хур кызлары муеннан.
Ә тәмугта йөреп була
Канализация юлыннан.

* * *

(Роберт Әхмәтҗановка дусларча шаяру)

Тормыш көймәсен гомергә
Упкынга каршы иштек.
Том артыннан том чыгарып,
Медальсез калдык, нишлик ?

Олуг шагыйрь, бөек шәхес,
Пушкинга тиң, диделәр,
Әмма ләкин нишлисең?
Лаекларга зур бүләкне
Партия беткәч бирделәр.

## МАГНАТ

(Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе
Зиннур Хөснияргa)

Гәҗит-журналлар магнаты —
Зиннур Хөснияр.
«Таһир—Зөһрә»се дәрт кабызды —
Таптык сөйгән яр.
Ә аннан соң
«Яучы» аша бар яшьләрне
Кавыштырды.
Ялгыз апаларга, сеңелләргә
Бәхетләрен табыштырды.
Таныштырды
Сакал җиткән абзыйларны.

Әнә хәзер, кара ничек:
«Салават күпере» — милли бишек,
Тәрбия кыла сабыйларны!..
«Сәхнә» аша күзәтәбез
Артистларның тормышын...
Долларга җырлаганы бай,
Күбесенең кесәсе сай.
Каһәрләп җырлап йөриләр
Тормышының ормышын.

* * *

(Татарстанның халык артисты
Нуретдин Нәҗмигә)

«Отелло»ны уйныйм диеп,
Скандал чыгарган Нәҗми.
Буең җитмәгәнгә, Нәҗми,
Хыялланма, «чёрт возьми»!

* * *

(Татарстанның халык артисткасы
Наилә Гәрәевага)

Театрда уйнамаган
Образларың сирәк инде.
Җыен куштан, ялагайның
Борыннарына чиертү
Күптән инде кирәк иде!

## ТИҢЛӘРМЕН

(Гөлнарага)

Дөньяның читендә дисәләр,
Елларны, юлларны иңләрмен.
Елларның иң авыр көннәрен,
Сагышлы, газаплы төннәрен
Кавышу язына тиңләрмен.
Салават күперен күзәтеп,
Юлларда теләкләр теләрмен.
Бәхетем төсләрен тараткан
Дуамал җылысын җилләрнең
Мин синең сулышка тиңләрмен.
Рәнҗеше төшкәндер кемнәрнең:
Бер таңда чәчәген өзделәр
Без парлап утырткан гөлләрнең.
Тамыры сулмаган гөл кебек,
Кояшым, мин сиңа үрләрмен.

## ИСЕМЕҢ КАЛДЫ

(Мәрдән Рәшитенә)

Кешеләр арасында кушаматың
Ямьсез иде: «Сугыш чукмары».
Кушкан чакта кемдер аңламаган
Йөрәгеңдә янган утларны.

Утларыңның дөрләткече иде
Гаделсезлек, заман тарлыгы.
Кайбер мәнсез, усал бәндәләрнең,
Ул хәерче, дигән «ярлыгы».

Сәбәпсезгә төшкән җәберләрне
Чиста җаның авыр күтәрде.
Шуңа күрә кайчак көрәк кулың
«Деңгә» кертә иде күпләрне.

Кыш. Саламга диеп киткән җирдән
Бураннарда калып уралдым.
Яшәргә дип туып, яшәвемә
Булган бөтен өмет югалды.

Ул син идең ачы бураннарда
Кырда мине эзләп табучы.
Туктый барган нәни йөрәгемә
Яшәү чаткылары салучы.

Бер күлмәктән калып, бишмәтеңә
Бик тиз төреп салдың чанага.
Кайнар тының өреп җылыта-җылыта,
Күзләремне ачтың дөньяга.

Матур күңелең игелекле иде,
Ул һәрвакыт иде хаклыкта.
Кушаматың күптән онытылды,
Менә исемең
Һаман әле йөри халыкта.

## ГОМЕР ШАВЫ

(Авылдашларым Гыйльман абый һәм
Нәйрә апага багышлана)

Аждаһадай үкереп ташу төште,
Ярсып кушылды ул инешкә.
Алып китте авыл күперен дә
Син ашыгып кайтып килешкә.

Ике ярда калды бер үк сөю:
Синең якта — сагыш, омтылу.
Каршы якта — наз сирпегән күзләр,
Өзелеп көтү, сагыну, юксыну!

Ә арада бозлар каерыла,
Шаулап ага офык ягына.
Бергә типкән ике яшь йөрәкне
Ничек әле бозлар аера?

Инеш ургып, кайнап күтәрелә,
Сыймас кебек иркен киң ярга...
Кеше бөтен каршылыкны җиңә
Саф күңелдә утлы хис барда!

Аргы яктан бау аттылар... Тотынып
Чыктың боздан бозга сикереп.
Ерак чакрымнарны якынайткан
Мәхәббәтне илаһ иттереп...

Гомерегез күзләреннән күзлим:
Сез һаман да әле
Икегез корган хисле дөньяда.

Берегез анда гүя чал бер кыя,
Икенчегез —
Ак күгәрчен шушы кыяда.

Һәр ел саен язлар килә тора,
Яшьлек күкрәүләрен яшьнәтеп.
Һәм һәр елны ташу төшә тора,
Сезнең мәхәббәтне яшәртеп.

* * *

(Фәрит Бикчәнтәевкә)

Әтиең — талант, әниең — канат,
Затлы нәселдән.
Баш режиссер буласыңны
Аһ, кем соң белгән?!
Марсель[1] белән Туфан[2] кебек
Иңгә-иң барып,
Һич яныңнан китмәс идем
Пьесалар язып.

* * *

(Күренекле артисткабыз Дания Нурлыга)

Зур сәхнәдә янар йолдыз —
Дания Нурлы.
«Һаман кызларны уйныйсың,
Ничә яшь булды?» — дигәч,
Дорфа җавап бирде:
— Унсигез тулды...

---

[1] *Марсель Сәлимҗанов* — режиссер.
[2] *Туфан Миңнуллин* — драматург.

* * *

(Татарстанның һәм Россиянең
халык артисткасы Нәҗибә Ихсановага)

Т. Мин[1] белән гөрләп яшә,
Әлмәндәр[2] килене бул.
Сабыр төбе — сары алтын,
Шуңа бөеккә әйләнгән
Илаһи Нәҗибә ул.

Сәхнәдә йөгереп йөр дә,
Яшең әбинеке булсын,
Шпагат ясап кара[3].
«Мәйсәрә»не уйнар идем,
Эх, гомер алга чаба.
Пенсиягә китәргәме,
Белергә вакыт-чама.

* * *

(Күп еллар Язучылар берлегенең әдәби фонд директоры булып эшләгән язучы Лерон Хәмидуллинга)

Әдәбият дөньясында
Пәйгамбәр Лерон Хәйдәр.
Тукай сүзе белән әйтсәк,
Әдәби фонд әгъзаларын
Яктыга, нурга әйдәр.

---

[1] *Т.Мин* — Туфан Миңнуллин.
[2] *Әлмәндәр* — «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле герое.
[3] *Шпагат ясап кара* — «Гөргери кияүләре» спектакленнән.

## ИРЛӘРГӘ ТИҢ ПАКЬ ХАНЫМНАР

(Сугыш юлын үткән артистка Бикә Шәкүровага)

Мәйданнардан тарих үтә:
Ветераннар саф-саф атлый,
Җиңелмәс юл хатирәсе —
Алтын йолдыз нурда балкый.
Горур атлый ир батырлар.

Батырларга тиң ханымнар;
Утта калып та янмыйча,
Илгә кайткан пакь хатыннар,
Ирләргә тиң тол ханымнар.
Егермеләп миллион чәчәк...
Ятып калган изге җаннар
Мәңгелек ут булып яна.
Тарих уты — ветераннар:
Исәннәре үксеп елый,
Ела-җырла! Әй, хакың бар.
Мең дә дүрт йөз унсигез көн[1],
Мең дә дүрт йөз унсигез төн
Яшь түкмәгән пакь ханымнар.
Сиксән алты[2] герой кызны
Мәскәү — Берлин юлы бирде.
Ун меңләбе зурлап үлде
Җан иңдергән туган илне.

---

[1] Бөек Ватан сугышы барлыгы 1418 көн барды.
[2] Сугышта 86 хатын-кыз Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды.

Каннарында — яшьлек дәрте,
Их, килгәндер сөеләсе...
Алсу ирен тәмен татып,
Бер янасы-көенәсе,
Иркәләнеп бер үбәсе...

## ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ

Хәсән Туфан булмадым,
Кабул итегез булганын...
Зато утыз ел яңгырый
Минем язган җырларым!



# Дөнья
# күләп
# тора

Шаулый базар, гөрли базар,
Елмая алыпсатар.
Алдау кәсебе үзләштерә
Монда «яңа татар».

## БУРЫЧ

Тормыш булгач, сүз юк, бер-берсеннән
Кеше ала, бирә бурычны.
Ләкин менә нәрсә өчен икән
Без гел илебезгә бурычлы?

Киң кырларда тозлы тир түгәбез,
Ватан өчен икмәк игәбез.
Юк-бар эш хакыннан күпме салым
Ул яшәсен диеп бирәбез.

Яклыйбыз да аны, саклыйбыз да,
Эретәбез тимер-корычны...
Амбарына безнең байлык тулган,
Ә без һаман аңа бурычлы.

«Ил алдында бурычыңны үтә!» —
Шушы иске җырны яңартып
Яшь кеше бар тапканын бүлешеп,
Казна кесәләрен кабартып...

Җилләр миңа нигә усал карый,
Ошамыймы фикер сөрешем?
Бүген менә илгә соңгы «бурыч» —
Үлем белән түләп килешем.

## ТУРЫ СҮЗ

Авыл халкы тикшерүчән
Энәсеннән җебенә.
Бу арада сөйләмидер
Хәбирәне кем генә.

Хатын-кызлар пышылдаша:
— Ни булды икән аңа,
Өченче елы кияүдә,
Тапмый гына бит бала!

Усал теллесе өсти,
Туры китереп сүз җаен:
— Беренчесен табар иде,
Кысырдыр ул, мөгаен!

Очрашканда сорадылар
Шушы хакта үзеннән.
Әйтте:
— Мондый тормышка үзем
Ник туганга үкенәм!

## ЯРСУ ҺӘМ АЙНУ

— Аерылам! — диде Гатаулла, —
Ничек инде болай яшәп була?
Бер йөз грамм кәксәм — чәрелдисең,
Артык китсә, куркып дерелдисең.
Төчкерсәм дә — яфрак төсле калтырыйсың,
Көлсәм — диванадай аптырыйсың.

Ачуланасың да, кичләр үтә ямьсез,
Ашың була тәмсез, үзең гамьсез.
Ничек инде булсын болай яшәп?
Миңа башка — ипле хатын хаҗәт!..
Әйтте хатыны: — Аерыл, Гатаулла,
Синсез дә бик әйбәт яшәп була.
Тик шуны бел:
Беренче яр — түшәк, гаиләң ак кояшы,
Икенчесе — хәсрәтеңнең килер башы!

—...Да-а, шулай шул, — диде Гатаулла.

## БӘХӘС

Күңел кинәт әрнеп ярсыды да
Охшап калып калай әтәчкә,
Сул як иңемдәге фәрештә белән
Кереп алдым кайнар бәхәскә.

— Син нәрсә, — дим, — ялгыш абынсам да,
Гөнаһ итеп язып куясың?!
Кемдер аркасында абындым ич,
Кеше языгын миңа җыясың.

Түрәләре пычрак кулы белән
Казна кесәсенә тыгыла,
Күреп дәшми калсам, гөнаһ диеп,
Минем дәфтәремә языла.

Алар урлый бит! Ә мин түгел!
Тик бары
Күрмәмешкә генә салышам.

Юк, изге җан, хаксыз кыланасың,
Болай барса,
Бугазыңа инде ябышам!..
Фәрештәнең һич тә исе китми,
Минем белән сүздә алышта.
Ак эт бәласе, ди, кара эткә,
Шулай түгелмени тормышта?!

...Заман капкасыннан карап торам,
Мәхшәр күзле адәм баласын.
Фәрештәне сатып алган заман
Ничек кешене сатып алмасын!

## БҮРЕК БЕЛӘН ТУФЛИ

Бүрек белән туфли очраштылар,
Бер-берсенең хәлен сораштылар.
— Бигрәк ялтырыйсың, — диде бүрек,—
Исем китеп торам сине күреп.

— Ялтырыйм шул! — диде аңа туфли, —
Хуҗам минем бик бай, чөнки түрә!
Куштаннары сөртеп кенә тора,
Ялагайлар исә ришвәт бирә.

Кая йөгерә иде әле бая,
Ике колакчының синең кая?

— Ә минеке ярлы, — диде бүрек, —
Эчеп, баш төзәтеп көнен күрә.
Колакчыннар? Аларны мин сатып,
Бурычын түләп кайтып киләм менә.

## БӘЙРӘМ

Чирмеш Иван дус бар иде
Мари авылында.
Утырырга туры килде
Бик еш табынында.

Бу якта халык кунакчыл,
Хет көн саен әйлән.
Мәҗүсилек гадәтенчә
Атна саен бәйрәм:

Яфрак коелу бәйрәме,
Бәйрәм — беренче кар.
Табигатьтә күп күренешнең
Үзенең бәйрәме бар...

Иван дустым белән икәү
«Җиффәрәбез» генә.
Алдыбызда куз яшедәй
Көмешкәсе көлә.

Ай буена салмыш йөрим,
Иван — еллар буе.
Чөнки авылда гөр итә
Бәйрәмнәрнең «туе».

Житәр, дидем, бервакытны
(Мине көчсез димә!),
Туктаттым бу сәрхушлекне —
Яшисе бит килә!

Ә ул һәрбер бәйрәм саен
Дәвам итте шулай.

Һәр кеше дә гомер сөрә
Үзенә ничек кулай.

Тәңре акыл шәрифләрен
Кемгә күпме язган...
Иван күптән ахирәттә,
Ә мин җырлар язам.

## ӘБИ БЕЛӘН БЕР КЫЗ ДИАЛОГЫ

Көч-хәл атлап,
Яулыгының
Чите белән
Битен каплап,
Очраганнан
Саулык сорап,
Әдәп саклап,
Юлдан бара
Түбән очның
Хөппи карчык.
«Саумы, әбкәм!
Сүзең бүләм»,—
Дип, каршымда
Нидер сөйли
Ярсып-ярсып
Югары очның
Сары Гөләм.
Үзе чибәр,
Үзе зәһәр.
Чәчләр җирән...
Бигрәк күркәм.
Ул күлмәкләр!..
Ул күкрәкләр!..
Ул башында
Заграничный,
Гармоничный,
Кабартмадай
Сары берет.
Ул күзләре!
Елан кебек
Боргаланып,
Урам иңләп
Йөрешләре
Үзләре бер
Авторитет.
Хөппи карчык
Шаярткалап,
Мавыктыргыч
Сүз аткалап,
Күңел кылларын
Тарткалап
Сорау бирде:
«Чемодан да
Кулларыңда,

Кияү дигән
Афәтеңә
Әллә, бәбкәм,
Китү мәллә?»
«Аңа түгел,
Икенчегә.
Интеллигент
Гарык итте,
Ягъни барам
Игенчегә.
Китәм, әбкәм,
Китәм инде.
Борыч Гайфи
Хатынынннан
Аерылгач,
Яучы килде.
«Чемоданың
Бик бәләкәй»,—
Диде карчык.
«Заманы шул,
Бу заманда
Бирмәсен дә
Ходай артык,—
Диде Гөләм,
Тәмам ярсып.—
Мескенкәйләр,
Бичаралар,
Сезнең заман,
Әйтер идем,
Ник булдыгыз
Шулай надан?
Төягәнсез
Түшәк, ястык,
Чүпрәк-чапрак,
Чана тартып,
(Ха-ха-ха-ха)
Көлеп үләмгә
Тау кадәр мал
Җый да, имеш,
Кияүгә бар».
«Алай, — диде
Хөппи карчык, —
Безнең заман
Кызым, олан,
Булса да тормыш
Бик яман,
Бирнәсен дә
Күп җыйнаган.
Сафлык, пакьлек
Иргә киткән,
Тешен кысып
Сабыр иткән.
Ирне ир дип
Гомер иткән.
Хәер,
Сез яшьләргә
Ике айга
Шул чемодан
Бик тә җиткән»,—
Дигән дә
Хөппи әби
Үз юлына киткән.

## КАЕН ҺӘМ ЮКӘ

Чәпчеде каен юкәгә:
— Мин агачның агачы!
Алдымда берни дә тормый
Хәтта алмагачы!
Миннән себерке ясыйлар,
Синнән — черек мунчала.
Себеркем белән кинәнеп
Чабыналар мунчада.
Ул кеше өчен шифалы,
Дару кебек сихәтле.
Хуҗалыкта да юк агач
Миннән битәр кыйммәтле!..
Юкә әйтте тыныч кына,
Чәпчүенә карамый:
— Кәперәймә,
Синең тактаң коймага да
Кагарга бит ярамый!

## СЫРАХАНӘ ЯНЫНДА

Озын чәчле яшь бер чибәр егет
Кайдан алган яхшы гадәтне?
Килгән саен илле грамм сала —
Кеше булса булыр әдәпле.

Аз эчәсең, димен, тәртиплесең,
Акыллысың, хәйран китәрлек.
Ә бу әйтә: «Абзый, исе килсен,
Җүләрлеге миндә җитәрлек».

## ЗӘХМӘТ

Өйләнеп җибәрде Фәрит,
Кыз менә дигән иде.
Гаиләне алып барырга
Бар яктан килгән иде.

Дөнья шундый: юк хәсрәтне
Эзләтә дә таптыра.
Бер-береңне йә хатыннан,
Йә үзеңнән «чактыра».

Алар да шулай булдылар,
Бозылды тормышлары.
Сүрәнләнә барды көннәр,
Хисләрнең агышлары.

Ничә китеп, ничә кайтты,
Юк, тарта өйгә күңел.
Әйтерсең лә шул чәчбисез
Яшәве мөмкин түгел.

Әйттеләр: «Нишләп йөрисең,
Кимсетеп ир-ат затын?
Тот та өйлән башкага,
Бетпәнме сиңа хатын?»

— Аңламыйсыз, — диде Фәрит, —
Шулаен шулай да, тик...
Ул зәхмәт хатын түгелдер,
Гүя ул бер наркотик.

## ГАРИП КАЛДЫ

Яхшы кеше, уңган егет
Шофер Солтан.
Ниләр килми алтын кебек
Кулларыннан!
Дуслар бердәм, чумара да
Уртак иде.
Хезмәт кергән, аз булса да
Кабыйм, диде.
Иртүк торып баш төзәтү,
Аннан — әбәт...
Кичләрен дә салмады ул
Һич тә жәлләп.
Көнен салды, атна салды,
Елын салды.
Инде салмас, параличтан
Гарип калды.

## ӨР-ЯҢА ПЕРСИДӘТЕЛ

1

Туйган идек,
Күпне чөйдек:
Берсе — надан, берсе — яман,
Берсе — куык, берсендә — тел.
Җибәрделәр безгә тагын
Өр-яңа бер персидәтел.

Килеп төште һәм кереште
Җиң сызганып,
 Эшләпәсен кыңгыр салып,
Басуларны йөреп чыкты,
Түтәйләрне күреп чыкты,
Кайберсенә кереп чыкты.
Кызып китеп,
Ферманы да карап чыкты,
Мал-туарны барлап чыкты.
Һәм шуннан соң
«Не то!» диеп,
Каш сындырып йөзен чытты.
Үзбәкчәләп тел шартлаткач:
— Кич җыелыш идарәдә,
Йөз процент явка булсын,
Аңлагансыз, Илдар ага! —
Диеп, яңа персидәтел
Китте-барды шул арада.

2

Җыелыш бара.
Халык — колак.
«Леп-леп» йөрәк,
«Келт-келт» сәгать.
— Ни ит, ни сөт,
Ни җон, ни май
Колхоздагы терлектән.
Полный лилипутия бит!
Бар мал вакланып беткән.
Дүрт йөзгә якын сарык
Берсеннән-берсе арык.

Көлке тагы сыерлар,
Җилем селкеп су ера.
Минем тәкъдим: суярга!
Кәҗә хәтле андый сыер
Чынлап торып закусить итсәм
Минем эчкә дә сыяр.
Казларны сую хаҗәт!
Пускай алар аз булсын,
Аз булса да китайски,
Пләмәнни каз булсын!
Аннан үрдәк мәсьәләсе:
Ул үрдәкләр үрдәкмени,
Күргәзмәдә үрнәкмени?
Чыпчык хәтле биш йөзе дә —
Нәселсез барлык үрдәк.
Алпан-тилпән килеп бүтән
Йөрмәсләр безне үртәп.
Суярга, диеп әйттим,
Сатарга минем тәкъдим.
Юкмы Сәвиткә каршылар?
Юк, минемчә!
Әйткәнемчә,
Өстән килде шундый карар:
Токымлы мал арттырырга,
Долой җыен лилипутлар!
Кирәк барсын весь кырырга,
Кырып бетереп фермабызга
Нәселле мал тутырырга.
Шулай иткән чакта гына
Безнең эшләр гөрләячәк.
Һәр колхозчы йөрәгендә
Эш ялкыны дөрләячәк.

3

Җыелыш бетте.
Көннәр үтте.
Үрдәк-казлар очып китте;
Сарык, сыер — бар лилипут
Фермабыздан таеп бетте.
Хәзер бездә токымлы мал.
Барсы — эре,
Барсы — үрнәк:
Җиде сыер,
Унбер сарык,
Унике каз,
Унбиш үрдәк.
Колхозыбыз гөрли хәзер,
Йөрәкләр дә дөрли хәзер.
Бар колхозчы үзбәкчәләп
Тел шартлатып йөри хәзер.
Молодец шул персидәтел,
Белә икән эшнең рәтен.
Дөрес, бу да бик аз торды.
Аз торса да колхозны ул
Агач атка атландырды.
Теңкә корды.
Күпне чөйдек:
Берсе — надан,
Берсе — яман,
Берсе — куык,
Берсендә — тел.
Тагын өстән килә, имеш,
Менә дигән персидәтел.

## ТИКШЕРДЕЛӘР

Аракы сөйгән берәүне
Җыелышта «теттеләр».
Соңыннан өенә барып,
Төне буе разбой салып,
Самогонын эчтеләр.

## КӘСЕПЧЕЛӘР

Дөнья матур, дөнья көлеп тора,
Кояш җиргә нурын сибеп тора.
Кәсепчеләр тулы илнең көне
Алар кәсебенә эленеп тора.

Мәскәү яктан капчык-капчык әйбер
Базарларга ташый кәсепчеләр.
Ул әйберне биш-ун бәясенә
Сатып ала эшле хәерчеләр.

Завод-фабрикасы бөлеп тора,
Үзенә эшче куллар көтеп тора.
Кәсепчеләр анда барамы соң! —
Хәрәм акча килмәгәнен белеп тора.

Арзан рекламада халык артистлары
«Зәңгәр экран»нардан көлеп тора.
Алары да әллә кәсепчеме?
Юк, фәкыйрьләр! Акча эшли — күренеп тора.

Дөнья матур, дөнья көлеп тора,
Бу тамаша бәгыремне өтеп тора.

## ТӨРЕК КАЕШЛАРЫ

Һай, бу төрек каешлары —
Чалбарның дәрәҗәсе!
Ләкин шактый кимсетә ул
Татарның шәҗәрәсен.

...Бабайлар мал асраган,
Караганнар атын да.
Күн-каеш эзләп бармаган
Мәмләкәтләр катына.

Тиресен дә иләгәннәр,
Теккәннәр кәвеш-читек.
Шуның белән көн күргәннәр
Җирдә бер дигән итеп.

Ясаган каешлары да
Алып торган күз явын...
Бүген каеш эзләп йөрим —
Бу нәрсә бу, Ходаем?!

Айкап чыгам базарларны,
Күн-каешлар — читнеке.
Аптырыйм: ил хәтле илдә
Кая соң, дим, безнеке?

Ни гаҗәп: маллар азайган,
Кыдырылган атлар да.
Шуңадыр күн мал артыннан
Барабыздыр ятларга.

...Һай, бу чит ил каешлары —
Чалбарның дәрәҗәсе!
Рәнҗидер Ил, Бабайларның
Тарихи шәҗәрәсе.

## МАРЬЯ, ЛИНА, НАТУША

Кашың ай күк билен бөккән,
Ә Ходай пәрештә иткән.
Җапрак бәйрәмнәре җиткәч,
Ни эшләрбез соң без, иркәм?

Кушымта:

Чибәрләрнең чибәре шул
Марья! Лина! Натуша!
Әти-әни, ерак җиңги
Сезне сөймәскә куша.

Патша тәңкәләре таккан,
Кәлүшләр аягында.
Барлык дуслар көнләшерләр,
Балкып торсаң янымда.

Кушымта.

Җиде күлмәк, дүрт балитәк
Приданыйга тулырмы?
Питрауларда гөрләттереп
Туй итәсе булырмы?

Кушымта.

Күгәрчен сөтләре салып,
Алтын чәркәләр бирсәм,
«Прощай, милай, до свидания»,
Диеп дәшмәссеңме икән?

Кушымта:

Чибәрләрнең чибәре шул
Марья, Лина, Натуша.
Әткәй, әнкәй, Иван дәдәй
Сезне алмаска куша.

## СЕРЛЕ КӨЧ

Көчле тартылдылар бер-берсенә,
Гүя Кояш һәм Ай шикелле.
Кыз Ай төсле аны нурга күмсә,
Егет Кояш сыман ялкын китерде.

Күк Кояшсыз-Айсыз булмагандай,
Мәхәббәт тә булмый кавышусыз.
Хисләреңнән такыялар үреп,
Якынаю, барышу-алусыз.

Вәгъдә бирештеләр. Кыз әтисе
Кайнар самавырдай кызды да
Сөрән салды:
— Сәйфулланың йолкыш ул малае,
Үз колагын күрә алмаган күк
Күрә алмас минем кызны да!

Кояшта да таплар булган кебек,
Ай битендә дә бар «чытык»лар.
Кышкы зәңгәр төндә ике йөрәк
Кинәт кенә юкка чыктылар.

Үтте еллар... Алар кире кайтты,
Оныгы төшми карт тезеннән.
Һәм карт әйтте:
— Бу дөньяда Сөю дигән нәрсә
Көчлерәк шул ата сүзеннән!

***

(Пародия)

Каршы алган да озаткан
Аккош күле бар иде шул,
Аккош күле бар иде.

*Мөдәррис Әгъләмов*

Аккош күле дәверләрдән,
Гасырлардан бар иде.
Классиклар исән чакта
Безгә юллар тар иде.

Квартирдан куучылар
Яшьтән сөйгән яр иде.
Карт-корылар дөнья куйгач,
Безгә дә йорт бар иде.

Алпан-тилпән кайткан еллар,
Билдән биек кар иде.
Минем үлемнән саклап калган
Аккош күле бар иде шул,
Аккош күле бар иде.

## ФӘРЕШТӘ ДӘ ИРЛӘР КЕБЕК

(Пародия)

Ник хисләнәм әле дисәм бу кичтә,
Сөбханалла, иңем сыйпый фәрештә.

*Дания Галәми*

Янып тора йөзең, диде,
Буй-сынымны карады.
Алларына утыртты да
Чәчләремне тарады.

Аннан күчте билләремә,
Күкрәкләрне сыйпады.
Хур кызлары ашый торган
Җимеш белән сыйлады.

Сөям, диде, көям, диде,
Нахалланды ул кичтә.
Хисләнерсең, бер хатын-кыз
Түзә алмый бу эшкә.

Чут-чут итте,
Чуп-чуп үпте.
Аңым җуйдым соңыннан.
Фәрештә дә ирләр кебек
Бик мут икән, чукынган.

## АВТОР ТУРЫНДА

Мансур Әхмәт улы Шиһапов 1940 елның 1 маенда Балык Бистәсе районының Яншык авылында туа. Башта туган авылы мәктәбендә укый, аннары шул ук районның Олы Солтан урта мәктәбен тәмамлый.

1957—1961 елларда ул В. Качалов исемендәге Зур драма театры каршында оештырылган Казан театр студиясендә артистлык һөнәре ала, бер үк вакытта Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист булып эшли. Соңрак исә Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый.

М.Шиһапов 1972—1974 елларда Татарстан Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге җитәкчесе булып эшли. Аннары 1974 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына баш администратор итеп чакырыла һәм анда бу вазифаны 1976 елга хәтле үти, ә 1976 елда — Казан дәүләт курчак театры, 1979 елда Күчмә театр директоры итеп билгеләнә. Ул әлеге театрның статусын күтәрүгә, аны стационар Татар дәүләт драма һәм комедия театры итеп үзгәртүгә ирешә.

Җитмешенче елларда берничә сәхнә әсәре иҗат итә. Гадел Кутуйның «Рөстәм мажаралары» повесте буенча эшләнгән «Безнең яшьлек ничек башланды?» спектакле 1977елда Казан дәүләт курчак театры сәхнәсендә куела.

1982 елда Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча эшләнгән «Кошның да үз оясы була» спектакле һәм Мәҗит Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча эшләнгән инсценировкасы Татар дәүләт драма һәм комедия театрында уйнала. 1992 елда ул СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алына.

1990—1996 елларда — Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, 1996—2009 елларда С. Сәйдәшев исемендәге Казан дәүләт Зур концерт залы директоры булып эшли.

М. Шиһаповның төп әдәби юнәлеше — үзенчәлекле, ифрат дәрәҗәдә халыкчан булган җырлары. Аның «Әйләнеп кайтыгыз», «Туй күлмәге», «Яшьлегем эзләре», «Өлешемә тигән, әй көмешем», «Сагыныр өчен», «Кыр казларын бергә каршылыйк», «Мишәр кызы» һ. б. шигырьләренә профессиональ композиторларыбыз язган җырлары зур танылу алды. Шагыйрь хәзер йөздән артык җыр, 12 шигырь китабы авторы, Халыкара телевизион эстрада фестиваленең «Татар җыры-2000» бәйгесе лауреаты.

Мансур Шиһапов — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре һәм атказанган сәнгать эшлеклесе. 2000 елда Татарстан Республикасы Президентының Мактау хатына лаек булды.



Минтимер Шәрип улы Шәймиев, мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм шагыйрь Мансур Шиһапов (уңда) Казан дәүләт Зур концерт залында.

Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин (сулдан дүртенче) һәм Мансур Шиһапов (уңда) сәнгать әһелләре арасында.





Шагыйрьнең әнисе Нәфисә
Мансур белән.



Мансур Шиһаповның әтисе
Әхмәдетдин Шиһапов.



Биш бертуган әтиләре сугыштан кайткан көнне төшкән рәсем. *Алгы рәттә уңнан сулга:* абыйсы Миңнеәхмәт, Мансур, абыйсы Рәшит; *арткы рәттә:* абыйлары Равил һәм Хуҗаәхмәт.

Абыйсы Хуҗаәхмәт.

Абыйсы Равил.

Мансур Шиһапов.

Абыйсы, булачак шагыйрь Рәшит Шиһапов.











Шагыйрьнең хатыны Клара ханым.



Мансур Шиһапов.



Мансур Шиһапов композитор Сара Садыйкова белән.

Казан дәүләт университетының журналистика факультетында укыган еллар. *Уңда* язучы Мөхәммәт Мәһдиев.





Татарстанның Апас районында узган әдәбият һәм сәнгать көннәре. *Сулдан уңга:* Илдар Юзеев, Мансур Шиһапов, Рәшидә Җиһаншина, Равил Тумашев.

Мансур Шиһапов Казан дәүләт Зур концерт залының 10 еллык юбилей кичәсендә чыгыш ясый.





Кызлары Эльвира һәм Ләйсән әтиләре янында.

Тулы гаилә.





Якташлар арасында.

Шагыйрь иң якын туганнары белән.





Илһам Шакиров шагыйрьне юбилее белән котлый.

Мансур Шиһапов абыйсы шагыйрь Рәшит Шиһаповны юбилее белән котлый.





Юбилей кичәсендә Мансур Шиһаповны Хәлим Җәләлов котлый.

Мансур Шиһапов һәм дирижер Владимир Спиваков.





Мансур Шиһапов композитор Резеда Ахиярова һәм җырчы Венера Ганиева янәшәсендә.

*Уңнан сулга:* Мансур Шиһапов, Хәйдар Бигичев, Татар опера һәм балет театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов.





Шәмсия Апакай Америкадан кунакка кайткач.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры Мансур Шиһапов театр ветераннары белән.





Мансур Шиһапов, пианист В.Чачава, җырчы Л.Казарновская Казан дәүләт Зур концерт залында.

*Уңнан сулга:* Опера җырчылары Азат Аббасов, Рәисә Билалова, шагыйрь Мансур Шиһапов.





Мәдәният министры Зилә Вәлиева, дөньякүләм атаклы виолончелист, дирижер Мстислав Ростропович һәм Мансур Шиһапов Зур концерт залында.

Шагыйрь һәм академик Роальд Сәгъдиев.



## ЭЧТӘЛЕК

Моңлы шагыйрь. Ә. Сафиуллин ........ 3

**Тормыш күкрәгендә бәргәләнәм**

Яшәү мәңгелек ........ 11
Кеше һәм заман ........ 12
Ирексез ........ 12
Гомер хакы ........ 14
Бер авыл баласы мин ........ 15
Йөрәгеңне тыңла ........ 16
Әйләнәмдә — сары яфрак шавы ........ 16
Югалтулар ........ 17
Җан ачысы ........ 18
Әткәм сулышы ........ 19
Ямансу минутларда ........ 20
Көз ........ 21
Милли җыр ........ 22
Йолдызлыклар астында ........ 23
Кем кирәк? ........ 24
Хата киңәш ........ 24
Хистә уйнаклар ........ 25
Җиңү көне җиңел бирелмәде ........ 26
Дөньяга ........ 27
Язмыш сүзе ........ 27
Ил баласе ........ 28
Хәрәкәттә — бәрәкәт ........ 29
Йөрәк авазы ........ 30
Казанның тарихи вокзалы ........ 31
Гүзәл затка бир түзем ........ 31
Булса да ........ 32
Юлга чыксаң ........ 33
Таза рух — хезмәттә ........ 33
Җыр иштәм таулар иленнән ........ 34
Яшәү сере ........ 35
Кайда соң? ........ 36

Өметсез өмет ........ 37
Үлем дәшкәч ........ 38
Бәйсезлек ........ 39
Халкым җыелган җирдә ........ 40
Акыл сатучылар ........ 41
Сагынам Балык Бистәсен ........ 41
Туган тел ........ 42
Тарихи чир ........ 43
Яшен хатасы ........ 44
Рәхмәтле булыйк ........ 45
Көнбагыш ........ 46
Югалмасын талантлылар ........ 47
Васыять ........ 48
Нәрсә әфьюн? ........ 48
Бәлки... ........ 49
Туган ягым ........ 50
Хатирәләр яңарганда ........ 51
Күңел дулкыны ........ 52
Җир үче ........ 52
Башкала ........ 53
Соңга калмагыз! ........ 54
Яңа елда яңа теләк ........ 55
Нинди кич бу? ........ 56
Оста ........ 57
«Йодрык хәтле генә...» ........ 58
Рәнҗетү ........ 59
Идеал ........ 60
Күңел сәяхәте ........ 61
Заман һәм җыр ........ 62
Моңлану һәм сызлану ........ 62
Нигә? ........ 63
Модалар ........ 64
Үткәннәрдән бер аваз ........ 65
Заман кинлегендә ........ 66
Шуны телим ........ 67
Кайсы җан ничек ........ 68
Сабак ........ 68
Имән ........ 69
Ялгыз ана ........ 70
Йөрәк әйтә ........ 71
Сызлану ........ 72
Буран ........ 72

Ыруг ..... 73
Шигырь ..... 74
Яшәгәндә булсын ..... 75
Кеше ..... 76
Сукбай ..... 77
Киек казлар кайта ..... 79
Дула, давыл! ..... 79
Бик якын син, Яншык киче ..... 80
Тормыш җавап эзләтә ..... 80
Солдат күңеле ..... 81
Язның шаулы күкрәүләре ..... 82
Аяныч ..... 83
Ачылган сер ..... 84
Гүзәллек көче ..... 85
Айны, татар! ..... 85
Кирәклеләр китә ..... 86
Мәдхияләр кирәк әтиләргә ..... 87
Яшәү һәм үзгәртү ..... 88
Чорлар алышынганда ..... 89
Ашык, Пәйгамбәр! ..... 90
Өйрәттеләр ..... 91
Ә яу нигә? ..... 92
И Зөһрә кыз ..... 92
Солтанлы мәктәп ..... 93
Уйлар — газиз туфракта ..... 94
Ирләр йөрәге ..... 95
Утлы мизгелләрдә ..... 96
Исән-хисап ..... 96
Яшәү ..... 97
Яхшы-яманы ..... 98
Ап-ак, диләр ..... 99
Хак сүзләргә каргыш төшәмени ..... 100
Тартылу ..... 100
Кем белә... ..... 101
«Йосыф кыйссасы» ..... 102
Үткәннәр ..... 103
Хатирә йомгагыннан ..... 104
Гомер бакый булеш ..... 106
Татар холкы ..... 107
Корбан ..... 108
Ялгыз аккош кайда оча? ..... 108

Сагыш ........ 109
Хаклы шик ........ 110
Үзенә дә төшть ........ 111
Хәзерге толлар ........ 112
Уйлану ........ 112
Күкрәүләр ........ 113
Бураннар ........ 113
Күкләр алдамады ........ 114
Ахун бабай ........ 115
Тормыш бусагасында ........ 116
Кеше яши сүнгәч тә ........ 117
Ник? ........ 118
Уйлап торсаң ........ 119
Капма-каршы ........ 120
Уфтанмагыз! ........ 121
Серле өннәр ........ 122
Ниләр сөйли буран? ........ 123
Ялгыш ........ 124
Артык акыл ........ 124
Яшен ........ 125
Болытларда ........ 126
Газиз әнкәм йортына ........ 127
Басып торам чатта ........ 128
Бәхет нидә? ........ 129
Кемнәр шулай... ........ 129
Алданма ........ 130
Бәхет кыйбласы ........ 131
Кешелек сере ........ 132
Әүлиялар ........ 133
Сабантуй көннәрендә ........ 134
Ак бураннар ........ 135
Кояшка мин ышанам ........ 136
Аерма ........ 137
Бердәнбере идем җиденең ........ 138
Үзгәрми кеше ........ 138
Ил белән ........ 139
Мин бәхетсез, диеп еламагыз ........ 140
Күнелдәге моңнар ........ 141
Кышкы моңнар ........ 141
Язмыш җәзасы ........ 142
Ташлама, шигърият! ........ 143

Мирас ..... 144
Кабер ташына язылачак шигырь ..... 145
Билгесезләр ..... 145
Туган якның якты иртәсе ..... 146

## Күңеленә гөл утырткан идем

Тормыш үзе матур ..... 149
Мәхәббәт урамы ..... 150
Жылы җилләр исә ..... 151
Безнең ара ераклашкан саен ..... 151
Туган як чишмәләре ..... 152
Акчарлаклар үксе һаваларда ..... 153
Карурман ..... 153
Җан авазы ..... 154
Көзге моңнар ..... 155
Җимерелгән язмыш ..... 156
Туй күлмәге ..... 157
Татар кызы ..... 158
Бәхилләшмим — саубуллашам ..... 158
Язгы мәхәббәт ..... 160
Әйтелмәгән сүз ..... 160
Төштә генә ..... 161
Фәйрүзә ..... 162
Төшенү ..... 163
Яшьлегем эзләре ..... 163
Алдану ..... 164
Тол ханым ..... 165
Люциякәй ..... 166
Агар су булсам иде ..... 166
Нәрсә әйтим? ..... 167
Бер кабат ..... 167
Сагыну ..... 168
Мәңгелек ут ..... 169
Буләк ит син ..... 170
Тылсымлы ..... 170
Диярсең ..... 171
Әй, гафу итсәнә, йөрәгем ..... 172
Гармун моңы ..... 173
Сер... ..... 173
Көт мине ..... 174
Мәхәббәт сынавы ..... 175
Туй балдагы ..... 176

Су һаман шаулап ага... 177
Моңнар 177
Кайту 178
Ачык хат 179
Эх, гомернең агышы 180
Өлешемә тигән, әй көмешем! 181
Зәңгәр нур 181
Алма-Атаның алмасы 182
Тәңкә карлар 183
Тәңре хакы 183
Синең турында 184
Моңсыз тумый беркем дә 185
Язгы җыр 186
Килеп чыгар әле каршыма 186
Урай урманы 187
Сызланам 188
Туган җирсез яшәү юк сыман 188
Алмалары пешәр әле 189
Йөрәгем бит һаман яшь әле 190
Табигать һәм моң 190
Сүнде шагыйрь 191
Акчарлагын эзли давылым 191
Ничәнче ел ялгыз аккош кайта 192
Соңгы үпкә 193
Сынмадым-сыгылмадым 194
Кырыс җилләр 194
Тынсез ярату 195
Кичер, тәкъдир! 196
Мәхәббәтем бар 196
Үзең өчен генә өз син мине 197
Кыр казларын бергә каршылыйк 198
Хисләр упкыны 198
Ялгыз ай тиңдәшен эзли 199
Сагыныр өчен 200
Көттермәгез! 201
Син генә 202
Мин яшәргә тиеш шул хакка 202
Сызлану һәм юану 203
Иркәләнер көннәр алда әле 203
Бу җир ял йорты түгел 204
Сиңа барам 206
Нигә башны салга салырга 206

Мин сиңа үпкәләмим ... 207
Сөеләсе изге бер җан калды ... 207
Унҗиде яшем ... 208
Чистару ... 208
Могҗиза иден ... 209
Бирсәнә түзем! ... 210
Кар суында шәл ага ... 211
Үпкәләмә ... 212
Көймә чайкала ... 213
Әйләнеп кайтыгыз! ... 214
Җил ... 215
Сөю килгән кыз бала ... 215
Мәңгелек сер ... 216
Яшьлегем үткән урам ... 217
Аккош белән серләшү ... 218
Моңсыз калсам ... 219
Ничек аңларга? ... 219
Тыңладем ... 220
Сихри көч ... 220
Безнең яшьлек нидән башланды? ... 221
Май аенда кар ява ... 222
Минем өчен син генә ... 222
Синең күзләрең ... 223
Бер шагыйрьгә иярен ... 224
Күзләремнән килеп кара ... 224
Серле йолдыз — Алия ... 225
Мишәр кызы ... 226
Клара ... 227
Сулар үргә акмый, диләр ... 227
Кайтыр идем ... 228

## Җырлы мәдхиягә лаеклылар

Эзлим ... 231
Гөберчәкне монсу томан баскан ... 232
Күккә юлланган уйлар ... 232
Энекәш ... 233
Кайтыйк әле! ... 234
Сагындым ... 235
Якын дус та... ... 235
Гүя үзең булып... ... 236
«Язучыдан бөеклеккә» ... 237
Җыр пәйгамбәре ... 237

«Әти» үлде... 238
«Күп пародия яздың...» 239
«Ашкынмагыз, көрешерсез...» 239
«Тормыш көймәсен гомергә...» 240
Магнат 240
«Отелло»ны уйныйм, диеп...» 241
«Театрда уйнамаган...» 241
Тиңнәрмен 242
Исемең калды 242
Гомер шавы 244
«Әтиең — талант, әниең — канат...» 245
«Зур сәхнәдә янар йолдыз...» 245
«Т. Мин белән горләп яшә...» 246
«Әдәбият дөньясында...» 246
Ирләргә тиң пакь ханымнар 247
Үзем турында үзем 248

## Дөнья көлеп тора

Бурыч 251
Туры сүз 252
Ярсу һәм айну 252
Бәхәс 253
Бүрек белән туфли 254
Бәйрәм 255
Әби белән бер кыз диалогы 256
Каен һәм юкә 258
Сырахана янында 258
Зәхмәт 259
Гарип калды 260
Өр-яңа персидәтел 260
Тикшерделәр 264
Кәсепчеләр 264
Төрек каешлары 265
Марья, Лина, Натуша 266
Серле көч 267
«Аккош күле дәверләрдән...» 268
Фәрештә дә ирләр кебек 269
Автор турында 270

Литературно-художественное издание

**Шигапов** Мансур Ахметович

ВЕСЕННЕЕ ПОЛОВОДЬЕ

Стихи, песни

Казань. Издательство «Магариф». 2010

*На татарском языке*

Әдәби-нәфис басма

**Шиһапов** Мансур Әхмәтович

ЯЗГЫ ТАШКЫН БУЛЫП

Шигырьләр, җырлар

Редакторы *Л.Ә. Гыйззәтуллина*
Рәссамы *М.Д. Вәҗиева*
Бизәлеш редакторы *Л.С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы
*Н.А. Казакова*
Корректорлары *Р.Ә. Фәйзуллина, А.А. Дәүләтова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *М.Д. Вәҗиева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.04.2010.
Форматы $70 \times 100\,^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Коринна» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 12,03 + форз. 0,16.
Нәшер-хисап табагы 5,38 + форз. 0,25. Тиражы 500 д.
Заказ О-477.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http: //www.magarif.com

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.